Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 33 (1449) 25 август 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

12

Иске Ашыт мәдәният йортын 40 ел буе җитәкләгән Саяра Фәттерахманова – Арча районының мактаулы гражданы исеменә лаек булган шәхес.

14-15

Актаныш-Минзәлә районы җирләре әле 1523 елда ук Сәхиб-Гәрәй хан тарафыннан Шәех-Әхмәт тарханга бүләк ителә.

16-17

Туфан Миңнуллинның кызы Әлфия, нәкъ сөекле әтисенең фатихасы белән, электрон татар матбугатына нигез салучыларның берсенә әверелә.

Нинди хозурият – түр башында Җиз самавыр җырлап утырса!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Венгрия хөкүмәте чакыруы буенча шул Европа иленә сәяхәт кылды.
- Балык Бистәсе район үзәгендә хатын-кызлар һөнәрчелеге буенча «Бистә шәле» дип аталган I республика фестивале үткәрелде.
- Азәрбәйҗан, Беларусь, Израиль, Казахстан коллективлары да катнашкан һәм Владимир каласында узган «Театр. Бердәмлек мәйданы» фестивалендә Буа дәүләт театры да Раил Садриевның «Дәрвиш» моноспектакле белән чыгыш ясады.
- Яшь җырчы Саидә Мөхәммәтҗанова Әхмәт Рәшитов сүзләре, халык көе буенча язылган «Зәңгәр шәл» җырын яңартып эшләгән һәм август ахырында аның халык җырларыннан торган беренче альбомы да дөнья күрәчәк.
- Республиканың Биоресурслар буенча дәүләт комитеты игълан итүенчә, Татарстанда хәзер 226 төрдәге сирәк хайван, 318 үсемлек һәм 87 төрле гөмбә «яши» икән.
- Санкцияләргә һәм геосәясәткә бәйле түгел, дип тәкърарласалар да, сентябрь аенда кәгазь, плёнка, шешә, шәраб, коньяк бәяләре 4-5 процентка артыр, дип көтелә.
- «КамАЗ» берләшмәсенә нигез салучы, 12 ел дәвамында автогигантның беренче генераль директоры, Ватан сугышы ветераны, Социалистик Хезмәт Герое Лев Борисович Васильев 98 яшендә вафат булган.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

25 август – җәлилчеләрне искә алу көне (1944 елда бу көндә Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә. Һәр елны Казанда 1 Май мәйданындагы һәйкәл янында нәкъ сәгать 12дә Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен искә алу үткәрелә).

31 август – әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, ТАССРның, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллинның тууына 120 ел (1903–1985).

СЫНАМЫШЛАР

●26 августка каен яфраклары саргайса, тиздән кырау төшәчәк.

●27 августта талгын җил иссә, көз аяз килә; давыл купса, сентябрьдә яңгырлы була.

●28 августка кадәр уҗымнарны чәчеп бетерү мәслихәт.

●29 августта (Чикләвек Спасы) торналар киткән булса, 14 октябрьдән суыклар башлана.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 34 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 59 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **14 сәгать 25 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **1 сентябрьдә 13 сәгать 54 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 26 август.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(24-31 август)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген сәфәр аеның 9 нчы көне

ЙӨЗ ЕЛ ЭЛЕК

Бер заманнан бирле хөрмәтле ата-бабайларыбызга, чабата туфракларын авыру күзләребезгә сөрмә итеп тарту тиеш булган бөек голәмә (галим) вә хөрмәтле сәләфләребезгә (элекке кешеләребезгә), дин вә милләт юлларында газиз җаннарын вә хөрмәтле каннарын фида иткән шәһитләребезгә дин ислам өйрәтеп, ул мөбарәкләрнең дөнья вә ахирәттә бәхетле булуларына сәбәп булган милли хәрефләребезнең рус хәрефләренә алмаштырылып, тел вә әдәбиятыбызның фани дөньядан бакыйлыкка күчәчәген 31 мартта мәгариф вәзире граф Толстой тарафыннан расланган указдан газета укучылар шаять аңламышлардыр.

Калебендә дини гайрәт вә милли хәмият (саклау, яклау) булган иманлы адәмнәр моның турында азмы-күпме булса да, әлбәттә, хәсрәт тә чиктеләр, ялкынны кызу сулуларын да суламышлардыр.

Ләкин «хак мөселманмын» дәгъвасында булып та, Коръән вә хәдисчә аслан хак мөселман булмаган дәгъвалы карендәшләребезнең, дин вә дөньядан һич тә хәбәре булмаган мәгарәияләренең бу хосусларда берни белми ятуларында вә бәхетсезлек диңгезләренә батуларында тузан кадәр шик вә шөбһә юктыр.

Бу хәреф үзгәртү мәсьәләсе – тышкы яктан бик кечкенә генә вә бик тә әһәмиятсез генә күренсә дә, ләкин эчке каты гаять зур вә соңы олуг нәтиҗәле бер мәсьәләдер. Бу хакта минем фикерем күршеләремә билгеле булса да, ерак карендәшләребезгә бөтенләй белемсез вә бөтенләй караңгыдыр. Иштә, минем белүем түбәндә язылачак берничә җөмләдән гыйбарәттер. Шулай:

Без мөселман татарлар –150 миллион әһеле, 4 млн. гаскәре, бөтен җирнең алтыдан беренә хуҗалык иткән Русия хөкүмәтенең гражданнарыннан вә аның итагатьле колларыннанбыз. Бу хөкүмәтнең идарәсе мөстәкыйль идарә булып, монда баш милләт – рус милләте, бөтен диннәргә хуҗа булган дин дә – христиан динедер. Русия хөкүмәте үзе никадәр бөек булса да, әһеле 150 миллион булынса да, бу мәмләкәттә гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнәгать шулкадәр түбән вә шулкадәр арттадыр ки, Европада, Төркиядән башка, моннан артта вә моннан надан вә моннан караңгы бер хөкүмәт юктыр.

Һади АТЛАСИ

ЯҢА НИЗАМ ҺӘМ ГОЛӘМӘБЕЗ

Бу мәмләкәттә гыйлем дә юк, мәгърифәт тә юк, һөнәр дә юк, сәнәгать тә юк, прогресс та юк, хөррият тә юк. Бар нәрсә – салкынлыкта котып бозларын көнләштерерлек фанатизм, караңгылык һәм дә золым вә җәберләрдер. Хөкүмәтнең үз халкына һичбер илтифаты вә һичбер кайгыртуы юктыр. Гыйлем урынына – наданлык, хөррият урынына – пулемет, мәктәп урынына төрмәләр белән җавап бирү; бәхетләрен бәхетсезлек белән алыштырып, халкын кан дәрьяларына батыру, Себер сахраларында катыру – бу хөкүмәтнең мәңгелек борынгы гадәте вә һәм дә иң яраткан бер эшедер. Димәк ки, яраткан нәрсәсе – золым, сөйгән нәрсәсе – золым, халкын сыйлаган нәрсәсе – тагы да золымдыр...

Золымнан тыш, тагы да бер яратканы вә авызына чиләкләп суларын китерткән бер нәрсәсе бар – ул да (булса), бөтен халыкны вә, бигрәк тә, мөселманнарны руслаштыру, үзләре әйткәнчә, христиан нуры илә нурландырмактыр.

Белгәне вә яратканы каһәр вә золым булган бу хөкүмәтнең безне бетерү вә җир йөзеннән корыту фикере – бик иске вә бик тә борынгы һәм дә үзенчә беренче дәрәҗәдә кирәкле фикердер. Ничә йөз меңләрдән гыйбарәт булган мөкраһларны (көчләп чукындырылганнар) рәсми сурәттә христиан итүе, ислам динен тотканнары хәлдә араларына хөкүмәт яклавында булган миссионерларны күндерүе, поплар җибәреп аларга ирексезләп христианлык тәлкыйн (төшендерү) иттерүе, башын бөкмәгәннәрен Сибирия сахраларына сөрүе – барчасы да күз алдыбызда ап-ачык вә кояш кебек яп-яктыдыр.

Тугрысы, кыскача әйткәндә: бюрократиянең беренче максаты – безнең динебезне вә милләтебезне бетерү, җир йөзеннән корыту. Дин вә нәсәп җиһәтеннән безнең белән карендәш булган ничә йөз мең адәмнәрне христиан итүе, үзе теләгән чокырларга салып хәрәкәттән вә бәрәкәттән мәхрүм итүе күз алдыбызда тулган вә ялтырап ята. Безне дә шуларча итү, дин вә милләтебезне үзенең сөйгән дине белән алыштыру хакында хөкүмәт күп заманнардан бирле тырышып килә, максатын акрынлап булдыра бара, күпме еллардан соң безне дә тәмаман хак христиан итәчәгенә канәгать кыла. Тыштан гаскәр вә җәберләү көче кулланмаганында да, хәрби көч канаты астында булган миссионерлар, инсафсыз вә вөҗдансыз чиновниклар аркасында безне корытачагына ышана һәм, сугым симерткән кебек, вакыт җиткәнче симертүдә иде. Заманнар искечә барса, җилләр һаман бюрократия теләгәнчә уңайлы яктан гына исеп килсә, безне бетерәчәгендә, дин вә милләтебезне тузан кебек итәчәгенә тузан кадәр шик вә шөбһә дә юк иде. Бу тарихтан 3-4 ел элек мин үзем безне бетерәчәген, динебезне вә милләтебезне корытачагын бик ачык белә идем. «Бетәбез, юкка чыгабыз!» җөмләләрен җан ачысы белән кычкыра, ни кылырга белмичә, ут эчендә калган күгәрчен кебек ахылдап, төрле тарафка чабуда идем...

Хәмедләр вә шөкерләр булсын, җилләр искечә исмәде. Заманның тәгермәчләре залим бюрократия теләгәнчә әйләнмәде. Киресенчә, бөтенләй башка вә аларның теләвенә кире булган бер тарафка хәрәкәт итте... бер дә хисапламаган җирдә вә әллә кайдан гына Япония сугышы килеп чыкты... Порт-Артур, Мукден вакыйгалары, Сусима мәсьәләләре кебек хәл кылуы мөшкел булган гаять авыр мәсьәләләр галәмгә баш күтәрде...

Вөҗданлы вә инсафлы, безнең дусларыбыз дип тәгъбир итдегемез рус каһарманнарының тартышу вә тырышулары, 1904-1905 елларының хәрәкәтләре, октябрь, декабрь вакыйгаларыэшнең тәртибен бөтенләй бозып ташлады...

Черек карт имән агачының куәтле җил белән пракында булганы кеби, хөррият җиле белән черек, залим бюрократия да пракында булып сөртелеп китте.

Гаять юаш вә гаять мазлум булган бер милләтне бетерергә бар куәтен сарыф иткән залимнәргә үзләренә торырга урыннар тар калды. Яшеннән качкан шайтаннарга, карчыгадан качкан чыпчыкларга, бүредән качкан этләргә урыннар тар булган кебек, безне бетерергә бөтен көчләрен сарыф кылган күзлекле еланнарга да киң җир өстендә, бер аршин кадәр булса да, кабердән башка тыныч урын калмады. Кайсысылары – Франциягә, кайсылары Швецариягә китте-барды. Ләкин хөррият хәрәкәтләре вакытында тау тишегендәге елан кебек боегып яткан зәһәрле еланнар бүгендә терелә башлады. Җыенда үзен куштаннар кыйнап эт иткән мужикның өенә кайтып, ачуыннан күсәк белән атны, чыбыркы белән хатынын кыйный башлаганы кебек инсафсыз вә кара йөрәкле бюрократлар да, хезмәтчеләр ачуын бездән ала башладылар. Бу көндә ачык сурәттә динебез вә милләтебезгә җинаять кылдылар. Җәнаб Хак тарафыннан, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәламгә аның белән Кәлам Шәриф иңдерелгән мөкаддәс хәрефләребезне, тел вә әдәбиятыбызны аңлатуда бөтенләй кимчелекле булган рус хәрефләре белән алмаштырып уку хакында законнар чыгардылар. Сәяси вә гражданский хокукларыбызны алып җәберләү җитмәгән кебек, рухани вә дини булган җәберләрне бу көнгәчә татыганыгыбыз тоярлык булмаган кебек иң актыккы җәберләргә бу көндә тагын да башладылар. Әүвәлдәге рәнҗүләре бетмәгән, борынгы яралары да төзәлмәгән йөрәкләребезгә ханҗәрләр белән тагын да чәнчеделәр... корырга җиткән каннарыбызга, чыгарга җиткән җаннарыбызга тагы да агулар сиптеләр. Беренче буларак, эшне хәреф үзгәртүдән башладылар. Әлдә сезне күп саклап килдек, вакыт җитте дип, һичбер карышуларыбызга илтифат итми, эшкә керештеләр. Аз булса да уянуыбызны күреп, көч белән тиз заманда эшне башкарырга уйлап һөҗүм иттеләр. Ильминский кебек ислам бәласе булган адәмнең планын аз заман эчендә чынбарлыкка чыгарып, дин вә милләтебезгә хатем бирергә чын көч белән керештеләр. Аман, йә Рабби, Аллаһуммәх-фазнә!

Тагы да кыскарак аңлатам: бюрократиянең әүвәлге вә хакыйкый фикере безне бетермәктер. Хәреф үзгәртү – шуның бер башыдыр.

Әй, дин башлыгы хисап ителгән безнең голәмә-әнбияләр (нәби, пәйгамбәр) варисларымыз! Сезләр кайдасыз? Сезнең гайрәтегез вә һиммәтегез кайдадыр? Сезнең хәмиятегез (яклау) кай җирегездәдер? Сезнең мөселманлыкыгызның мәгънәсе нидер? Пәйгамбәрләр варислыгыгыз кай кулыгызда, кай җирегездәдер? Сезнең калебләрегезнең нуры, хәяте кайдадыр?

(Дәвамы 4 нче биттә).

Олуг галим белән хушлашу

18 августта, 95 яшендә, танылган филолог-галим Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев вафат булды. Ул филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Россиядәге лингвистика академиясе академигы, Татарстан Фәннәр академиясенең гуманитар бүлеге академик-секретаре, Халыкара төрки академиясенең татар бүлеге бюросы рәисе, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты, Башкортстан Республикасының Җәлил Киекбаев премиясе лауреаты (1993), «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» медале иясе (2015). Казанның мактаулы гражданы (2021) иде.

Мирфатыйх Зәкиев 1928 елның 14 августында Татарстанның Ютазы (хәзер Баулы) районындагы Зәйпе авылында туа. Аңа 5 яшь тулганда, колхоз рәисе булып эшләгән әтисе Зәки, салкын тидереп, 1933 елда дөнья куйган. М.Зәкиев әнисенә 5 баланы тәрбияләүдә булыша. Сугыш елларында көтүче, ат караучы, кышын туң тирес чабучы, тимерче, эретеп ябыштыручы һ.б. хезмәтләр башкара. Тырышлыгы «Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакяр хезмәт өчен» медале белән бәяләнә. Мәктәпне «бишле»гә тәмамлап, Казан дәүләт университетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Университетны кызыл диплом белән тәмамлый, аспирантурада калдырыла. 1954 елда кандидатлык диссертациясе яклый. Башка милләтләрнең грамматика китаплары белән эзлекле танышкач, татар теле буенча шундый хезмәт язып бастырды. «Синтаксический строй татарского языка» дип аталган 464 битлек китабы докторлык диссертациясе буларак бәяләнә. Диссертация 1962 елда яклана.

М.З.Зәкиев 1960-1965 елларда – КДУның татар теле кафедрасы мөдире, 1965-1967 елларда Казан дәүләт педагогия институтында фән буенча проректор булып эшли, 1967-1986 елларда Казан дәүләт педагогия институты ректоры вазифаларын башкара, бер үк вакытта, 1968-1986 елларда институтның филология факультетында татар тел белеме кафедрасы мөдире вазифаларын да алып бара. 1986-1996 елларда ул – СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалында Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры (1992 елдан Татарстан фәннәр Академиясе составында), 1996-2000 елларда Татарстан фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры булып эшли, шул ук вакытта, 1992-2002 елларда – ТФАнең гуманитар бүлеге академик-секретаре, 1980-1990 елларда ТАССР Югары шурасы депутаты һәм Татарстан АССР Югары шурасы рәисе вазифаларын да башкара. Галим һәм остаз буларак, М.Зәкиев җитәкчелегендә 60 ка якын фән кандидаты һәм 18 фән докторы әзерләнә. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен орденнары, күпсанлы медальләр, мактаулы исемнәр белән бүләкләнә.

Күренекле галим вафат булу уңаеннан Татарстан Рәисе Р.Н.Миңнеханов, Татарстанның Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы рәисе Ф.Х.Мөхәмматшин, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Р.Н.Миңнеханов Мирфатыйх Зәки улының гаиләсе, якыннары һәм хезмәттәшләренең кайгысын уртаклашты.

М.Зәкиев 2023 елның 20 августында Казанның Самосырово бистәсендәге мөселман зиратында (Шәмсир) хатыны Лена янәшәсенә җирләнде.

Җилкендерә торган көн

Татарстан һәм татар халкының иң яңа тарихында тирән эз калдырган дата – 30 август якынлаша. Моннан 33 ел элек бу көнне ТАССР Югары Советы Татарстанның дәүләт суверенлыгы турында декларация кабул итте.

Тарихи үзгәрешләр ягыннан бу вакыт аралыгы гасырларга тиң вакыйгаларны колачлады, инсаният яңа гасыр һәм яңа меңъеллыкка да аяк атлады. Зурдан алганда, кешелек дөньясы үз тарихында моңарчы билгеле булмаган, төрле тетрәнүләр вә глобаль янаулар белән тулы яңа эпохага кереп бара дисәк тә, әлләни арттыру булмастыр. Кардиналь үзгәрешләр халыкара мөнәсәбәтләрдә, хокук нормаларында яисә инсаниятнең иҗтимагый-сәяси яшәү рәвешендә генә түгел, ә кешеләрнең әдәп вә әхлагында, рухи кыйммәтләрендә һәм дөньяга карашында да бара. Геосәяси терминнарга күчерсәк, дөнья тотучыларның «яңа дөньяви тәртип урнаштыру» дигәннәре шул буладыр инде. Глобаль үзгәрешләр чорында, әлбәттә, бер Татарстан гына тотрыклылык утравы булып кала алмый (аңа андый мөмкинлекне бирмәсләр дә иде). Нәтиҗәдә, Россиядәге башка милли республикалар белән бергә, Татарстан да, «суверенлык» сүзенең «С» хәрефе дә калмаслык итеп «чистартылды». Шуңа да карамастан, бу истәлекле дата милли үзаңы югары, иманы нык, аек фикерле татар кешесендә бүген, ул шанлы көннәрне хәтердә яңарту һәм сәяси романтизм чорындагыдай җилкенеп алу белән бергә, мөгаен, шактый ук каршылыклы вә үкенүле фикерләр дә уятадыр.

Әлбәттә, үткәнне инде кире кайтарып булмый, аннан бары тик гыйбрәт вә сабак кына алып була. Әмма Татарстанның милли вә рухи күтәрелеш елларында халыкара нормаларга таянып ясаган хокукый адымнары, бүген генә түгел, киләчәктә дә җитди үзгәрешләр өчен хокукый нигез булып калачак. Милли яшәешебездә әле бүген дә дәвам итә торган чигенүләр һәм киләчәк темасына тукталыйк. Дөресе шул: бүген хокукый, сәяси, икътисади һәм хәтта милли-мәдәни планда да чигенергә җирлек калмады да сыман. Дәүләти яктан да республиканың хәзер «исеме бар, җисеме юк» килеп чыга. Чөнки дәүләт атрибутлары бар, ә хокукый яктан милли республика өлкәләрдән берни белән дә аерылмый. Бурычларда гына аерма шактый һәм ул салым күләме ягыннан да, хәтта МХО зонасы өчен батальоннар әзерләгәндә дә сизелә (аларга атама да ни өчендер татарча бирелә). Хәлбуки, Татарстанга «ышанычы» халыкара дәрәҗәдә төрле чаралар үткәргәндә дә күрсәтелә. Сүз монда мәдәни яки спорт чаралары турында гына түгел, фәнни һәм хәтта сәяси чаралар хакында да бара. Соңгылары рәтенә, әйтик, Казанда 28-30 август көннәрендә узачак Глобаль яшьләр саммитын, яки 2024 елда республикабыз башкаласында җыелачак БРИКС саммитын да кертергә була (җөмләдән, БРИКС белән бәйле хәл мондый ышанычның сәбәпләренә дә ачыклык кертә. График буенча 2024 елда ул Бразилиядә узарга тиеш була. Ә бу ил, «Зур егермелек»тә дә рәислек итү сәбәпле, чиратны алышырга Россиягә тәкъдим итә. В.Путин исә БРИКС саммитын үткәрү урыны итеп Казанны билгеләи. Әйе, БРИКС хисабына үткәрелгән чараның отышлы яклары да бар, ә мәшәкатьләре күбрәк).

Чигенүләргә килгәндә, бүген милләтнең киләчәгенә зур куркыныч тудыра торган юнәлешләр булып милли һәм рухи тәрбиянең зәгыйфьләнүе, шулай ук туган телебезнең хәзерге бик тә аяныч хәле кала. Күрүебезчә, алар барысы да милли мәгариф өлкәсенә карый. Ә ул соңгы елларда дәүләт үткәрә торган милли сәясәт концепциясе нигезендә җимерелде. Нәтиҗәдә, совет чорыннан аермалы буларак, туган телдә белем вә тәрбия алу мөмкинлеге, калаларда гына түгел, хәтта татар авылларында да бетерелде һәм балалар анда инде үзара да күбрәк урысча аралаша. Чигенүләр әле дә бара. Хәлнең өметсезлеген узган атнада Казанда үткән август киңәшмәсе дә күрсәтте. Белем бирүнең яңа феде-раль стандартларына күчү, «Разговоры о важном» дәресе, флаг күтәрү, гимн тыңлау, тарих дәреслекләренә Украинада үткәрелә торган МХО турында материал өстәү һ.б. – болар һәммәсе дә милли сәясәт концепциясен гамәлгә ашыру галәмәте инде. Бу исә мәгарифнең милләткә түгел, ә сәясәткә хезмәт итүен күрсәтә. «Мәскәү электрон мәктәбе»нә бушка кереп, анда татар телен укыту җае булдырылуына куану, Мәскәү белән Казан өчен цифрлы бердәм мәгариф экосистемасы булдыру кебек чаралар да шул җөмләдән. «Бесплатный сыр бывает только в мышеловке», – ди урыслар андый чакта. Ә Татарстанның кайбер район үзәкләрендә бер генә татар мәктәбе дә калмавы кебек хурлыклы фактлар ул киңәшмәдә күтәрелмәгән дә. Татар теленең бүгенге мөшкел хәле өчен дә җавап тотучы юк. Әйе, хәл ителәсе мәсьәләләр бихисап. Әмма халык вә хакыйкать безнең якта. Шуңа күрә Җәнабе Хак татарга бүген киләчәкне җайга салуның метасәяси ачкычын тапшыра да. Әмма ул аны дөрес итеп куллана алырмы – бусы инде аның ихтыяр көченнән, рухи әзерлегеннән һәм иман ныклыгыннан тора.

Фоат УРАЗАЙ.

Юл авариясендә 8 кеше вафат

21 августта Ростов өлкәсендәге юл авариясендә берьюлы 8 кеше: өйләнешергә йөргән егет белән кыз, икенче машинада 4 бала һәм аларның ата-анасы һәлак булган. Бу турыда «Комсомольская правда» хәбәр итте.

Юлда баручы бер машинага көйләнгән видеокамера язмасы аны гаҗәеп зур тизлек белән «Лада Приора» машинасы узып китүен, ә андагы руль артында 23 яшьлек егет идарә итүен терки. Ул каршы як полосага чыга һәм «ВАЗ-2114» машинасына бәрелә. «ВАЗ» машинасында 4 бала һәм ир белән хатын була. Машиналар металл өеменә әверелә, 2 машинадагыларның барысы да вафат була.

Мәрхүм гаилә башлыклары бик җаваплы эти-әни буларак билгеле. Фаҗига булган көнне гаилә Волгодонск шәһәренә мәктәп кирәк-яраклары: олы балаларына мәктәп формасы алу өчен, ә кечесен иптәшкә алып барганнар.

Мәрхүм гаилә турында бистә халкы яхшы сүзләр генә сөйли. «Әниләре эшләми, балаларны карый. Ир белән хатынның 2 улы һәм 2 кызы бар. Әниләре ата-аналар җыелышына бармый калмый, 3 баласының өлгереше белән кызыксынып тора. Кече кызлары әле мәктәпкә йөрми», – ди мәктәп хезмәткәрләре.

Укытучылар сүзләренчә, балалары да шат күңелле, мәрхәмәтле булган. «Өстәмә дәресләргә йөрделәр, яхшы укыдылар, бәхетле гаилә иде», – ди алар.

«Лада Приора» хуҗасы да – күрше генә бистә егете. Ул өйләнергә җыенып йөргән. Машинада янында кәләше дә булган.

Россия Тикшерү комитетының Ростов өлкәсе буенча Тикшерү идарәсе җинаять эше ачты.

1 нче биттә – Әтнә районының Кышлау авылында үткәрелгән «Җиз самавыр» фестиваленнән бер күренеш. С.Кашапова фотосы.

Бронь мобилизациядән коткармый

Эш урыныннан бирелгән бронь 100 процент мобилизациядән котылып калу чарасы түгел. Ханты-Мансий автоном округы судындагы карар шуны күрсәтә, дип яза «Московский комсомолец».

Сургутта яшәүче Сергей Вахрамеевны октябрь аенда мобилизациялиләр. Ул «Сургутнефтегаз» оешмасында эшләгән була. Сергей, броне булуы сәбәпле, военкоматны судка бирә. Әмма беренче инстанцияне дә, югары инстанцияне дә оттыра. Июль аенда суд коллегиясендә дә аның броне кире кагыла. Апелляция карарында судьялар броньнең ни сәбәпле 100 процент гарантия булмаганын аңлаткан.

Бронь мобилизация чорында түгел, тыныч вакытта бирелергә тиеш. Мобилизация башлангач, «ишекләр ябыла». Эш бирүче Сергейны исемлеккә өлешчә мобилизация башлангач керткән, шуңа да аның броне «дөрес түгел» дип табылган.

Кемгә бронь бирелә икәнен эш бирүче түгел, военкоматлар хәл итә. Монда кешенең яше, хәрби званиесе, белгечлеге, кем булып эшләве карала. Дөрес итеп һәм вакытында бирелгән броньга гариза да хәл ителәдигән сүз түгел. Моны Дума депутаты Виктор Соболев та раслый. «Бронь өчен «тимер нигез» – оборона комплексы предприятиеләрендә эшләү, – дигән ул. – Ул кеше гариза язып, броньнан баш тарта ала, андыйлар күп».

ХМАО суды карарыннан чыгып фикер йөрткәндә, хәтта хәрби заводта эшләү дә бронь алуга гарантия түгел. «Бронь отсрочка бирүнең абсолют нигезе була алмый. Мобилизацион чараларны тормышка ашыру өчен, военкомат броньле кешеләрне дә алырга хаклы», – диелгән анда.

Айтишниклар мобилизациягә алынмый, дигәннәр иде. Әмма бу да бронь түгел. Аннары мондый катгый критерийлар бар. Айтишник эшләгән предприятиенең махсус реестрда аккредитация үтүе, ә хезмәткәрнең профильле белемле, хезмәт килешүе белән эшләве шарт. Айтишникларга бронь бирелми, бары тик Оборона министрлыгының карары белән алынмыйча тора.

Мобилизациядән качучыларны төрмә көтә

Мобилизациядән баш тартучыларны җинаять җаваплылыгына тарту турында закон проекты көзгә әзерләнә. Бу хакта «Парламент газетасы»ның интервьюсында Думаның Оборона буенча комитеты җитәкчесе Андрей Картаполов әйткән.

Депутат бу законның кирәклеген «вазгыятьне көйләү» белән аңлаткан, чөнки җинаять кодексында армиягә чакырылудан качып йөргән өчен иректән мәхрүм итү каралган, ә менә мобилизация өчен – юк булып чыга. Картаполов, бу законны кабул итүне тартып-сузып йөрүнең «бернинди кирәклеге» юк, дигән.

Картаполов җинаять кодексының 328нче маддәсенә 3нче пункт өстәргә тәкъдим итә. Закон кабул ителгән очракта, мобилизациядән качып йөрүчеләргә ярты миллион сум штраф салырга яки инде 5 елга утыртып куярга мөмкиннәр. Хөкүмәт бу инициативаны хуплаган.

Мобилизациядән качып йөрүчеләрне җинаять җаваплылыгына тарту турында депутатлар былтыргы өлешчә мобилизация чорында ук сөйләнгән иде, әмма чакыру тәмамлангач, депутатлар бу идеяне яңадан күтәреп чыкмады. Инициатива актуаль түгел, дип аңлаттылар. Быел июль азагында бу закон проекты турында яңа төрдәге повесткалар кабул ителгәч, кабат сөйли башладылар.

Былтыр мобилизацияләнгәннәрне срочникларга җибәрә торган повесткалар белән чакырганнар иде. Ә повестканың яңа формасында «мобилизация» дигән сүз язылган һәм бу чакыруның президентның мобилизация турындагы кануны нигезендә икәне әйтелгән. «Моның сроклары вазгыятьтән чыгып хәл ителәчәк», – дигән иде Путин.

Махачкалада корбаннар саны 35кә җитте

14 август төнендә Дагыстан башкаласы Махачкалада «Глобус» сәүдә үзәге янындагы автосервис бинасында шартлау булды. Шартлаудан соң ут ягулык салу станциясенә, ә аннары берничә автомобильгә күчкән. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, 105 кеше зыян күргән, шуларның 35е һәлак булган.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 70тән артык хезмәткәре Махачкалада янгын урынында корылмаларны тикшерүне һәм зыян күрүчеләрне эзләүне дәвам итә.

15 август Дагыстанда матәм көне дип игълан ителде. Республиканың бөтен территориясендә дәүләт әләмнәре төшерелде, мәдәният учреждениеләре һәм телеканаллар күңел ачу чаралары һәм тапшырулар күрсәтмәде.

Дагыстан Республикасы Хөкүмәте рәисе Абдулмөслим Абдулмөслимов медицина хезмәткәрләренә, коткаручыларга һәм үз теләкләре белән булышучыларга ярдәмнәре өчен рәхмәт белдерде. Һәлак булганнарның гаиләләренә һәм барлык зыян күрүчеләргә Резерв фондыннан матди ярдәм бүлеп биреләчәк.

Россия Президенты Владимир Путин, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Дагыстан башлыгы Сергей Меликовка кайгы уртаклашу телеграммасы җибәрде.

«Новости Tatar today» телеграмм каналыннан алынды.

ЯҢА НИЗАМ ҺӘМ ГОЛӘМӘБЕЗ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Дин өчен тешләрен сындырып, битләрен канатып тартышкан адәм сезнең кемегездер? Дөя эчендәге тизәк суларын эчеп сәфәрләрдә булган адәмнәр сезнең сәхабә кирам дип атаган адәмнәр түгелмедер? Корсагына таш бәйләп ач булганы хәлдә дин юлында иҗтиһад итеп йөргән адәм сезнең пәйгамбәрегез, өммәте дәгъвасында булган расул ходаңыз түгелмедер?

Кайда сезнең иман вә Коръән гайрәтеңез?

Кайда сезнең иманнан тугмыш хәмиятеңез? Кайда сезнең милләт кайгыңыз? Кайда сезнең Коръәнеңез? Кайда аның белән гамәлеңез? Кайда аның аятләрен хакы илә аңлау вә куллануыңыз? Кайда Коръәнгә үзе әйткәнчә иманыңыз вә аның белән хәрәкәтеңез? Оят! Газиз вә мөбарәк исем алган, пәйгамбәрләр варислары исемен күтәргән, Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәлам кеби хак нәби вә хак гайрәтле расулнең өммәте саналган, гыйлем вә мәгърифәттән гайрәт вә иҗтиһаттан гыйбарәт булган, Коръән әһеле дәгъвасында булган сезнең кеби картларга, безнең кеби яшьләргә! Оят – сезгә, соңра оят безгә!

Дин исламга хилаф дип, кирәкмәгән җирләрдә ач бозау кадәр кычкырдыгыңыз хәлдә, динемезгә хакыйкый хилаф булган бу кебек урыннарда, дин вә милләтебезне бетерер өчен беренче сәбәп булган бу кеби мәсьәләләрдә ни хәйлә таптыгыз да, постыгыз? Нигә протест бирмисез? Нигә бирергә юл күрсәтмисез? Аллаһ рәхмәт итсен Оренбург имамнары вә мөселманнарына, алар протест бирделәр, тавышларын җир кырыйларына кадәр ишеттерделәр. Гайрәт диния вә хәмият миллиянең ни икәнен фигыльләре илә күстәрделәр. Күңелләрендә иман нуры вә Коръән игътикады барлыгын мәйданга куеп иманлы вә хак мөселманнар тарафыннан чын күңелдән ихлас калеб илә булган рәхмәт вә догалары алдылар. Яшәсен Оренбург имамнары вә мөселманнары!

Шул мәсьәләләрне белеп тә, соңра мәңгелек хараплык икәнен сизә торып та, башка милләтләрнең бирелмәгән хокуклары өчен матди вә мәгънәви куәтләр илә тырышуларын, тузан кадәр хокукларын югалтмас өчен үзләрен корбан иткәннәрен күрә торып та, Коръәнегездә иҗтиһад вә гайрәткә өндәгән, түгел аятьләр генә, камил сурәләр булганын белә торып та, пәйгамбәрегезнең дин юлында кан коеп тырышканын ишетеп тә, Коръәнегез гыйлем, хәят, тәрәккый, сәгадәт, гайрәттән гыйбарәт була торып та сезләрнең бу кадәр гайрәтсез вә бу кадәр хәмиятсез вә бу кадәр каткан үлекезең мәгънәсе нидер?

Газиз бәрадәрләрем вә хөрмәтле карендәшләрем, хәййә галәл-фәләх! (әйдәгез уңышка!)

(«Вакыт». 1906 ел, №84).
(Низам – тәртип, канун)

- Медицина фәннәре докторы, табиб-диетолог Алексей Ковальков әйтүенчә, дөньяда иң зыянлы продукт – шикәр, аны бөтенләй кулланмау хәерлерәк, чөнки кеше организмы шулкадәр углеводка исәпләнмәгән.
- Аена бер плитка ачы шоколад ашау гомерне бер елга озайтырга сәләтле, баш авыртканда ике шакмагы кан басымын нормальләштерә ала. Әмма аны чамасыз күп куллану йөрәк-кан тамырлары авырулары китереп чыгарырга мөмкин.
- Дөньяда иң күп кулланыла торган ризык – дөге, аның 15 меңнән артык сорты билгеле. Япон галимнәре раславынча, Азиядә бик популяр булган көрән дөге Альцгеймер авыруыннан саклый, чөнки анда баш мие эшчәнлеген яхшырта торган матдәләр ак дөгегә караганда уннарча тапкыр артыграк.
- Бер килограмм чипсы бәясе шулкадәр үк бәрәңге бәясеннән 200 тапкырга кыйммәтрәк.
- Иртән алма ашау каһвә эчүгә карата тизрәк йокыдан айныта.

Гомерләр үтә икән

«Гомерләр үтә икән ул» дигән җыр бар. Ялгышмасам, Роберт Миңнуллин сүзләре кебек. Ә гомер дигәнең, чыннан да, аккан су кебек, сизелмичә дә үтә. Гомер үткән саен хатирәләр ешрак кузгала, үткәннәр искә төшә, күңел еракта калган елларга күбрәк кайта башлый.

Танышларым арасында да соңгы елларда андый кешеләр ешрак калкып чыга. Шундыйларның берсе – якташым, күренекле галим, өч академия академигы, гомерен балаларга гомумбелем һәм профессиональ белем бирү системасында эшләүгә, сәүдә хезмәткәрләре тәрбияләүгә багышлаган, 1971-1978 елларда – ТАССР мәгариф министры урынбасары, соңрак – Мәскәү потребительләр кооперациясе университетының Казан филиалы ректоры булган, соңгы елларда Казандагы Социаль һәм гуманитар белем бирү институтының менеджмент кафедрасы мөдире булып эшләгән, күпсанлы фәнни хезмәтләр, дәреслекләр һәм методик әсбаплар авторы Роберт Вафа улы Шакиров.

Р.Шакиров 1938 елның 29 августында Олы Битаман авылында укытучылар гаиләсендә туа. Улына бер яше тулар-тулмаста аның әтисе Вафа Шакировны солдат хезмәтенә алалар. Әнисе Фатыйма апаны исә Чуаш Иле мәктәбенә укытырга күчерәләр. Әмма Чуаш Илендә бер ел эшләүгә, икенче елны Юртышка, аннан Кара Күлгә күчергә туры килә. Роберт шунда беренче сыйныфка укырга керә. 1945–1946 уку елын тәмамлауга тагын яңа авыл – Ювас. Монда бер ел укыткач, Фатыйма апаны улы Робертның әтисе туган Юртыш авылы мәктәбенә күчерәләр. Әнә шулай, алар ел саен авылдан-авылга, мәктәптән-мәктәпкә күчеп, 1947 елга хәтле сәяхәт итеп йөрергә мәҗбүр була. Әтиләре Вафа абый шул 1939 елда чыгып киткән җиреннән әйләнеп кайтмый. Роберт башлангыч мәктәпне Юртышта тәмамлый, аннары Мәмдәл мәктәбендә урта белемгә ия була. Балачак, үсмер еллары шул ике авыл арасындагы сукмакны таптап үтә. Мәктәптә яхшы билгеләренә генә уку белән бергә ул физик яктан да чыныгып, нык егет булып үсә, көрәш белән мавыга. Буш вакытларында авыл малайлары арасында шахматта аннан да оста уйнаучы булмый. Ул елларда авыл малайларын шахмат буенча халыкара ярышларда дан алган күренекле татар егете Рәшит Нәҗметдинов үрнәге кызыктыра. Робертка киләчәктә Рәшит абыйсы белән дә очрашырга насыйп була, аның белән такта артына утырып, шахмат фигураларын чәкәләштерү бәхетенә дә ирешә. Иң мәртәбәлесе – атаклы шахматчы, күп чемпионнарның остазы булган, Россия һәм Татарстан күләмендә үткәрелгән ярышларда чемпион калган Рәшит Нәҗметдинов белән уены уртак нәтиҗәгә тәгәлләүгә дә ирешә! Бу аның өчен үзе чемпион калу белән бер була. Рәшит абыйсының котлап кулын кысуы, кичә генә булган шикелле, һаман да аның күз алдында тора. Бу вакыйга Робертның мәктәп елларында түгел, бераз соңрак, инде Казанда университетта укый башлагач була.

Егет мәктәптә укыганда очучы булырга, самолётта зәңгәр күкне иңләргә хыяллана. Мәктәпне тәмамлагач та шушы хыялын тормышка ашыру өчен Казанга ашкына, очучылар әзерли торган Аэроклуб каршында дәресләргә йөри башлый. Очучы булу өчен физик яктан нык, таза булырга кирәк. Егет буш вакытын физик күнегүләргә багышлый, ирекле көрәш белән шөгыльләнә, чаңгыда йөгерә, парашютта сикерә, шахматта уйный. Төп максаты – спортның үзе шөгыльләнгән барлык төрләрендә дә яхшы нәтиҗәләргә ирешү. Шахмат буенча ул - беренче разрядлы уенчы. Ирекле көрәш буенча спорт мастерлыгына кандидат нормасын үти. Парашютта сикерү дә аның өчен көндәлек бер шөгыльгә әйләнә. Ә иң мөһиме – самолёт штурвалы артына утыру, корыч кошны иярләү! Аэроклубта ул ЯК-18 очкычында очарга өйрәнә. Профессионал очучы булу өчен Аэроклуб белеме генә аз була. Осталыгын тагын да камилләштерү өчен аны Уральск шәһәрендәге хәрби очучылар әзерли торган училищега җибәрәләр. Бер ел укып, ЯК-18-У самолётында очу күнекмәләрен үзләштергәч, Волградка, Советлар Союзындагы хәрби очучылар әзерли торган иң данлыклы А.Ф.Мясников исемендәге Кача Хәрби Авиация училищесына күчерәләр. Монда ул МИГ-15 маркалы реактив очкычта очуны үзләштерә. Ләкин яшьлек хыяллары тормышка ашмый кала. Шул елларда хакимияткә килгән Хрущев фәрманы белән армиядә кыскартулар башлана, хәрби училищелар ябыла. Роберт белем алган уку йорты да шундый язмышка дучар ителә, Волградтагы училищеда ике ел гына укырга өлгергән егетне, укуын алдан тәгәлләде, дип, диплом һәм хәрби чин биреп, отставкага чыгаралар. Ул туган якларга әйләнеп кайтырга мәҗбүр була.

Иксез-чиксез һава киңлекләрен иңләгән бөркетнең канатын кискән кебек була бу хәл. Балачактан очучы булырга хыялланган, аны тормышка ашыруга яшьлегенең дүрт елын биргән егет алдында яңадан һөнәр сайлау бурычы килеп баса. Кем булырга, кая барырга? Ул әти-әнисе юлыннан китәргә дигән карарга килә. Шул елда ук Казан университетының тарих факультетына укырга керә. Инде шактый дөнья күргәч, лаеш шулпасын чөмергәч, бөтен уңышларның да бары тик тырышлык белән генә килүен аңларга өлгергән егет университетта укуга, яңа фәнне үзгәштерүгә бөтен игътибарын юнәлтә. Төркемдәшләре арасында да тарих фәнен яраткан, аны зур кызыксыну белән өйрәнергә омтылган егетләр шактый була. Университетны тәмамлагач күренекле тарихчы галимнәр булып танылган Геннадий Атласов, Михаил Крашенинников, Рәфыйк Гарәфетдинов, Рифкать Шәрифуллин, Харис Сафиннар белән бер төркемдә «кимерә» алар тарих нигезләрен. Бу егетләр киләчәктә фән юлыннан китә.

Роберт исә үзен мәктәптә сынарга була, туган ягына кайтып, Биектау районындагы Алат урта мәктәбендә тарих укыта башлый. Мәктәп тормышын яраткан, дәресләрен мавыктыргыч алып бару белән генә чикләнми, дәресләрдән соң да укучыларның буш вакытын нәтиҗәле

итү өчен туган як тарихын өйрәнү буенча түгәрәк эшен җанландыра, укучыларның район күләмендә үткәрелә торган чараларда катнашуларын оештыра. Җиңүләргә дә ирешәләр. Алат мәктәбенең ул чактагы директоры, сугыш ветераны Петр Белотелов та аңа педагогика серләрен төшенергә ярдәм итә.

Актив яшь белгечне мәгариф бүлегендә дә, партиянең район оешмасында да күз уңына алалар. Мәктәптә бер ел да эшләргә өлгерми, 1965 елда Биектау районын яңадан оештырылганда аңа район комсомол оешмасын җитәкләү бурычын йөклиләр. Ләкин комсомол эшендә озак тоткарланырга туры килми. Аны Казан авиация институтына эшкә димлиләр. Авиатор булырга, корыч кошларны иярләргә хыялланган егет тәкъдимне теләп кабул итә. Аның алдында самолётлар конструкцияләүче белгечләрне әзерли торган уку йорты үз ишекләрен ача лабаса!

Егет бер үк вакытта Казан дәүләт университетында аспирантурага да урнаша, баш-аягы белән фән дөньясына чума. Бу вакытта инде ул егетлек чорын узган, гаилә корган, матур гына тормыш алып бара башлаган, тормыш иптәше Алсу белән кыз бала үстерүче үрнәк гаилә башлыгы, ата кеше. 1964 елда өйләнешә алар Алсу белән. Алсу да, Роберт кебек үк, Биектау районы кызы, Тимерче авылыннан, Мүлмә мәктәбен тәмамлаган. Башта училищеда укып, аш-су остасы һөнәрен үзләштергән. Аннары Казан университетында татар филологиясе бүлегендә югары белем алган. Гомере буе балалар бакчасында логопед булып эшләгән.

1971 елда аспирантураны тәмамлап, кандидатлык диссертациясен яклаган яшь галим Роберт Шакировны Татарстан мәгариф министры Мирза Мәхмүтов үзенең урынбасары итеп эшкә чакыра. Аның кул астында эшләү Робертка тормышта күп тәҗрибә бирә.

Министрлыкта Р.Шакиров укытучыларның хезмәтен оештыру буенча гаять зур хезмәтләр башкара, республика җитәкчелеге каршында да абруй казана. Үзенә тапшырылган вазифаларны җиренә җиткереп, зур җаваплылык белән башкарырга өйрәнә. Роберт Вафа улына, урынбасар буларак, мәктәпләрдә проблемалы укытуны оештыру мәсьәләләрен хәл итү бурычы йөкләнә. Ул мәктәп укучыларына дөнья таләпләренә җавап бирерлек белем бирүне оештыруны үзенең төп максаты итеп куя, шуның өчен бөтен белемен, энергиясен биреп эшли. 1976 елда Казанда укытучыларның бөтенсоюз Конференциясен уңышлы оештыру аның абруен тагын да күтәрә. 1978 елда Р.Шакиров бер төркем белгечләр арасында Әфганстан Демократик Республикасына эшкә җибәрелә. Өч ел буе, катлаулы шартларда, революцион үзгәрешләр барган Әфган илендә мәгариф министрлыгының киңәшчесе вазифаларын башкарырга туры килә. Аңа мәктәп дәреслекләрен укыту методикасын әзерләү, яңа шартларда укытучы кадрлар әзерләүне оештыру йөкләнә. Аның җитәкчелегендә фарсы телендә тарих буенча дүрт дәреслек әзерләнә. Аларның һәрберсе билгеле бер чорны эченә ала һәм 5-8 сыйныфларда укытуны күз алдында тота. Шулар белән бергә укытучыларга дәрес алып бару өчен методик кулланмалар төзелә. Ни гаҗәп, шуңа кадәр Әфганстанда тарих дәресләрен системалы рәвештә укыту мәктәп программасына бөтенләй кертелмәгән була. Балалар ни үз илләренең тарихын, ни дөнья тарихын белмичә үсә.

Әфганстанда эшли башлаганда халыкның совет белгечләренә мөнәсәбәте начар булмый, аларны хөрмәт итәләр. Ләкин озак та үтми Әфган хакимнәре арасында барган үзара көрәш нәтиҗәсендә хәлләр үзгәрә. 1979 елның сентябрендә президент Н.М.Тараки Кубадан кайтышлый СССРга туктала. Ул анда Әфганстанның революцион совет председателе булып торган Хафизулла Әминнең кан дошманы Бабрак Кармаль белән очрашкан, дигән сүз тарала. Әмин моның өчен Таракидан үч ала, аның урынын үзе били. Әмма Әмин Советлар Союзы өчен теләгән президент булмый, Америкада укып белем алган бу сәясәтче күбесенчә Америка киңәшләренә колак сала. Аны тәхеттән төшерү өчен СССР җитәкчелеге 1979 елның 25 декабрендә совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын Әфганстанга кертергә дигән карар чыгара. Ләкин бу совет иленең бик зур хатасы була. Сугыш озакка сузыла. Әфган җирендә 15 мең совет солдатының гомере өзелә. Татарстаннан ун мең егет Әфганстанда интернациональ бурычын үти. 261 егет сугыш хәрәкәтләре вакытында һәлак була, 220 егет алган яралардан сугыштан соң дөнья куя. 570 солдат яралана, 260 ы гарип булып кала...

Роберт абый Әфганстанда эшләгән елларын һәм сугыш вакыйгаларын тетрәнеп искә ала. «Бер генә нәрсә тынычландыра – Әфган балаларын укыту өчен әзерләгән дәреслек һәм методик кулланмалар. Әфган балалары бүген дә шул китаплар буенча белем аладыр дип беләм».

Роберт Вафа улына Әфганстан укытучыларының беренче корылтаен үткәрү, аны хәзерләү эшендә катнашырга туры килә. Күрше илләрдән һәм Советлар Союзыннан да вәкилләр чакырыла. Ул чактагы СССР мәгариф министры Михаил Прокофьев Р.Шакировның корылтайны оештырудагы эшчәнлегенә югары бия бирә. СССРның Әфганстандагы тулы вәкаләтле илчесе Фикрәт Табеев та аңа рәхмәт сүзләрен белдерә.

(Ахыры киләсе санда).

Рафис КОРБАН.

Сталинның «Махсус папкасы»

Совет хөкүмәте җитәкчеләре элек-электән үзләре кабул иткән мөһим документларны матбугатта бастырмаган, аларны халыктан яшергән. Дөрес, вакытлы хөкүмәтне бәреп төшергәннән соң В.И.Ленин һәм башка совет лидерлары кул куйган декретларда халыктан яшереп сәясәттән ачык сәясәткә күчү дәвере җиткәнлеге игълан ителә. Патшаның һәм вакытлы хөкүмәтнең нигезендә тышкы сәясәткә кагылышлы яшерен документларын басып чыгару бу юнәлештә беренче адым була. Әмма тиздән, 1917 елның февраленнән соң күпчелек эш-гамәлләрен сергә әйләндерә башлыйлар. Моны гражданнар сугышы шартларында хәрби хәлнең катлаулы булуына сылтыйлар.

Әмма сугыш тәмамланганнан соң да һәммәсен сер итеп саклау дәвам итә. Асылда райкомнарныкыннан башлап партия карарлары, әгәр аларны бастырып чыгару турында искәртелмәсә, ябык саналган, ә алардагы мәгълүматларны чәчеп йөргән өчен җәза бирелгән.

Профессор Булат Солтанбәков билгеләп үткәнчә, серлелек дәрәҗәсе җәһәтеннән документлар ике төркемгә бүленгән, ләкин иң яшереннәрен «махсус папка» дип аталганнары тәшкил иткән. Алар хәтта күпчелек партия һәм дәүләт хезмәткәрләре өчен дә ябык булган. Архивларда эшләүче тикшерүчеләр белә: күпчелек яшертен һәм аеруча яшертен карарлар белешмәләрдә бәян ителсә дә, аларда һәрчак «махсус папка» дигән серле тамгалар, ә үзләрендә текстлар юк. Бу – аларның эчтәлеген белергә тиешле затлар даирәсе бик тар булган дигән сүз.

Хәбәрдарлык төшенчәсе ярым-йорты һәм каршылыклы булган безнең дәвер факт һәм вакыйгаларның, шул җөмләдән төрле дәрәҗәдәге кайбер «махсус папка»лар эчтәлегенең серен ачты. Россия архивының иң кадерле партия мирасыннан – Сталин һәм Молотовның 1944–1953 еллардагы «махсус папка»ларыннан серлелек пәрдәсен өлешчә ачуы бу юнәлештә мәгълүм бер адым булды. Кызганыч ки, партия серләрен ачу буенча Россия Президенты фәрманы белән төзелгән комиссия, илнең баш архивчысы В.П.Козловның «Известия» газетасында басылган чыгышына караганда, берничә ел бөтенләй эшләмәгән. Билгеле, моның сәбәбе финанс проблемаларына гына бәйле түгел.

Ике юлбашчының «махсус папка»ларындагы документлар нигезендә махсус хезмәткәрләрнең документлары, папкаларда партия-совет органнарыныкы әллә ни күп түгел икән. Әйтергә кирәк, чекист органнары мәгълүматлары нигезендә илнең югары җитәкчеләре урыннардагы хәл-халәтнең торышы, фән-техниканың иң әһәмиятле тармакларындагы фактлар турында шактый тулы һәм объектив информация алган. Бу – 20 еллар башыннан чекистларның вазифасына кертелгән. Башка оешмалардан аермалы буларак чекистлар беренче чиратта тискәре күренешләр һәм гадәттән тыш хәлләр турында хәбәр итми торырга тиеш булган. Еш кына бу урыннардагы җитәкчеләргә белдермичә эшләнгән. Бер-берсеннән бәйсез ике яклы информация алып торуның мондый үзенчәлекле системасы һәм үзәктәге һәм төбәкләрдәге «йомшак урыннар»ны белеп торырга ярдәм иткән.

Россия архивы тарафыннан игълан ителгән документлар тасвирламасы күрсәткәнчә, урыннарда иң җитди җинаятьләр, борчулы сәяси күренешләр, фән-техника өлкәсендә иң мөһим ачышлар турында Сталинны кызыксындырган информация килеп торган. «Махсус папка» аша юлбашчыга җиткерелергә тиешле вакыйгалар һәм хәлләр исемлеге төбәкләрдәге, тармак-

лардагы чын хәл турында фикер йөртергә мөмкинлек биргән.

1944 елдан башлап 1948 елга кадәр бөтен илдән Сталинга килгән йөзләрчә хәбәрләр арасында Казаннан 17 хәбәр булган. Күбесе республиканың район һәм шәһәрләрдәге вакыйгаларга кагылышлы. 1948 елдан соң матбугат каналлары аша Татарстаннан «махсус папка»га материаллар кермәгән. Молотовка җиткерелгән мәгълүматлар аз санлы һәм алар нигездә хуҗалык мәсьәләләренә багышланган булган.

Бу елларда Татарстанның яшертен дип исәпләнгән вакыйгаларының кайсылары Сталинга мәгълүм булган соң? 1944 елның 25 маенда Татарстан НКВДсы аның игътибарына республикада кешеләрнең кан чире (септик ангина) белән күпләп авыруы турында доклад җиткерә. Сүз ач кешеләрнең кыш чыккан черек бәрәңге һәм ашлык куллануы, моның массакүләм төстә иң авыр формалардагы кан чиренә китерүе, аларның еш кына үлем белән тәгәлләнүе турында бара. Авырудан бигрәк тә балалар зур зыян күргән.

Казанның Ирек мәйданында бандитларның, әллә инде эре алыпсатарларның асып үтерергә җыенулары турында имеш-мимешләр тарала. Мәйданга дар агачы кору өчен бүрәнәләр китерелгән, имеш. Моны үз күзләре белән күргән кешеләр дә бар икән. Мондый юл белән җәза бирүнең яшертенлек традициясе бозылган, ул җәмгатьчелек өчен бер тамашага әйләнгән булса кирәк. Бу хактагы мәгълүматлар СССР НКВДсының 1944 ел, 12 июньдәге язмасында бәян ителгән. Ул «Балалар үтерүче җинаятьчеләргә суд һәм җәза турында таралган имеш-мимешләргә бәйле рәвештә Казан һәм Куйбышев шәһәрләрендә кешеләрнең рөхсәтсез җыеннары хакында» дип атала. Сталинның секретаре Поскребышев телефоннан шалтыраткач, вакыйга Казан шәһәр комитеты бюросында тикшерелгән һәм аның беренче секретаре З.Муратов әлеге хәлгә юл куйган өчен шәһәр башкарма комитеты җитәкчеләренә җәза бирүне таләп иткән. Ләкин бу «гаеп»не әлләни күпертеп тормаганнар. ТАССР НКВДсы башлыклары агентура эшен начар куйганнары өчен җитди кисәтү алган.

СССР НКВДсы Оборона дәүләт комитеты инициативасы белән Сталин кабул иткән «СССР НКВДсының 4 нче махсус берлегенең аеруча тырышлык күрсәткән тоткын белгечләрне азат итеп, суд хөкемен юкка чыгару һәм аннары авиация промышленностена җибәрү турында»гы карарында ирекккә чыгарылырга тиешле кешеләрнең исемлеген ачыклау бурычы куелуын һәм карарның үтәлүен юлбашчыга хәбәр итә. Казан махсус авиация төрмәсендә тотылган Мясишев, Королев, Глушко, Незваль, Изаксон һәм реактив техниканың беренче үрнәкләрен, ПЕ–8 һәм ПЕ–2 самолетларын һ.б. авиация техникасын яңарту өстендә эшләгән бүтән күренекле конструкторлар азат ителә.

ТАССР НКВДсының «Татарстан АССРда авыр азык-төлек хәле һәм ачлык турында»гы махсус хәбәрендә ач үлем һәм демография буенча коточкыч фактлар һәм саннар (бигрәк тә авыл җирләрендә) китерелә. Эчке эшләр министры Горбулинның җибәргән телеграммаларында ике гадәттән тыш хәл турында белдерелә. Берсе – «387 нче завод моторчылары Фомин һәм Кузьминның һәлакәт белән тәгәлләнгән рөхсәтсез очышлары турында», икенчесе – Казан шәһәрендә балигъ булмаганнарны төркем белән көчләү очраклары».

Казаннан иң күп хәбәрләр «махсус папка»ны 1945 елда тулыландыра. Аларның байтагы республикадагы кискен сәяси проблемаларга кагыла һәм сугыш вакытындагы кырыс, ә кайчан фаҗигале чынбарлыкны ачып бирә.

Хакимият органнары көчәя барган җинаятьчелек белән көрәшүдә зур тырышлык куйган. Республика НКВДсы җәмгатьчелектә зур яңгыраш тапкан өч җинаять турында Сталинга хәбәр итә. Казанда киң колач белән йөз сумлык ялган акча ясаучы һәм сатучы Казаковлар гаиләсе кулга алына. Танылган галим Блюмштейнны үтә зур тәвәккәллек күрсәтә талыйлар. Өч адреска: Сталинга, Молотовка һәм Маленковка җинаятьчеләрнең республика территориясендә каберлекләрне ачулары турында мәгълүматлар җибәрелә.

Татарстаннан 1946 елда кергән беренче махсус хәбәр шулай ук сугыш вакыйгаларына бәйле. Хәбәр «Татарстан АССР эчке эшләр министрлыгының татарлардан, башкортлардан һәм чувашлардан оешкан һәм исеме «Большевизмга каршы союз» дип үзгәртелгән «Идел–Урал» исемле Советка каршы милләтче оешмада катнашкан 18 кешенең кулга алынуы турында» дигән озын исем белән атала. Анда хәрби әсирләрне иләктән үткәрү һәм хыянәтчеләрне эзләү буенча зур эш алып барылуы бәян ителә.

Сугыштан соң юлбашчы, гомумән, милли проблемаларга аеруча зур игътибар биргән. Депортацияләнгән халыкларның яңа урыннардагы тәртибе, Синцзяньда уйгурларның үзәк хакимиятләргә каршы чыгышларын оештыру, Ирандагы баш күтәрүче көрдләрдән һәм бу илнең төньяк төбәгендә әзербайҗаннардан кадрлар әзерләү, Украинада һәм Балтыйк буенда милләтчелек белән көрәш турында аңа даими рәвештә хәбәр җибәреп торганнар. Украинаның 1933 елда ук кулга алынган элекке зур дәүләт эшлеклесе А.Шумскийның, 1937 елда могҗиза белән исән калып, лагерьда ун елдан артык гомерен үткәргәннән соң, дәвалап булмый торган рәхимсез авыруы сәбәпле азат ителүе һәм Саратовка сөргенгә озатылуын җиткергәннәр. Әмма ул сәламәтләнгән һәм туган иленә кайтаруларын таләп итәргә керешкән. Бу таләп үтәлмәгән очракта үз-үзенә кул салырга җыенуын белдергән.

1946 елның ноябрендә Берия Сталинга доклад тапшыра. Көнчыгыш районнарда нефть чыгару эшләрен көчәйтү өчен 175 мең тоткын, шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителеп, 5–10 ел дәвамында эштән китмәү шарты белән мәҗбүри төстә нефть промыселларына һәм күмер шахталарына җибәрелә. Тиздән ТАССРның көньяк-көнчыгышында беренче «махсус» нефтьчеләр һәм төзүчеләр төркемнәре пәйда була.

1947 елның беренче яртысында Татарстан чекистлары Сталинның «махсус папка»сына үзләре бик мөһим дип санаган ике хәбәр юллый. 31 гыйнвар хәбәрендә күрсәтелгәнчә, «Идел–Урал» төркемендә катнашучыларны ачыклау буенча уздырылган операция барышында яңа кулга алулар үткәрелгән, йөзләрчә элекке хәрби әсирләр «эшкәртүгә» дучар ителгән.

Әмма 22 нче заводның сынау очышлары башлыгы Л.И.Баклуновның үз-үзен үтерүе Союз күләмендә иң зур шау-шу тудырган вакыйга була. Бу фаҗигале вакыйгада дәүләтнең яшертен гамәлләргә йогынты ясаучы факторлар да чагылыш таба. 1947 елның 19 апрелендә берьюлы дүрт адреска – Сталинга, Молотовка, Маленковка һәм совет сәяси олимпында кабынган яңа йолдыз, ВКП (б) ҮК секретаре, махсус хезмәтләр җитәкчесе Кузнецовка җибәрелгән хәбәрдә бәян ителгәнчә, Баклунов моңа хәтле Глушко һәм Королев уйлап тапкан реактив җайланмаларын сынаудa, ПЕ–8 җайланмасын яңартуда катнашкан һәм авиация промышленносте министры Шахуринда яхшы исәптә торган. Ул авиация тарихына сынаучы очучы А.Г.Васильянко белән бергә ПЕ-2 самолетында Королевның реактив җайланмасын тоташтырып, беренче очыш ясаган.

Сталинга ТАССРдагы уголовный җинаятьләрдән Мамадыш районында кеше үтерү турында хәбәр итәләр. Анда бәян ителгәнчә, Түбән Ушма авылында хисапчы Г.Хәйруллин хезмәтенә карата җитди кисәтү ясап аны прокуратурага биргәч, колхоз рәисе С.Аппаковны, парторг К.Ишмурзинны һәм тагын ике кешене үтергән, 2 июльдә Мәскәүгә ТАССР да һәм башка өлкәләрдә берничә кешене үтергән банда төркемен юк итү турында хәбәр җибәрәләр. Казанда дәүләт милкен аеруча күп урлаган промкомбинат хезмәткәрләре төркемен фаш итү турындагы хәбәр Татарстаннан Сталинның «махсус папка»сына эләккән соңгы информация була.

1944–1947 елларда Молотовның «махсус папка»сында Казаннан өч хәбәр бар. Аларда 1944 елның азагында эпидемиягә күчү белән янаган авыруларның кискен күбәюе, укучы бала-чаганы көчләү очраклары һәм ирле-хатынлы Рахлиннарның бандитлар тарафыннан үтерелүе турында сүз бара. Казан шәһәр башкарма комитеты шикаятендә НКВД органнары трамвай юлларын төзәтү өчен тоткыннар бирүдән баш тарткан өчен гаепләнә.

НКВД һәм МВД материаллары тупланган «махсус папкалар» ул дәверләрдәге серләрнең аз өлешен генә ачып бирә. Сталин архивы да, ә аннары КПСС Үзәк комитетының гомуми бүлегенең махсус секторы архивы да хәзер Президент архивына күчкән. Тышкы разведка һәм шулай ук башка серле учреждениеләрнең махсус тамгалары бар. Әмма аларның якын арада гына ачылу ихтималы юк.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.



Архивымнан бер документ эзләгәндә, утыз-кырык елдан артык кояш нуры күрми боегып яткан бер кулъязмага тап булдым. Ул – Муса Җәлилгә багышланган «Очыгыз, тулпарларым!» дигән поэма булып чыкты. Аны 1966 елда, каһарман шагыйребезнең 60 еллыгына туры китереп, Азербайҗанның халык шагыйре, академик Бәхтияр Ваһабзадә язган, ә мин аны тәрҗемә иткәнмен. Бу поэманың татар телендә газета-журналларда басылуын хәтерләмим, ул минем китапларыма да керми калган.

Мин 1981 елда «Азәрбайҗан» дигән әдәби журналның 50 еллыгына Бакыга бардым. СССРның барлык союздаш республикаларыннан, алар белән янәшә Татарстаннан, Башкортстаннан әдәби журналларның баш редакторлары җыелган иде. Күрәсең, ул елларда ук безнең халыкларга кардәш азәрбайҗан җәмәгатьчелегенең аерым – туганнарча якын – мөнәсәбәте булган. Хәер, ул якынлык әле дә исән – Тукай бәйрәмнәренә Казанга Бакыдан саллы кунаклар килә, безнең язучылар да шундый чараларда катнаша. Мин үзем Бакыга барган саен данлыклы шәхесләр җирләнгән аллеяда булам һәм истәлекләрне яңартам. Ул данлыклы Аллеядә минем яраткан шагыйрьләрем Расул Рза, Сәмәд Вургун, дустым Мәмәд Араз, яхшы танышым Бәхтияр Ваһабзадәләр белән җаным сөйләшә. Истәлек тә бит үзенә күрә кыйммәтле архив, истәлекләр дә мирас!

«Очыгыз, тулпарларым»ның минем кулыма килеп керүе, бәлки, шул очрашуда булгандыр. Башка вакытта булуы да ихтимал, әйтик, 1989 елның 14 мартында да без Бакыда очрашканбыз, ул миңа «...старому другу по перу...» дип «Достоинство» дигән китабын бүләк иткән булган. Мөһиме шул, мин Бәхтияр ага Ваһабзадәнең бөек Муса Җәлилгә багышлаган поэмасын тәрҗемә иткәнмен, бу хезмәт сакланган, һәм ул ике халыкның да мирасы булып саналырга хаклы.

Ренат ХАРИС,
Татарстанның халык шагыйре.

Бәхтияр ВАҺАБЗАДӘ, Азәрбайҗанның халык шагыйре

Очыгыз, тулпарларым!

Әй, Физули, газапларны бер чикмичә
Мөмкинме соң чын шатлыклар тәмен тату –
Язгы тамчы ак энҗегә әверелә
Кабырчык караңгысында бикле ятып.
М.Физули

Алдымда «Моабит дәфтәре» –
зинданда боекмый, бөеккә
әйләнгән шагыйрьнең көннәре.
Һәр көне – бер шигырь, бер энҗе,
газапны җиңүче сөенеч...
Һәр шигырь – үлемсез бер адым...
Һәм соңгы адымы соңында
шагыйрьнең Үлемне үтергән
үлемсез йөрәген куралдым...

Калкансыз ачылган бу йөрәк
корычтан түземрәк –
ул хәтта газаптан көч алган,
тапталган килеш тә очалган,
газапның үзеннән үч алган...

Шагыйрьнең газабы минем дә
йөрәктә илһамга әйләнде,
Мусаның йөрәге утыннан
минем дә җаныма ут капты
һәм минем җаным да ут атты.
Ут мине каядыр әйдәде...
Җанымны әйдәде...
Каләмне әйдәде...

I

Тын өйләрдә,
рәхәтлектә йөзә-йөзә,
язабыз без дә...
Гәрчә йөрәк айлар буе янмый тибә...
Баш өстендә ныклы түбә...

Шигырьләребездә
бер төсле үк бертөслелек –
дулкынсыз аккан көннәребез кебек.

Ага тора борчылусыз көннәр.
Күңелләр дә,
әйтерсең лә тынсыз өйләр.
Өебезгә керми искән җилләр.
Өйдә җылы,
тәндә ялкын,
җанда салкын.

Йыш язабыз бары тик язар өчен –
үз күңелебезне үзебез назлар өчен.
«Әй кайгысыз чаклар, – дибез, –
кайгысыз чаклар!..»
Өстәл өстебезгә иеләбез.
Карасак –
җансыз кәгазьләр
җанны чәнчи,
әйтерсең лә пычаклар...

Ә без язабыз. Хәреф саен каләм абына,
кәгазьне тырный...
Шигырь картая тумас борын.

Көчәнә-көчәнә язган шигырь,
кычкырсак та аны биек таугa менеп,
ерак китмәс,
колакка җитмәс,
йөрәккә үтмәс.
Бернәрсәгә дә әверелмәс
утта кызмаган тимер.
Беркемне дә җылыта алмас
ялкынсыз йөрәктән чыккан шигырь.

Шигырь тусын өчен лампа яктысы түгел,
рух балкышы кирәк,
ялкынлы күңел!
Җан утын сүндерә алмас хәтта төрмә:
кабындымы –
суда да дөрләр.

Елаган – елата,
кабынган – кабыза,
Җирдән рөхсәт сорый мени туасы таң?
Орлыгы өлгергәч,
әнә, үлән ташны тишеп чыккан...
Һәм күңел дә,
тулса әгәр,
яңгыр болыты белән бәрабәр –
барыбер түгелә,
кыш дип тормый, җәй дип тормый.
Аңа мөмкин түгел башкача!
Күз яше яралгандай йөрәк утыннан,
иң гүзәл сүз энҗеләре
кара зинданнарда ярала кайчак.

II

Әсирлектә калды Җәлил, ә сынмады,
югалтмады горурлыгын, буйсынмады.
Кол итедә ireккә дан җырлаучылар –
Маркс, Һейне хатирәсе ничек чыдар?!.

Карар чыкты – аның гомере соңгы чиктә.
Үлемне үтерүчене үлем көтә.
Аны дошман таш зинданга кертеп япты,
ә ул вакытның үзен тотып туктатты.

Ул элек тә, канлы көннәргә чаклы да,
язды шигырь...Ул шигырьләрдә чаткылар
чатный иде. Ләкин фашист балтасына
башны куйгач, язганнары ялкын сыман
дөрләп китте...киләчәк таңга тоташты.
Җыры белән шагыйрь мәңгелеккә ашты.

Үз дуслары аткан туплар тавышында
үз җырларын ишетте ул көненә мең.
Һәрбер яңа җыры аша гасырларга
бирә барды мизгелләрнең гомерләрен.

Үлем килеп бугазына үрелгәч тә
төшенкелек баткагына батмады ул,
зинданнарда соңгы сәгатен көткәндә
өметсезлек ләхетенә ятмады ул.

– Яшәү – ирек, – дип әйтте ул Үлемгә дә, –
ә ирегем дошман табаны астында.
Шуның өчен аермалык күрмим һич тә
Үлем белән болай Яшәү арасында.

Вәгъдә итеп маташтылар аңа ирек...
– Юк, – диде ул, баш тартты ул
чын ир булып, –
Ил хакына шәһит китү – олы бәхет,
бүләк бәхет – үзең теләп алган коллык.

III

Зинданнарда туган шигырьләрдә
юк үкенү эзе, боегу,
төрмә сакчысының аяк тавышы
кушылса да җырга көй булып.

«Ни сөйләнә тоткын үз-үзенә?..»
Аңлый алмый төрмә сакчысы.
....
Хәзер Җирнең кайсыдыр төшендә
шул ук сакчы, бәлки, чак посып,
Җәлил шигырьләрен укыйдыр да,
искә төшерәдер үткәнен...
Тик белмидер утлы шигырьләрне
үз тоткыны иҗат иткәнне...

Җәлил качмасын дип, ишеккә ул
автоматтай торган эленеп,
тик белмәгән сакчы Уйлаучының
уен чикләү мөмкин түгелен.

Тик белмәгән: аның эше – зая.
Ул саклаган бары тавышны.
Төрмәләрдән чыгып, Җәлил үзе
мәңгелеге белән кавышты.

Җәлил үзен һич тә кайгыртмады,
кайгыртты ул җырын-канатын:
«Төрмә ишекләрен ватса җырым,
мин Җыр булып илгә кайтамын!..

Сез очыгыз, минем тулпарларым!
Сез җилләрне канат итегез,
утлы, канлы киртәләрне үтеп,
Ватаныма кайтып җитегез!

Сездә минем бөтен тойгыларым*,
сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онтылырмын,
яшәсәгез мин дә яшәрмен...»

Урадылар җырлар бар дөньяны,
барлык киртәләрне үттеләр,
йолдыз кәрваннары булып илгә
тезелешеп кайтып җиттеләр.

Йолдызлардан кабыналар таңнар –
шундый көчле алар чаткысы!
Көннәребез балкышында безнең
Җәлил йолдызлары яктысы.

1966 ел

* Җәлилнең «Җырларым» шигыреннән.

Дәрдемәнд даирәсендәге

(Дәвамы. Башы 30, 31, 32 нче саннарда).

Татар әдәбиятына багышланган хезмәтләрдә сирәгрәк искә алынган шәхесләрнең тагын берсе Ярулла Вәли буладыр. «Татар әдәбияты тарихы» тупламасының 2 нче томында (1985) аның исеме бер урында – Мөхәммәт ага Гайнуллинның «Драматургия»гә багышланган очеркында телгә алына. Ике гасыр аралыгында иҗат ителгән һәм китап буларак басылып чыккан проза әсәрләрен барлау, бәяләү бүлегендә исә ул автор бөтенләй дә искә алынмый.

Ә хәзер язучы Ярулла Вәли белән якыннанрак танышыйк. Элегрәк, «Татарстан хәбәрләре» газетасы нәшер ителгән

● Ярулла Вәлиев.

сында бу ике әсәр китап рәвешендә басылып чыккан яисә труппа эшли башлаган көннән үк диярлек даими рәвештә уйналган. Сәхнә тормышына, сәхнә әсәрләрен иҗат итүче авторларга багышланган гаять тә бай эчтәлекле «Октябрьгә

диновны атау очраклары да теркәлгән.) Әдәби әсәрләрен һәм тәрҗемәләрен ул үзешчән театрда уйнаган вакытта кабул иткән тәхәллүсе – Д.Таждаров исеме белән чыгарган. Кайбер хезмәтләрен «Хөсәенов» фамилиясе белән дә нәшер иткән. Г.Тукай Казанга килгән беренче елны аны җылы түшәк, «яхшы гына акча түләнгән» эш белән тәэмин итеп торган, үзенең «Китап» нәшриятын булдырган шәхес.

Икенче бер урында, «Сәйяр» труппасының 1910 елда Чиләбе шәһәрендәге гастроле турында язганда: «Оят, яки Күз яше» драмасы аеруча уңыш китерә», дигән җөмләне дә укыйбыз ул китаптан. Бу әсәр аерым китап буларак Оренбургта 1902 елда

күргән «Каравыл тавы» нәсере булуы да әйтелгән. Алда хәбәр ителгәнчә - «Үзенә кайту» әсәре башка жанрда язылган булырга тиеш.

Революциягә кадәрге татар театрлары тарихына багышланган китап битләренә тагын күз төшерик. 1908 елда басылып чыккан «Ачлык кушты»ны да шул чор театрлары үз иткән. Чөнки ул татар кыз балаларының фаҗигале язмышын тасвирлаучы әсәр. Татар авылларында, ачлык елларында зур гаиләне ачлык фаҗигасыннан йолып калу ниятеннән чыгып, яшь кызларны Урта Азиядә гомер итүче үзбәк, төрекмән һ.б. милләт байларына сату гадәте дә булган. Шул вакыйгаларга багышланган күләмле бер

уңышка ирешкән. Мәкәрҗә ярминкәсендә 1907 елда беренче мәртәбә уйналганнан соң, татар һәм рус газеталарында аңа карата хуплау мәкаләләре басылып чыга. «Татар тормышыннан алып язылган, труппаның моңарчы куелган әсәрләреннән барыннан да яхшысы,» дигән сүзләр дә була ул мәкаләләрдә.

1930 елларда, чит илдә яшәгәндә язган «Шималь төрекләренең әдәбиятына бер караш» хезмәтендә Г.Исхакый да язучылар исемлегендә Ярулла Вәлине үзеннән соң өченче урында теркәгән. «Г.Исхакыйдан соң берничә ел соңрак әдәбият мәйданына Г.Камал чыга», диелә дә, ике бит чамасы урында әдип Галиәсгар Камал иҗа-

кыска гомерле бер мәлдә, ул шәхес турында кечерәк бер мәкаләм басылган иде. «Татар энциклопедиясе»нең русча һәм татарча чыккан вариантларында да шул мәкаләнең сөземтәсе бирелде. Газетада әлеге мәкалә басылганнан соң миңа Ярулла Вәлиулла улын якыннан белгән берничә кеше белән аралашырга, аның турында кызыклы истәлекләр ишетергә туры килде. Әмирхан ага Еники дә, үз биографиясенә бәйле вакыйгаларны тасвир иткән соңгы әсәрләренең берсендә Ярулла Вәли исемен бик җылы итеп искә алган. Яшүсмер елларында, Дәүләкәндә яшәгәндә мавыгып, йотлыгып укыган әсәрләре арасында бу язучының шактый күләмле «Үзенә кайту» китабы булуын да бәян итә ул. Шушы юлларны укыгач, мин Әмирхан абый белән очрашып та сөйләшкән идем. «Язучы Ярулла Вәлине күреп тә белә идегезме әллә?» – дип тә сорадым. «Юк, якыннан таныш түгел идек. Аның хәл-әхвәлен болай гына, ишеткәләп кенә беләм», – дип җавап биргән иде әдип. Ул яратып укыган «Үзенә кайту» әсәренең жанры буенча повестьмы, романмы булырга тиешлеген, нәшер ителгән елы 1913 тирәсендәдер, дип әйткән бер дәфтәрчеккә теркәп тә куйганмын. Әмирхан аганың:«Ул китап минем өстәл өстендә озак ятты, кат-кат укыган идем мин аны. Күршедәге бер кызга күзем төшеп йөргән чаклар иде», – дип сөйләгән хәтердә.

Узган гасыр башында Ярулла Вәли драма әсәрләре авторы рәвешендә дә бик популяр шәхес була. Аның ике драма әсәре – «Оят, яки Күз яше» белән «Ачлык кушты»сы ул чорда эшләгән барлык театр труппалары тарафыннан да сәхнәләштерелгән, дияргә ярыйдыр. «Сәйяр» труппа-



● Оренбург каласындагы Кәрвансарай. 1844 елда төзелеп беткән.

кадәрге татар театры» китабында (1988 ел, 398 бит. Авторлары Б.Гыйззәт, Һ.Мәхмүтов, Ильтани Илялова) Ярулла Вәли һәм аның пьесалары исеме еш очрап тора. Менә 41нче биттәге берничә җөмләгә күз төшерик. Казанда 1907-1910 елларда «Яшьләр» труппасы актив эшли. «1907-1908 елларда гына да алар Г.Исхакыйның «Ике гашыйк» һәм «Алдым-бирдем», Г.Камалның «Бәхетсез егет», Я.Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Д.Таждаровның «Яшь хатын» әсәрләрен сәхнәләштереп, шактый уңыш һәм популярлык казаналар». Искәртеп үтик, соңгы әсәр авторының чын исем-фамилиясе Габдерахман Дәүләтшин, дип алда әйтеп киткән идек. Әхмәт бай Хөсәеновның тәрбиягә алган улы. Бер агасының байтак еллар дәвамында »Хөсәения« мәдрәсәсенең имам-хатибы (җитәкчесе) булганын да әйтик. (Югыйсә безнең шул уку йортына багышлы кайбер язмаларда мәдрәсә башлыгы рәвешендә Риза хәзрәт Фәхрет-

Гыйльман Кәримов басмаханәсендә чыккан. Бу язучының аңа чаклы һәм аннан соң басылган әсәрләре дә башлыча шушы басмаханәдә дөнья күргән: «Мәңгелек мәсҗед» 1901 дә, «Әфиюн» 1906 да, «Җанлы җеназа», «Ахырзаман баласы» һәм «Урман әүлиясы» 1907 елда һәм «Ачлык кушты» драмасы 1908 елда Кәримовлар басмаханәсендә чыккан. Бу тәртиптәге проза әсәрләренең хикәяме, повестьмы булуы әлегә ачыкланып бетмәгән. Г.Исхаки шул чорга багышланган бер хезмәтендә аның драма, хикәяләре белән рәттән «романы» булуын да искә ала. Әмма әсәрнең исемен атамый. «Әдипләребез» китабында алар хикәя буларак теркәлгән. «Оят, яки Күз яше» драмасының басылып чыгу датасы бу белешмәлектә 7 елга кичектерелгән, гәрчә ул әсәр 1907 ел урталарыннан башлап берничә труппа тарафыннан сәхнәләштереп өлгерсә дә. «Шура» журналына багышлы хезмәтләрдә бу авторның тагын 1909 елда дөнья

мәкаләсендә Мөхәммәд Мәһдиев тә андый гадәтнең хәзерге Татарстан төбәге авылларына хас булуын да язган иде. Я.Вәлинең «Ачлык кушты» драмасында шундый аянычлы бер вакыйга бәян ителә. Һәм әлбәттә инде, ул әсәрне шул чор театр труппалары күтәреп алган кебек була. Аны басылып чыккан елында ук сәхнәләштерә башлыйлар. Театр тормышына багышланган әлеге китаптан тагын берничә язма китерик. «Бу чорда драма әсәрләреннән Г.Исхакиның «Мөгаллим», Г.Камалның «Уйнаш», Я.Вәлинең «Ачлык кушты», Ф.Әмирханның «Яшьләр»е аерылып тора... «Ачлык кушты» матбугатта күренү белән, Г.Камал һәм Ф.Әмирхан аңа карата зур-зур мәкаләләр язып чыга. Г.Камал бу драманың кыскарак булуын тели, сәхнәгә куяр өчен катлаулы эшләнгәнлегенә игътибар итә», диелә китапның 123-126 битләрендә. «Әсәрне сәхнәләштергәндә әлеге фикерләр искә алына. «Сәйяр» аны Төркестаннан кайтышлый беренче тапкыр Оренбургта күрсәтә. Аннары драма Казанда, Панаев бакчасындагы Җәйге театрда уйнала» (127 б.). Бу китапның «Йомгаклау» өлешендәге нәтиҗә чыгару җөмләсендә дә Я.Вәлинең исеме Ф.Бурнаш, Г.Исхаки, Г.Камал, К.Тинчурин, С.Рәмиев, М.Фәйзи, Г.Колахмәтов исемнәре белән бер төркемдә китерелгән.

1926 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Татар театры тарихыннан» китабында да (авторлары режиссер В.Мортазин-Иманский һәм шагыйрь Т.Ченәкәй) Ярулла Вәли иҗаты югары бәяләнгән. «1907-1909 елларда «Сәйяр» труппасы күп кенә шәһәрләрдә гастрольләрдә булганда «Оят, яки Күз яше»н уйнаган. Шуның белән зур

ты тасвирлана. Аннары: «Шул ук чорда Ярулла Әлвәли исемле бер язучы берничә хикәя, роман һәм пьеса яза. «Ачлык кушты» исемле пьесасы шактый зур уңыш казана. Ләкин... әдәби сәләте җитәрлек булмавы аркасында, язучы тиз арада әдәбият мәйданынан сәүдә базарына күчеп урнаша», дип яза автор. Шул рәвешле Г.Исхакый каләмдәше Я.Вәлинең үз дошманы Фатих Кәрими кул астында эшләгәнлеген дә, унынчы еллар урталарында бай кызына өйләнеп, «байларга ялчы булуын» өнәмәвен дә, Оренбург төбәгендәге кайбер каләм әһелләре белән даими рәвештә диярлек килешмичә яшәгәнлеген дә сиздереп куя. «Таң йолдызы» нәшер ителгәндә, 1907 елда ук аның Ф.Кәримине «буржуаз язучы» дип битәрләгәнлеге мәгълүм ич. Ул елларда бу ике шәхеснең бер-берсен тәнкыйтьләп язган язмалары матбугатта даими рәвештә калка торган. Ә Ярулла Вәли - шул елларда Фатих Кәрими мәхдүмнең якыннары исемлегендә йөргән шәхес. Димәк, Г.Исхакыйның Я.Вәли иҗатына бәя биргән өлешен укыганда әлеге искәрмәне дә истә тоту хәерледер.

Г.Исхакыйның бу хезмәтендә Я.Вәлидән соң китерелгән язучылар исемлегенә дә күз төшереп үтик. Менә алар: әдипнең Казан укытучылар мәктәбе буенча шәриктәше, гасыр башы театрларында тәрҗемә әсәрләре даими рәвештә уйналган, шул чорның әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый вакыйгаларына багышлап китаплар чыгарган, мәкаләләре белән катнашкан Шакир Мөхәммәдъяров, күренекле шагыйрьләр Г.Тукай, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, М.Гафури, Н.Думави һ.б.

Алтмышынчы елларда Ярулла Вәлинең әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенә Исмә-

шәхесләр

гыйль Рәмиев тә игътибар иткән. Вафаты алдыннан (1969) нәшриятка тапшырган энциклопедик эчтәлекле, уртача күләмле хезмәтендә Я.Вәлигә, «милли-либерал «Вакыт» һәм «Яңа вакыт» газеталарына багышланган аерым мәкаләләре бар. Язучы һәм тәҗрибәле мөхәррир Рәис Даутов бик кыйммәтле булган ул белешмәлекне озак еллар үзендә саклады. 2001 елда гына «Әдәби сүзлек» исеме белән бастырып чыгарган иде.

Бөек әдип Г.Исхакыйның Я.Вәли иҗатына карата әйткән кайбер сүзләрендә, мөгаен, дөреслек тә бардыр. Чынлап та 1913 елдан соң Я.Вәли язудан туктаган, яңа әсәрләр иҗат итмәгән, ахрысы. Әллә кайнатасы Дәрдеменд үрнәгендә язганнарын китап рәвешендә китерергә ашыкмаганмы? Дәрдеменд тә бит әнә күпме югары сыйфатлы әсәрләр иҗат итеп тә, һәм кул астында иң заманча җиһазлы басмаханәсе була торып та, үз әсәрләрен китап рәвешенә китерергә тырышмаган. 1910 елда аның балаларга багышланган юка бер китапчыгы гына чыгып калган.

Я.Вәлинең шул замандагы газеталарда, яисә мәҗмугаларда чыккан әсәрләре турында да әлегә берәр төрле хәбәрнең күренгәне булмады. 1913 еллар тирәсендә аның «буржуй» Закир Рәмиевнең кече кызы Зәйнәпкә өйләнүе – Исхакый язганча, «байларга ялчы булуы» иҗат итәргә комачаулаганмы? Әллә соң җилкәсенә өелгән җаваплы эшләрнең күплеге аны иҗат эшеннән аергандырмы – әйтүе кыен. Бу вакытта бит ул «Вакыт» басмаханәсенең эше өчен җаваплылыкны үз өстенә алучыларның берсе була. Ә 1917 елгы түнтәрешләр чорында ул ярты ел чамасы «Вакыт» газетасының баш мөхәррире булып та торган. Шул вакыйгаларның чагылышына бер дәлил итеп, архив фондында сакланган бер телеграмма каралмасын да күрсәтергә була. Ф.Кәрими аны сентябрь аенда шул чорда Чиләбе шәһәре тирәләрендәге приискасында булган Закир әфәнде Рәмиевкә юллаган: «Басмаханә хезмәткәрләре баш күтәрә, эш хакын икеләтә арттыруны таләп итә, Ярулла әфәнде чара күрми. «Вакыт» газетасы вакытында чыкмаска мөмкин», дигән сүзләр бар ул телеграммада. Шуннан соң озакламыйча Ф.Кәрими үз кәнәфиен ташлап китә, башка сәүдәгәрләр белән килешеп, «Яңа вакыт» газетасын нәшер итүгә керешә. Исмәгыйль Рәмиевнең «Әдәби сүзлек» белешмәлегендәге «Яңа вакыт» мәкаләсенә күз төшереп алыйк. «Ф.Кәрими вә аның фикердәшләре, әүвәлге «Вакыт» идарәсе белән килешә алмыйча, аны ташлап чыкканнан соң, «Яңа вакыт» тирәсенә оеша. Наширләре (ягъни яңа хуҗалары) – Дәминев, Галәлетдинов тиҗарәтханәсе (сәүдә йорты). Газетаның фикри юнәлешен Ф.Кәрими болай билгели: газета вә аның мөхәррире бер партиягә дә мөнасиб социалист түгел, ул хөр фикерле тәрәккъыйчы... милләтчедер». Газета 1917 елның 1 ноябреннән 1918 нең 3 октябренәчә нәшер ителгән.

Шул ук китапның 61 нче битендә И.Рәми: «1917 елны «Вакыт» газетасы мөхәррирлеге Ярулла Вәли кулына күчте», дип яза. Ул үзгәрешнең кайсы айда булганлыгын хәбәр итми.

● Өфедәге мөфтият мәчетенең бистә ягыннан күренеше.

● Оренбургтагы Хөсәения мәчете.

ТҮНТӘРЕШ ЯКАДАН АЛГАЧ...

Әйе, 1917 елның сентябрь-октябрь айлары «Вакыт» газетасы хезмәткәрләре өчен бик аянычлы тәмамлана. Кемнәрнеңдер коткысы белән «Вакыт» басмаханәсендә кайберәүләр үз вазифаларын башкарудан баш тарта. Эш хакын икеләтә арттыруны таләп итәләр. Газетада эшләүчеләрдән дә аларга кушылучы булгандыр ахрысы. Фатих Кәриминең Чиләбе шәһәре тирәләрендәге үз приискасында булган Закир Рәмиевнең исеменә юлланган телеграммасында: «Чара күрелмәсә, газета чыкмаска мөмкин. Аның вакытында чыгуы бу көндә бик кирәк», дигән катгый таләпләр дә куела.

Закир Рәмиевнең әмере буенча «Вакыт» газетасы белән басмаханә хезмәткәрләренә эш хакы әле март башында гына шактый күтәрелгән була. Татарстан Милли архивында шуны раслаучы документ та сакланган. Анда, әйтик, газета хезмәткәрләренең элек алган хезмәт хакы да,1917 нең март башыннан түләнергә тиешлесе дә тулы саннар белән күрсәтелгән. Ул исемлектә «Вакыт» белән «Шура»да эшләүче 16 кеше исеме теркәлгән. Тулы исемлекне китермичә, танышрак исемнәргә тукталыйк. Кави (гадирәк эш башкаручылар арасыннан беренче килә) элек 85 сум алган, түләнәчәк 120 сум; Кәбир Бәкер - элек 120 сум алган, түләнәчәк 180 сум; Шәриф Камал – элек 120 сум булган, түләнәчәк 180 сум; Ярулла Вәлиев – элек 180 сум булган, түләнәчәк 250 сум; Ризаэддин хәзрәт – элек 225 сум булган, түләнәчәк 275 сум; Фатих Кәримов – элек 225 сум иде, түләнәчәк 325 сум. Калганнарга, өч айдан ким эшләмәгәннәргә, март башыннан хезмәт хакы 20 процентка арттырылачак, диелгән. (Татарстан архивы, 1370 фонд). Бу «калганнарга» диелгән сүз, мөгаен, «Вакыт» басмаханәсендә эшләүчеләргә карыйдыр.

Ил күләмендә барган үзгәрешләр нәтиҗәседер инде, басмаханә хезмәткәрләренең кайберләре кабат эш хакын күтәрүне таләп иткән. Һәм бу вакыйгага Фатих Кәриминең эштән китүе белән тәмамланган. «Идарә белән уртак фикергә киленмәде. «Вакыт»ның минем тарафтан чыгарылган саны 1917 елның сентябрендә булды. 1917 елның 20 октябрендә «Вакыт»тан хисапны өзеп чыктым», дип яза Ф.Кәрими шул ук фондта теркәлгән документта. Мөгаен бу вакытта инде Дәрдемәнднең дә Оренбургка кайткан чагы булгандыр. Ни сәбәпле алар үзара килешә алмаган соң? Бу сорауга әлегә җавап юк. Әмма Фатих әфәнденең илдәге болганышлар башланган чордан үзара мөнәсәбәтләргә карата фикере үзгәрә баруын чамалардай истәлекләр бар. Мәсәлән, сеңлесе Закирә Шәрәф истәлекләрендә китерелгән кайберәүләрнең хатларыннан аны чамаларга була.

● Баймак районының Юлык авылы зиратында Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең абыйсы Гомәр Мөхәммәтсадыйк истәлегенә куелган кабер ташы. З.Бәширов фотосы.

Ф.Кәриминең «Вакыт»тан китеп ун көн үтмәстән үзенә яңа ишләр табып, шулар ярдәмендә «Яңа вакыт» газетасын 1 ноябрьдә үк халыкка тарата башлавы – аның элекке тормышка карата фикер үзгәреше кичергәнлеген белдерә бугай. «Яңа вакыт»ның наширләре Дәминов белән Галәлетдиновлар, газета редакциясе аларның тиҗарәтханәләрендә (сәүдә йортында) урнаша, дип яза И.Рәмиев. Әмма ул газетаны бөтенләй башка кешеләр ярдәмендә, башка хуҗалар исеменнән чыгарылуын әлегәчә күпләребез танымады сыман. Күпчелек галимнәребез әле дә аны шул ук Рәмиевләр наширлегендә калып, фәкать исемен генә үзгәрткән газета сыманрак кабул итә шикелле. Яңа «газетаның фикри юнәлешен Ф.Кәрими үзе болай билгели, – дип белдерә дә И.Рәмиев, баш редактор мәкаләсеннән берничә җөмлә китерә. – «Яңа вакыт» вә аның мөхәррире большевик түгел. Хәтта берәр партиядә торучы социалист та түгел. Ул хөр фикерле тәрәккый бер милләтчедер. Шул хакта үз белгәнен, үзе хак дип игътикад иткәнен яза».

Шушы урында Тәүфыйкъ ага Сәгыйтов истәлекләреннән дә бер җөмлә китерәсе килә. «Фатих аганы 1905 елдан бирле якыннан беләм. Яшьлегемнән гаиләләрендә аралашып үстем... Фатих ага һичкайчан малга, шөһрәткә табынмады. Бай да, ярлы да булмады. Бөтен гомерен халыкка хезмәткә багышлаган иде», – ди ул 1970 елда язган истәлегендә.

(Дәвамы 23 нче биттә).

Лирон ХӘМИДУЛЛИН.

Мәдәни җомга
25 август
№33, 2023

КҮЛ БУЕНДА СЕРЛЕ ТӨН

Вахит ИМАМОВ

Еракта, Урал өстендәге Кызыл Өфе дигән калада таныштык без. Андый аулак җирдә Сабантуй уздыруның рәтен онытканнар, быел андагы татар белән башкортка сабак бирегез әле, дип җырчы, биюче, гармунчы һәм пешекчеләрдән хасил бер төркемне, ике автобуска утыртып, Чаллыдан Уралга юллаганнар иде. Әйдә, арада бер-ике каләм иясе дә булсын, дип соңгы сәгатьтә генә мин фәкыйрегезне һәм телевидение хәбәрчеләрен дә аларга өстәделәр.

Агыйдел, Дим, Әй, Йөрүзән буйларының, Урал тау итәкләренең матурлыгын сүзләр белән генә тасвирларлык түгел. Анда дала-яланнар да, тау калкулыклары да махсус бер шоба таягы белән үлчәгәндәй тезелешеп бара. Кояш баешы ягында биек тау сыртлары, ә аннары камыр, как, келәм җәеп киптерердәй тигез дала. Ул яланнар унбиш-егерме чакрым чамасы сузыла да, янә махсус өеп куйгандай биек, яңа тау сыртына килеп терәлә. Билгеле ки, тау сыртларын агач-куаклыклар каплаган, Йөрүзәнне узгач, кичке якта ерактагы калкулык һәм андагы урман куе-кара төскә күмелгәндәй була. Берсенә, әнә, Кара-Тау дигән исем дә кушканнар. Асылда, янына бара башласаң, ул тау өстен һәм итәкләрен дә ямь-яшел нарат, чыршы, карагайлар каплап китүе ачыклана инде.

Йөрүзән дә, Агыйдел дә буар елан төсен алып, бормаланып ага. Өфе каласыннан Чиләбе аермасына җиткәнче генә дә ул елгалар өстеннән өчәр-дүртәр тапкыр узып киттек бугай. Безнең Татарстанда юньле урманы да, биек таулар да юк, ә Уралда бөтенләй башка дөнья! Андагы иркенлеккә тәмам шаккатмалы. Басулары гына да безнең автобус тәгәрмәчләреннән алып зәп-зәңгәр офыкка кадәр сузыла. Бодай, арпа, арыш басулары җир өстендә бер-берсенә терәп җәйгән аерым келәм сыман. Сап-сары чәчәкле көнбатышлар кыры – аерым түбәтәй күк. Мондый кырда бер көтү уракчы түгел, хәтта көчле комбайннар да офык артына кереп югалырлар сыман.

Юлда очрап торган бистә-калаларны узуга, фәлән чакрымга сузылган чыршы-нарат агачлары эчендә курорт-санаторий, балалар яки гаилә лагерьлары корып куюлары тагын шаккатырды. Бик чемченеп эзләсәң, Әгерҗе, Кукмара, Шәмәрдән тирәсендә дә дала бәндәләре кызыгырдай наратлыклар бар бит, иллә мәгәр безнекеләр табигать кочагының имен-ямен белми, шуңадыр, ахрысы, бездә чит-ятны чакырып кунак иттерерлек тә, саулык кебек байлык өстәп җибәрерлек тә шифаханәләр юк...

Кызыл Өфе каласы да матур. Аңа нигез салган татар алпавыты Тәфтиләү урынны да сайлый белгән инде! Янда ярсу Өфе елгасы ургылыплар ага. Яртылаш кыя-ташлардан хасил биек яр өстендә кирмән торгызганнар. Елга өстеннән килеп, аны яуламалы түгел. Дала ягыннан якынаеп була, дигән фараз кылганда да меңәрләгән ирләрнең, берсен-берсе этә-төртә, биек кыя өстенә үрмәләвен күз алдына китерүе читен. Чөнки кирмәннең имән диварлары өстендә дә, иң биек калкулыкларда да дистәләгән чуен туплар торган. Алардан очкан ядрәләрдән тыш, фетнәче ташкын өстенә эре-эре ташлар, кайнар сумала белән ук-сөңгеләр дә, яңгыр төсле, тоташ түгелгән бит. Мәгәр барыбер дә Кызыл Өфе кирмәненә Акай фетнәчеләре дә, Пугачев батырлары да бәреп керә алган. Шушы кыялар өстендә каратунлы тәре ияләрен дә, патша әфисәрләре белән казакларны да дар агачына асып куйганнар йә дивар уемыннан елга өстенә болгап ыргытканнар. Күз алдына китереп карасаң да, беләкләргә каз тиресе чыга. Андый бәла-казаны күрүдән Ходай ярлыкасын!.. Әй, монысы бөтенләй дә башка кайгы лабаса! Мин бахырыгызны алда танышу көтә бит, серле, шәп танышу!..

Сабантуй булачак мәйдан читенә чатырлар кора башлагач та, яныбызга Кызыл Өфе каласындагы татарларның әйдәманнары шикеллерәк вәкилләр китеп җитте. Без, гадәттә, андыйларны «җыен чытлы», дип бәяләргә күнеккәнбез инде. Боларның да күбесе – теле-телгә йокмас «кушбугазлар», мондыйлар ишектән куып чыгарсаң, тәрәзәдән керә, ә бармак очыны тешенә эләктердеме – терсәгеңнән йота. Күпчелеге, әлбәттә, хатын-кызлар. Йә, әйтегез, ихатасында ике-өч сабые йә оныгы булса, эшчән хатын, бугаз ярып, теләсә нинди бәйрәм-мәҗлесләрдә итәк җилфердәтеп йөри аламыни?..

Артта, ышыктарак торган бер яшьрәге игътибарны алды.

– Кызыл Өфедәге бердәнбер татар теле укытучысы бу. Үзе Башкортстанда туып-үскән булса да, ана телебез өчен ут-ялкынга керә, – дип чәрелди алга чыгып баскан капчык шикелле үзе кыска буйлы, үзе шалкан сыман юан бер хатын. Аннары бик көттереп кенә, югалткан җеп очын тапкандай өстәп куйды. – Исеме дә, үзе дә бик сөйкемле, Гөлчирә ул безнең.

Чытлы әйдәманның бәясе артык түгел, асылда да, чибәр генә ханым иде безнең мөгаллимә. Үзе кеше алдына да чәчрәп чыкмый, әле теге хатын аңа таба кулын төртеп күрсәткәч тә оялу-читенсенүдән башын аска иде. Миссиябез бар бит, сораштырмыйча да булмый.

– Кайсы районнан? – дим.

– Ишембайдан, – ди. – Үтәк атлы авылдан. Габдрахман Гомәри дигән бик борынгы мәгърифәтче турында ишетеп беләсездер. Ул безнең авылда туган, муллалыкка указ алып кайткан, аннары ногай белән йөрт татарлары чакыруы буенча Әстерханга күчкән. Андагы Тияк бистәсендә имам йөгеп җилкәсенә алган. Беренче инкыйлаб барышында, ниһаять, татарлар да уянгач, үз мәчетенең бер бүлмәсендә «Идел» атлы газета чыгара башлаган. Дүрт ел буе шулай ике-өч йөкне япа-ялгыз тарткач, түзә алмагандыр, ярдәмгә янына бездән кул сузымында гына урнашкан Акман авылыннан чыккан Сәгыйть Рәмиевны дәшкән. Анысы – үз заманында бик танылган шагыйрь, Тукайның да бик якын дусты. Рәмиев Әстерханга күчеп бер ел чамасы эшләгәч, Тукайны кунакка чакырган. Безнең Тукаебыз шунда айдан артык кымыз белән дәваланган, тик ни кызганыч, файдасы гына бик үк тимәгән шул...

Ашыга-кабалана бераздан өстәп куйды.

– Әй лә, оныткамын. Үнҗиденче елда татарлар типкәнгә күрә асаба башкортларның юлбашчысына әверелгән Зәки Вәлиди дә бездән биш чакрымдагы Көзән авылында туып-үскән бит. Әтисе үзе мәдрәсә тотса да, Зәкине менә безнең Үтәк авылына китереп укыткан. Чөнки безнең мәдрәсәдә урыс телен үтә каты укытканнар, диләр...

Гөлчирә, билгеле, бу сүзләрне туктый-туктый, кайчакларда күзләрен мин фәкыйрегездән яшерә-яшерә тезде. Югыйсә, кызыкайдан тәмам күз алмаслык. Яше буенча әле утызга да җитеп бетмәгәндер. Куе-кара чәчле. Буйга миннән бер карышка түбән. Бик ябык та, нык таза да түгел. Төртеп торган тыгыз күкрәкләр, озын, төз аяклар, ике учка сыеп бетәрдәй неп-нечкә бил, алсу, мул иреннәр – һәммәсе теләсә кайсы ирнең күзен яндырырдай нигъмәт. Әммә төп магниты – керфек сирпегән саен көйдереп алырга сәләтле чем-кара күзләре. Алар керфекләрен кысса – усаллана, ә елмайса – мөлаемлык, хәтта наз да бөркеп яна сыман. Шайтан алгыры, әллә миңа гына шулай төбәлеп карыймы ул, әллә миндәй хыялыйга гына шулай тоеламы?..

Тагын дүрт-биш тозсыз җөмләләр алышканнан соң «чытлыкайлар» төркеме китеп барды. Гөлчирәне шактый үкенүле караш белән озатып калган идем, без чатыр һәм сәхнәләрне корып бетергәч, ул чибәркәй тагын ике-өч мәртәбә яныбыздан урап үтте әле. Берсендә җай чыгарып, мәктәбе турында сораштырдым.

– Безнең монда әллә кайчан, әле унҗиденче елга кадәр үк Хәбибулла бай белән Агафуров байлар төзеп биргән бик зур мәктәп булган. Ике катлы, дивар эчендә ясап калдырылган торбалар аша җылытыла торган бик тә олы мәктәп. Анда татар белән башкорт балалары укмашып укыганнар, «бу – безнең җир, сез – килмешәк», дип берәү дә талашмаган... Мәгәр кала байлыгына комиссарлар хуҗа булып алгач, үзләренең «чека»ларын татар байлары төзегән мәктәп эченә кертеп утыртканнар. Аннары мәктәптә район милициясе дә, орлыкчылык инспекциясе, нинди химия берләшмәсе дә эшләп алган. Хуҗалар тишек чабата урынына алышынып торган, мәгәр сыңары да бинага ремонт үткәрү турында уйлап карамаган. Менә, туксанынчы елларда гына аны безгә кайтардылар. Дүрт-биш бүлмәсе ярты-йорты исән, анда балаларны җыеп була әле. Ә калган бүлмәләр, аеруча беренче кат, бүген-иртәгә ремонт ясамыйсың икән, ишелә дә төшә...

Гаҗәпләнүдән баш чайкамыйча да булмый.

– Ә син андый бинага нинди генә балаларны туплый алдың соң? Аерым мәктәпме ул, әллә филиалмы?

– Шимбә-якшәмбе генә эшли торган мәктәп шул ул, абый. Әүвәл каладагы ун-унбишләп ата-ана үгетләгәнгә генә эшкә алынган идем, бер-ике ай эчендә балаларның саны йөзгә җитте. Башта кич ике-өч сәгать кенә укыта идем, хәзер шимбә белән якшәмбедә көннәр буе. Ялгызым гына җитешә алмагач, пенсиягә чыккан бер апаны да тарттым. Хәзер икәүләп тә һич өлгереп булмый.

– Аерым татар мәктәбе ачылуга өмет юкмы?

– Менә, шушы бер ай эчендә сезнең Татарстаннан Шәрипов килә, диләр. Безнең Чиләбе губернаторы Сумов белән килешү төзиячәк, шуннан соң яңа бина бирәчәкләр, шунда аерым мәктәп оешачак, дип ышандыралар. Барып чыкса ярар иде дә бит.

– Бирсен Ходай, – дип кабатлый-кабатлый аерылыштык...

Кичен кала читендәге бер кафеда ступай шулпасы шикеллерәк күмәк мәҗлес булды. Халык гаҗәеп күп, бик быгырдык иде. Уеннар-җырлар да суздылар, биюләр дә кабатланып торды. Гөлчирәкәй белән бер-ике мәртәбә генә танго биеп алдык. Кыяр-кыймас рәвештә сораштырдым:

– Ял көннәреңне гел мәктәптә үткәрәм, дисең, бүген дә, менә, кичең безнең белән уза. Ирең түзем икән.

– Мин япа-ялгызым бит. Хәтта, сигез яшьлек балам да авылда, әниләр янында. Көннәр буе мәктәптә яткан чагында ничек карый алыйм? Мәгълүм шигырьдәгечә, мәгърифәт дип йөри-йөри, гомер уза инде. Бала бик кызганыч, үтә сагындыра, кайчагында таң атканчы елыйм...

(Дәвамы киләсе санда.)

Берлинны яулаган татарлар

(Дәвамы. Башы 30-32нче саннарда).

1924 елда туган **Әһлиулла Шаһивәли улы Әхмәтгалиев** сугышка Киров районы комиссариаты аша 1942 елда озатыла. 146 нчы укчы дивизиянең 280 номерлы артеллерия полкында өлкән разведчик булып хезмәт итә, кече сержант дәрәҗәсенә ирешә. 1945 елның гыйнвар һәм февраль айларында, бер-бер артлы, ике тапкыр «Батырлык өчен» медальләре белән бүләкләнә. 1945 елның 22 апрелендә беренчеләр сафында Берлинны штурмлауга ташлана, дошманның 12 пулеметын, 6 зениткасын һәм 20 дән артык снайперны юк итүдә катнаша, хәтта кул сугышына керүдән дә куркып тормый. Ләкин 28 апрель көнне батырларча һәлак була. Аны I дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим итәләр.

Әһлиулла Әхмәтгалиевны сугышчан орденга тәкъдим итү кәгазе.


Все графы заполнить полностью
НАГРАДНОЙ ЛИСТ
289
1. Фамилия, имя и отчество: Ахметгалеев Аглигулла Шагивалеевич
2. Звание: мл. сержант 3. Должность, часть: Старший разведчик 280 артиллерийского полка 146 Стрелковой Островской Краснознаменной дивизии
Представляется к: ордену «Отечественной войны первой степени»
4. Год рождения: 1924 5. Национальность: татарин 6. Партийность: чл. ВЛКСМ с 43 г.
7. Участие в гражданской войне и в последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда): Отечественная война с 1942 года
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне: ранений и контузий не имеет
9. С какого времени в Красной Армии: с 1942 года
10. Каким РВК призван: Кировским РВК Тат. АССР
11. Чем ранее награжден (за какие отличия): Дважды медалью «За отвагу» (пр. 280 АП 01) н от 26.1.45 и 02) н от 23.2.45 года
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению или его семьи: [redacted]

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

В уличных боях за город Берлин проявил себя исключительно, как смелый, бесстрашный и неутомимый разведчик наблюдатель. С 22.4 по 26.4.45 года им выявлено 12 пулеметов, 6 зенитных установок и до 20 снайперов противника. 22.4.45 года тов. Ахметгалеев первым ворвался в город и в уличных боях взял в плен 3 солдат и уничтожил до 15 чел. пехоты противника. 28.4.45 года при выполнении боевого задания тов. Ахметгалеев пал смертью храбрых.
Достоин посмертного награждения.

Командир 280 артиллерийского полка
4.5.45 г гвардии подполковник (Петров)

Достоин правительственной награды ордена «Отечественная война первой степени» посмертно.

Командующий артиллерией 146 Стрелковой Островской Краснознаменной дивизии
6 мая 1945 г. подполковник /Петров/

Чистай районының Кызыл Ялан авылында 1920 елда туган **Шаһит Исрафил улы Ибраһимов** 1942 елның апрелендә Сарман районы комиссариаты тарафыннан чакырыла. 7 нче гвардия танк корпусының 5 нче мотоштурм һәм инженер-сапер батальонында отделение командиры урынбасары булып хезмәт итә, кече сержант дәрәҗәсен ала. Әле Берлинга якынайган чагында ук, Грюневальд урманын чистартканда дошманның 8 сугышчысын юк итә. Берлинны штурмлау башлангач, 26 апрельдә гитлерчыларның бер пулемет ноктасын, ике фаустпатрончыны сафтан чыгара, ләкин үзе дә авыр яралана. 27 апрельдә Берлин янындагы Рульсдорф бистәсендә вафат була. Грюневальд урманындагы батырлыклары өчен аны, вафатыннан соң, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләклиләр.

Шаһит Ибраһимовны бүләкләү кәгазе.


02595
ПРЕДСТАВЛЯЕТСЯ ВПЕРВЫЕ
182
НАГРАДНОЙ ЛИСТ
1. Фамилия, имя и отчество – ИБРАГИМОВ Шагит Исрафилович
2. Звание – Гвардии мл. сержант 3. Должность, часть – зам. командира отделения 5-го Гвардейского отд мото-штурмового инженерно-саперного орд Трудового Красного Знамени Севастопольского батальона
Представляется к награждению орденом «КРАСНАЯ ЗВЕЗДА»
4. Год рождения – 1920 г. 5. Национальность – татарин
6. Партийность – член ВЛКСМ
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне /где, когда/ – Ленингр. фр. с 15.1.43 г. по 10.10.44 г. и 1 Укр. фр. с 1.3.45 г. по 26.4.45 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне – ранен 26.4.45
9. С какого времени в Красной Армии – с 2.4.42 г.
10. Каким РВК призван – Сармановским РВК, Татарской АССР
11. Чем ранее награжден/за какие отличия/ – медалью «ЗА ОТВАГУ»
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи –

Краткое конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

Имея задачу прикрыть огнем ручного пулемета действие взвода по захвату занятых немцами домов в городском районе Груневальд, тов. ИБРАГИМОВ, несмотря на сильный огонь противника, отлично выполнил поставленную ему задачу, уничтожив при этом 8 гитлеровцев.
26.4.45 г. в берлинском городском лесу Груневальд тов. ИБРАГИМОВ отразил огнем ручного пулемета контратаку фаустпатронщиков, уничтожил при этом пулеметную точку немцев, прикрывавшую фаустпатронщиков, убил двух фаустпатронщиков и рассеял остальных. В этом бою тов. ИБРАГИМОВ был ранен и эвакуирован с поля боя.
За проявленное мужество и отвагу, достоин награждения орденом
«КРАСНАЯ ЗВЕЗДА»

КОМАНДИР 5-го ... ОТД МОТО-ШТУРМОВОГО ИНЖЕНЕРНО-САПЕРНОГО ... ТРУДОВОГО КРАСНОГО ЗНАМЕНИ СЕВАСТОПОЛЬСКОГО БАТАЛЬОНА
ГВАРДИИ МАЙОР
НАЧАЛЬНИК ШТАБА БАТАЛЬОНА
ГВАРДИИ ... /СЕРГИЕНКО/
«5» мая 1945 г.

Арча районының Иске Муй авылында 1916 елда туган **Мансур Асат улы Гарипов** сугышка Мәскәүнең Октябрь районы комиссариаты аша чакырыла. Ул 74 нче укчы дивизиянең 240 номерлы гвардия укчы полкында пулеметчылар взводы командиры булып хезмәт итә, кече лейтенант. 1945 елның язында Одер елгасын кичү һәм дошман оборонасын өзү барышында батырлыклар кыла. 1945 елның 15 апрелендә Берлин янындагы Фридерсдорф бистәсен азат иткән чакта сугышчылары һәлак булган пулемет артына басып, үзе шуннан ут ача һәм контрһөҗүмгә ташланган 30 дан артык гитлерчыны юк итә. Әмма яу барышында үзе дә һәлак була һәм вафатыннан соң 2 дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.


Посмертно.
Все графы заполняются полностью.
НАГРАДНОЙ ЛИСТ
115
1. Фамилия, имя и отчество: Гарипов Мансур Асатович
2. Звание: гв. мл. лейтенант 3. Должность, часть: командир пулеметного взвода 240 Гвардейского стрелкового полка 74 Гвардейской стрелковой дивизии
Представляется к: ордену «Отечественная война 2 степени»
4. Год рождения: 1916 5. Национальность: татарин 6. Партийность:
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда):
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне: убит
9. С какого времени в Красной Армии: с 1941 года 10. Каким РВК призван: Октябрьским РВК города Москвы
11. Чем ранее награжден (за какие отличия): Не награждался
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи –

1. КРАТКОЕ, КОНКРЕТНОЕ ИЗЛОЖЕНИЕ ЛИЧНОГО БОЕВОГО ПОДВИГА ИЛИ ЗАСЛУГ

... орденом «Отечественная война 2 степени»

Командир 240 Гвардейского ... полка
Гвардии подполковник ... Шишкин

Командир (начальник)
(подпись)
... Мая 1945 г.

Мансур Гариповны вафатыннан соң сугышчан орден белән бүләкләү кәгазе.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

Иске Ашыт Саярасы

Арча районының Иске Ашыт авылында зур бәйрәм булып узды: 40 ел гомерен авыл клубында эшләүгә багышлаган атказанган мәдәният хезмәткәре, Арча районының мактаулы гражданины Саяра Фәттерахмановны искә алу кичәсе үткәрелде. Исән булса, аңа 95 яшь тулыр иде.

Саяра апаның хыяллар белән тулы үсмерлек еллары сугыш урлый, ул өлкәннәр янәшәсендә ул чордагы барлык михнәтләрне кичерә. Әле буыннары да ныгып өлгермәгән Саяра элеватордан симәнә орлыгы ташый, таңнан кичкә кадәр кырда бил бөгә, урып-җыюда катнаша, күмәк хуҗалыкның барлык эшләрен башкара. Әмма Саяра боегып утырырга яратмый. Җыр да сузып җибәрә, биеп тә алгалый. Шушы сыйфатлары аркасында, чандыр кызны 1947 елда авыл клубына мөдир итеп куялар.

Саярага нибары 19 яшь, яңа гына килен булып төшкән чагы. Никахлашу үткәннең 22 нче көнендә Саяра ханым ирен армиягә озаткан. Ире Рафаэль өч ел буе хәрби хезмәттә була. Шул арада яшь килен йорт-җирне бизәргә керешә. Сугыштан соңгы елларда бик кадерле булган ситсы табып, тәрәзә пәрдәләре дә тектерә. Күрше-тирә йортны «Курчак өе», дип бәяли.

Бу – халыкның икмәк-бәрәңгегә тамагы туймаган, әтиләрен югалткан ятимнәрнең күз яшьләре дә кипмәгән еллар. Халык сугыш китергән хәерчелек белән көрәшә. Кыз авыл кешеләренең күңелен күтәрү, аларны мәдәнияткә тарту кирәклеген яхшы аңлый. Эш урыны исә – иске мәчетне сүтеп торгызган җиде тәрәзәле клуб. Кыз аны ул еллардагы мөмкинлекләрдән чыгып тәртипкә китерә, тишек-тошыкларын томалый. Саяра эштән арып кайткан егет-кызларны керосин лампалары асып яктыртылган, мичнә карлы-бозлы салам, агач ботаклары ягып, аз булса да җылы өретелгән клубка җыя. Утырырга урыннар да санаулы, кайсы терәксез, кайсы аяксыз җиде урындык. Аптырап тормыйлар, бүкәннәр табып, шуңа такталар куеп утыралар. Яшьлек үзенекен итә: клубта «Наза», «Агач башмак», «Чабата», «Зәлидә» кебек җырлы-биюле кичке уеннар гөрли. Көйләрне исә ике рәтле гармунда Саяра үзе яңгырата, такмак әйтеп тә биилэр. Инде алга таба үзешчәннәр көче белән концертлар да куела башлый. Әмма клуб мөдиренең авылдашларын спектакльләр күрсәтеп сөендерәсе, рухи дөньяга алып керәсе килә. Шулай итеп театр коллективы барлыкка килә. Репетицияләр, кичке уеннар, концерт хәзерләүләр төнге берләргә кадәр сузыла. М.Фәйзинең «Асыльяр»ы, «Галиябану» ы, М.Әмирнең «Тормыш җыры», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е, «Сүнгән йолдызлар»ы, Таҗи Гыйззәтнең «Чаткыннар»ы, һ.б. спектакльләр сәхнәдә куела. Кинонәрне исә авыл кешеләреннән дә алып торгалыйлар.

Ф.Фәтхи әнисе Саяра белән

Саяра Фәтхрахманова

Тирә-күрше авылларда ашытларның дәрәҗәләре дә үсә. Аларның спектакль куячагы турында хәбәр яшен тизлегендә тарала, яше-карты клубка агыла, күрше-тирә авыллардан да киләләр. Баш рольләрдә исә – Саяра үзе. Кышкы озын кичләрне ямьләндерү ниятеннән өчәр атка төялеп, спектакльләр белән күрше авылларга баралар. Соңрак бу сәфәрләр трактор арбаларында кылына. Саяра ханымның өенә – кайнанасы һәм ире Рафаэль янына төнге икеләрдә, өчләрдә кайткан көннәре күп була. Иртән исә икенче авылга бару өчен, яисә бәрәр кирәк-ярак сорап, күмәк хуҗалык рәисе янына иртәнге дүрттә нәрәдка төшеп утырырга кирәк. Үзеннән-үзе «Бер дә арымадымы икәнни?» - дигән сорау да туа. Әле бит йортта тавык чүпләп бетермәслек эшләр күтеп тора. Әлбәттә, арыгандыр. Бу уңайдан Ташкичү мәдәният йорты директоры Гөлфия Магсумова шундый бер вакыйганы да искә алып сөйләде.

Бер спектакль барышында Саяра үзенең сәхнәгә чыгар вакытын көтеп урындыкка утыра һәм йокымсырап китә. Инде аның «баз»дан менеп сәхнәгә чыгар вакыты житә, ә ул – юк. «Саяра, Саяра!» диешәләр. Моны залдагы халык та сизеп ала. Шулвакыт, «Базга төштем дә, менә алмый тордым бит җаным!» – дип сәхнәгә Саяра апа килеп керә. Барысы да мөлаем елмаеша.

Еллар үтә. Клубка күмәк хуҗалык ярдәме дә сизелә башлый. Озын эскәмияләр барлыкка килә. Концерт-спектакльләр куйган акчага да кирәк-яраклар, шул исәптән, җиде телле гармун да сатып алына. Алга таба, клубны сүтеп, иске бүрәнәләрне алыштырып, яңадан салалар, хромка гармун да алалар. Клуб мөдире вокаль инструменталь һәм фольклор ансамбльләр дә оештыруга алына. Ашытлылар район күләмендә узган смотрларда алдынгы урыннар яулый. Мәдәният йорты исә озак еллар дәвамында «Социалистик ярышта җиңүче» вымпелын үзендә тота. «Сине ташлап китә алмыйм» спектакле белән Кукмарада узган авыл клублары арасындагы бәйгегә бару да уңыш китерә. Алар җиңүче исемен яулый. Театр коллективына режиссер Ш.Сарымсаков тәкъдиме белән халык исеме бирелә.

Саяра ханымга заманына күрә агитатор да, рәссам да булырга туры килә, агитбригада оештырып, колхоз кырларында, ындыр табакларында концерт та куялар. Ә авылга артистлар килсә, Саяра апаның самавыры кайнаган, өстәле әзерләнгән була. «Саяра апа безне матур каршылады, ул авылның горурлыгы булды», – дип искә ала Татарстанның халык артисты Рабига Сибгатуллина. Артистлар күп очракта Саяра апаларда куна. Кайнанасы Галия абыстайның аларны бәлеш пешереп көтеп тору гадәти хәлгә әверелә.

Саяра ханым көн саен эштән төн урталарында гына кайтса да, кайнанасы Галия абыстайдан аз гына да кырын сүз ишетми. Килен-кайнана арасы һәр кешегә үрнәк итеп куярлык була. Саяра апаның ике улы Рифат һәм Фердинад (Татарстанның халык артисты Фердинанд Фәтхи), ул кичләр буе клуб эше, концерт, спектакльләр куюю мәшәкате белән йөргәндә, әби карамагында калган. Килене дә кайнанасы хакын хаклап яшәгән. Әйтик, авылда абыстай булып гомер иткән кайнанасы мәетләр юып кайтканда, Саяра аның кайтуына мунчасын ягып торган, киемнәрен юып элгән. Галия абыстай әҗәл авыруы белән ятканда да, Саяра апа казан кабартмасы пешерү өчен баскан камырын аның янына алып чыгып, булганмы әле, дип күрсәткән. Әбекәй керфеген сирпеп карап ала да, әз генә баскала әле, ди. Гомере буе аш-суга, камыр ризыклары әзерләү осталыгы белән даны чыккан кайнанасы янында яшәгән Саяра апа камырның әле әзер түгеллеген белгәндер, әмма кайнанасының күңелен күрү, аны олылау ниятеннән киңәшкәндер. Ул, Галия абыстай шушы авылда яшәүче кызы янына бәрәр атнага киткән вакытында да, «Әнкәйнең күңеле булсын», – дип, кереп хәл-әхвәлен белеп чыга торган була. Дүрт егет, бер кыз тәрбияләп үстергән Галия абыстай вафаты алдыннан Саярага бер сер чишә. «Киленнәрем арасында иң яраткан син булдың. Масаеп китмәсен дип кенә сиздермәдем», – ди.

Саяра апа Фәттерахмановларга килен булып төшкәндә, бер йортта ике килен дә бергә торганнар. Әмма йортта тавыш чыкмаган. Малларны күп асраганнар. Саяра апаның аларга иртәнге өчләргә кадәр бәрәңге тураган чаклары булган. Бүген авыл халкы «Алар бик матур яшәде», – дип сөйли.

Саяра апа улы Рифат өйләнгәч тә, кайнана-килен арасын сакларлык итеп кора. Улы Рифатның җәмәгате Сәвия ханым «Ул минем үз әнием кебек булды. Без сердәш кебек идек, эч серләребез уртаклаштык. Һәрвакыт ачык йөз белән каршы ала иде», – дип искә ала.

Саяра апа оныкларының да яраткан әбисе була. Татарстанның халык артисты Фердинанд Фәтхинең исә әнисенә мөнәсәбәте риваятьләргә тиң. Ул, әни матурлык эчендә яшәсен дип, йорт та салып бирә. Бик күп операцияләр кичергән әнисен табибларга йөртә. Саяра апаның 92 яшькә җитеп бакыйлыкка күчүенең бер сере шушы кайгыртучанлыктадыр...

Шунысы күңелле: Арча районы, авыл халкы һәм җитәкчеләре Саяра апага хөрмәтне үзе исән вакытта ук күрсәтеп өлгерә. Аның барлык юбилейларын мәдәният йортында зурлап уздыралар, күңелләрендәге иң матур хисләрен җиткерәләр. Саяра апа «Мәдәният – ул халыкның җаны, күңел көзгесе», дип кабатларга яраткан. Бүген Иске Ашыт мәдәният йортының диварына шушы сүзләр язып куелган. Мәдәният йортына Саяра Фәттерахманова исеме бирелгән. Иске Ашыт халык театры да Саяра апа исемен йөртә. Берзаманны мәдәният йортына кергәндә, яндагы бакчада Саяра апаның бюсты да басып торыр әле.

Саяра апаны искә алу кичәсе истәлекләргә бай булды. Килүчеләрне Ташкичү мәдәният йортының «Өммегөлсем» фольклор коллективы җырлап-биеп, төрле уеннар белән каршы алды. Кәй-моңнарыбыз исә Татарстанның халык артисты Рабига Сибгатуллина, композитор, Татарстанның халык артисты Фәрит Хатыйпов, Халыкара конкурслар лауреаты Энже Шәймурзина, музыкант Рафинат Сәләхов, Татарстанның атказанган артистлары Гөлшат Имамиева, Вәис Бәйрәмов һәм Татарстанның халык артисты, Саяра апаның улы Фердинанд Фәтхи башкаруында яңгырады.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

«Җиз самавыр» кунак җыйды

Халкыбызның үткәне төрле вакыйгаларга, йола, гореф-гадәтләргә бай. Хәтта район, авыл саен шул җирлекнең үзенә генә хас йолалары булган. Мәшһүрләребез Г.Тукай, Ш.Мәрҗәни, С.Хәким эзләрен саклаган Әтнә районында да шундый йолалар яшәгән.

Әйтик, Кышлау авылында гасырлар дәвамында буыннардан-буыннарга тапшырылып килгән самавыр агарту йоласы сакланган. Чәчүләр тәмамлангач, Сабан туе алдыннан, урамнары белән авылның Маһитап чишмәсе янына килеп, самавыр чистарта торган булганнар. Бу, мөгаен, Сабан туена кайтачак кунакларны каршы алырга әзерләнү дә булгандыр. Җиткән кызлар, әни-җиңгәчәйләр чишмә янында самавыр чистартканда, балалар шул тирәдә ду килеп уйнап йөргән. Аннары көзге кебек, йөзләрне чагылдыра торган итеп ялтыратылган самавырларны су тутырып кайнарга куйганнар. Шул арада җырлы-биюле уеннар белән, күңелле итеп бәйрәм иткәннәр. Икенче көнне башка урам кешеләре чишмә янында самавырларын ялтыраткан. Авыл – зур, шәхси хуҗалыклар күп булу сәбәпле, самавыр агарту 4-5 көнгә сузылган. Ахырда зур итеп бәйрәм үткәреп, күңелле ял иткәннәр. Бөек Ватан сугышы башлангач, аннан соңгы елларда әлеге йола онытылып торган. Соңгы елларда авылның Кышлау мәдәният йорты директоры, «Чишмә» халык фольклор ансамбле җитәкчесе Зөлфия Шакирова җитәкчелегендә авылның өлкәнрәк кешеләреннән сорашып, йоланың нечкәлекләрен өйрәнгәннәр һәм берничә ел элек «Җиз самавыр» йоласын кире кайтарырга ниятләгәннәр. Беренче тапкыр ул авыл күләмендә генә уздырылса, узган ел фестивальне районның сәнгать коллективлары катнашында зурлап үткәргәннәр. Бәйрәм исә элекке еллардагыча Маһитап чишмәсе янында гөрләгән. «Халык аны бик яратып кабул итте, ел саен уздыруыбызны сорадылар», – ди З.Шакирова.

Быел инде Кышлау авылында «Җиз самавыр» фестивале республика күләмендә үтте. Бәйрәмгә килүчеләрне Маһитап чишмәсе янында парларын чыгарып кайнап утырган самавырлар, коймак, тәм-томнар куелган өстәлләр белән каршы алдылар. «Җиз самавыр» йоласын Кышлау авылының «Чишмә» фольклор ансамбле «Чишмә юлы» күренеш белән башлап җибәрде. Бәйрәм тантанасы исә Әтнә районы башкарма комитеты рәисе Айрат Каюмов, Әтнә мәдәният бүлеге җитәкчесе Алия Абдуллина сәламләве белән ачылды. «Йолаларны искә төшереп, аларны киләчәк буыннарга тапшыру ниятеннән без дә читтә калмаска тырышабыз. Тарихны әле тагын да барларга кирәк. Яшьләргә тарихны житкерү – безнең максат», – ди А.Каюмов.

Фестивальгә республиканың 9 районынынннан 25 ләп сәнгать коллективы килгән иде. «Фольклор-этнографик күренеш», «Халык җыры», «Халык биюе», «Инструменталь башкару» номинацияләрендә тамашачылар хозурына «Самавыр юу», «Каурый сыдыру йоласы», «Көтү озату», «Мунчала чыгару», «Печән чабу», «Аулак өй» һ.б. күренешләрне тәкъдим иттеләр.

● Айрат Каюмов

Өлкән һәм урта яшьтәге җырчы-биючеләрдән торган коллективлар янәшәсендә яшьләр дә күп икән. Арча районы мәдәният йортының «Хәзинә» фольклор коллективы – шундый яшь егет-кызларны берләштергән ансамбль. «Оешканыбызга әле бер ел да булмады. Яшьләрдән генә хасил фольклор ансамбль тупладык. Монда «Көтү озату» фольклор күренешен алып килдек. Хәзер инде авылларда электр көтүчеләре эшли, малларны куу да онытылып бара. Башка яшьләрнең дә фольклор күренешләргә тартылуын телибез», – Арча районы мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Ләйлә Хәкимова.

«Умырзая» фольклор ансамбле Апас районынынннан килгән. Яңарак кына оешкан коллективның «Җиз самавыр» фестивалендә беренче чыгышы. Алга таба ансамбльне тагын да зурайтып, Апас ягындагы йолаларны күрсәтеп, районнарын танытуда аларның ниятләре.

Буа районынының «Ләйсән» халык җыр һәм бию ансамбле ансамбле тамашачыларны оста чыгышы белән сокландырды. Коллектив солистлары И.Шәйхаттаров һәм Х.Җиһаншина башкарган «Җизнәкәй» җыры да күңелләрне күтәрде. «Районыбызда «Ләйсән» коллективынннан тыш бер генә чара да, бәйрәм дә узмый. Сабантуйлар үткән вакытта төрле өлкәләрдә чыгышлар ясыйбыз», – ди ансамбльнең җитәкчесе Люция Сибгатуллина.

● Реваль Закиров

Чишмәнең Маһитап исеме белән аталуы да кызыклы иде. Бәйрәмдә әбинең оныгы «Стеклолайн» фирмасы җитәкчесе Реваль Закиров та катнашты. Ул үзенә 6-7 яшьлек чагында, сугыш михнәтләре белән онытылып, ташландык хәлгә килгән чишмәне әбисе Маһитапның, мөмкин булганча дүрт ягына шифер утыртып, өстен каплап төзәткәләп йөрүен хәтерли әле. Әбекәй астан кайнап торган чишмәдән суны чиләкләренә чүмеч белән тутырып алып кайта торган булган. Чишмә дә рәхмәт әйткәндәй суы артып, зураеп киткән. Реваль үсә төшкәч, иптәшләре белән су чыганагын казып, аңа шаң куеп ага торган итеп ясаганнар. Чишмә тагын да ямьләнгән. Маһитап әби исә чишмәне гел карап, чистартып торган. Ул инде 80 не узып бакыйлыкка күчкән. Аның бүген 15 оныгы, 30 оныкчыгы бар. Чишмәнең баскычларын Маһитап әбинең улы ясаса, соңрак аны оныгы Реваль тимердән эшләп куя. Ә биш ел элек чишмә «Таң» күмәк хуҗалыгы көче белән тагын да яңартыла.

Авыл җирлеге рәисе Айрат Кашапов белән дә гаплəшеп алдык. Ул соңгы елларда Кышлауда яшьләр кимесә дә, авылның әле шактый нык булуы турында әйтте. «Таң» авыл хуҗалыгы кооперативында эш урыннары бар, хезмәт хаклары да әйбәт», – ди ул. Авыл тормышын исә мәдәният хезмәткәрләренең актив булуы, аларның төрледән-төрле бәйрәмнәрне әйбәт оештыруы бизи.

Бәйрәмдә читтән кайтучы кунаклар да хәтсез иде. Налия Закирова Казаннан махсус кайткан, ул үзе мөнәҗәтләр башкара икән. Арча районында үткән «Мөнәҗәтләр» бәйрәмендә гран-прига лаек булган.

«Җиз самавыр» фестивален Татарстанның халык артисты Рабига Сибгатуллина, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Фәрит Хатыйпов һәм Татарстанның халык артисты Фердинант Фәтхи чыгышлары да ямьләндерде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

● Бәйрәм күренешләре

АКТАНЫШ

Актаныш районыннан чыккан бер «шомабаш» Бөтендөнья татар конгрессына сәер кәгазь китереп тапшырган. Ул Актаныш районындагы авылларның кайсы елларда нигезләнгән булуын бәян итә, имеш. Әлеге исемлекнең ни дәрәҗәдә тозсыз һәм фәнни яктан шыр-нигезсез булуын ачыклау өчен, сезгә дә күз төшереп алырга ирек бирик.

Мәчти-Наратлы – 1134, Иске Өшәр – 1135, Байсар – 1212, Иске Балтач – 1236, Түмерҗә (Таймурза) – 1250, Иске Такталачык – 1300, Шәбез – 1322, Түбән Гәрәй – 1342, Әҗәкүл – 1350, Иске Кормаш – 1360, Иске Богады – 1370, Иске Әлем – 1400, Теләкәй – 1400, Иске Кадермәт – 1409, Иске Сәфәр – 1415, Иске Айман – 1423, Адай – 1435, Күҗәкә – 1450, Олы-Имән – 1500, Мерәс – 1520, Апач – 1558, Тыңламас – 1680, Чуракай – 1768, Актаныш – 1780, Ирмәш – 1850 елда нигезләнгән, имеш...

Әлеге шыр-ялганнан хасил исемлекне шыр-наданнарның хакыйкать дип кабул итүе бар. Ә ялган мәгълүматне юкка чыгармыйча ярамый.

Мисалны зур, данлыклы авылга исем биргән морза Байсар Күзәшевтан башлыйк. 1653 елның 5 мартында Уфа воеводасы Иван Франзбековка язган үтенеч хатында **Бүләр *(Байсар авылының тәүге исеме)*** авылында гомер итүче ясаклы «башкорт» Байсар Күзәшев үзен 80 яшьлек карт дип күрсәтә. 1653 елдан 80 не алсак, Байсар 1573 елда туган булып чыга. Бүләр авылы фәкать ул вафат булганнан соң, димәк, 1700 елларда гына Байсар исемен ала. Ә Бүләр авылына вотчина грамотасын Байсарның бабасы Күккүз-Күгәй-Күзәш би **1586** елда алып бирә. Бүләр авылы өчен ясакны Байсар морзаның бабасы Күккүз би 1573 елдан бирле түләп килә. Ә 1816 елгы җанисәп Байсар авылының 11 йортында Бүләр волосте вотчинниклары яшәвен ачыклый, ә 69 йортта Йәнәй волостеннан килгән «башкорт» типтәрләре «канат җәеп» ята. Бар мәгълүматны да бергә җыйсак, Бүләр авылы **1560-1570** елга кадәр үк тамыр җибәрә, ә Байсар исеме белән 1700 еллардан соң гына танылa. Ягъни, Байсар авылының килеп чыгышын мифик 1212 елга илтеп тоташтыру – тулысы белән уйдырма һәм ялган!

Мерәс авылы да 1730 елларда Байсар авылында гомер итүче Мерәс Солтанаев исеме белән бәйле. Әлеге Мерәс атлы «башкорт» **1738** елның 19 сентябрендә Гәрәй һәм Йәнәй волосте «башкортлары» белән Уфа канцеляриесенә бара һәм Йәнәй волостендагы Төкәй авылы старшинасы Ирмәш Урмашев белән бүгенге Бакалы районының Киләй авылыннан күченгән йөзбашы Мәсәгуть Абызаевка Бүләр волосте биләмәсендә булган Сөн һәм Сикия елгалары ярында 30 ар йортлы үз авылларын булдырырга рөхсәт бирә. Каракүл конторасында 1707 елның 8 июнендә теркәлгән икенче бер документ буенча, Йәнәй волостеның Төкәй авылы (хәзер Илеш районында) вәкиле Ирмәш Урмашев ул вакытта Бим елгасы буендагы Шайтан авылында гомер итә һәм анда тегермән төзергә рөхсәт сорый. Ә 1738 елда Бүләр волостена күчеп килгән, Ирмәш – Агыйдел буенда, ә йөзбашы Мәсәгуть Сикия елгасы ярында үз авылларын нигезли. Бездә Шәймөхәммәт, Хуҗамөхәммәт, Исәймөхәммәт кебек исемнәрне Шәммәт, Хуҗәмәт, Исәммәт рәвешендә бозып сөйләшү йә яртылаш йоту һәрчак «модада» бит, Мәсәгуть авылы да озакламый «Мәчти» булып китә. Әгәр аңлашылса, Мерәс авылы – һичнинди 1520 елда түгел, ә 1730 еллар тирәсендә, һәм Мәчти-Наратлы да 1134 тә түгел, ә **1738** елда гына канат җәйгән!..

● **Район чигендә юлчыларны Актаныш менә шундый панно белән каршылый.**

Теләкәй авылы һичничек тә 1400 елда нигезләнгән булып санала алмый, чөнки Теләкәй Улакаев атлы гаять зур биләмәләр һәм меңнәрләгән елкы атлар хуҗасы булган морза 1670-1680 елларда бүгенге Красный Бор, кичәге Пьяный Бор (татарча исеме Пәнҗәр) авылы янындагы үзенең вотчинасын Софья атлы патшабикә Савва-Сторожев монастырена бүләк итә башлагач, һәм аеруча Петр һәм Иван Алексеевичлар 1681 елның 16 маенда татар морзаларын көчләп чукындыру, ә чукынмасалар крестияннарын һәм вотчиналарын тартып алу турында фәрман чыгарганнан соң, Уфа-Казан юлындагы барча крестияннарны азатлык явына күтәрә. 1682 елда хәтта Уфадан чыккан воевода Д.Коркодинов гаскәрен дә тар-мар иткәннән соң, воеводаны кәнәфиеннән алып ыргыталар. Д.Барятинский атлы яңа воевода гаскәре белән бәрелешләр вакытында яраланып, Теләкәй морза әсирлеккә төшә. Карательләр аны 1684 елда дар агачына асып үтерә. Актаныштa **1650** еллар тирәсендә нигезләнгән Теләкәй авылы да, 1719 елда Илеш районында барлыкка килгән һәм 4 ел элек үзенең 300 еллыгын бәйрәм иткән яңа бер Теләкәй дә каһарман яу башлыгының исемен йөртә...

Тарихи документларның берсендә Апач мулла Тутаев белән Әгъбәс Дускаев исеме аерылгысыз. Бүләр волосте «башкорты» Әгъбәс Йәнәй волостеннан килгән Апач муллага **1731 елда** үзенең Шәбез елгасы буендагы вотчинасында авыл корырга рөхсәт бирә һәм Апач хәзрәт шул елда ук күрсәтелгән урында үз авылын калкыта. 1735 елда ерак бабалары җирендә Оренбург каласын төзү башлангач, Теләкәй морзаның оныгы Акай Күчемов белән Килмәк абыз Норышев җитәкчелегендәге яңа азатлык явы кузгала. Карательләр ягына сатылган өчен Апач мулланы якташ крестияннары ук каен агачына асып юк итә, әмма өч елдан соң карательләр Акай батырны да Петербургтагы Шлиссельбург крепостена алып китеп, дар агачына асып үтерә. Инде аңлашылгандыр: Әгъбәс бернинди дә 1769 елда яшәми, ә 1730 елга кадәр үк үз исемендәге авылны нигезли. Апач мулла өчен дә 1558 ел бөтенләй төшенә дә керә алмас заман, ул 1731 елда гына үз авылын корган, ә 1735 елда агач ботагына асылган...

Мөгаен, җитәрдер дә. Авыллар тарихын төптән белү өчен әлле-мәлле, бик тә шикле шәҗәрәләр актару гына җитми. Авыл тарихлары аерым шәхес һәм вакыйгаларга, татар милләтенең тарихына бәйле. Милләт тарихы һәр авылда булган вакыйгалардан, шуларда туып үскән шәхесләрдән тора. Иҗекләрдән – сүзләр, тезмәләрдән зур әсәрләр тудырган шикелле, милләт тарихын да ашлык бөртегедәй кадерле вакыйгалар һәм алар агышында кайнар мич янына басып татлы ризык әзерләүче пешекчеләргә охшаш авыл әйдәманнары, дин әһелләре һәм халык бәхете хакына башын җуярга әзер каһарманнар тудыра.

Ә хәзер Актаныш районында барлыкка килгән авылларның архивлардан табылган асыл тарихына күз йөгертик. Ни кызганыч, 1959 елда гына районны 129 авыл тәшкил итсә дә, хәзер алар саны 87 гә генә калган. Монысы да безнең ачы тарих.

●**Актаныш авылы үзәгендәге Җиңү паркында Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларыбыз хөрмәтенә куелган һәйкәл.**

Байсар – Кыргыз волосте җирләре һәм андагы авыллар, шул исәптән яшәвенең тәүге елларында Бүләр исемен йөрткән Байсар авылы өчен тәүге вотчинная грамотага Иске Кыргыз авылында яшәүче Кушык бинең улы Күккүз-Күгәй-Күзәш би **1586** елда ия була. Башкортстан галиме Әнвәр Әсфәндияров ни өчендер Кыргыз волостена һәм андагы авылларга тиешле вотчинная грамотаны Күккүз бинең игезәк уллары Кылчан белән Тонуз (Тәнеч) бары тик 1632 елда гына алуга ирешә, дип бара. Әмма 1632 елгы грамота 1613 елда Михаил Романовны патша итеп утыртканнан соң, кыргызлылар тарафыннан яңа хакимдардан яңартып алынган икенче грамота була бит ул! Ә Уфа провинциясе карамагында булган һәм Сөн белән Ык елгаларының ике як ярлары буенча сузылып урнашкан барча «башкорт» волостьларының 1620 елга кадәр үк үз җирләре өчен вотчина грамоталары алып бетерүе билгеле, моны башкорт галимнәре дә раслый. Өстәвенә, Карабәк-Габдулла хан нәселенә кагылышлы шәҗәрәдә Байсар авылына һәм Кыргыз волостена тәүге вотчина грамотасын Күгәй-Күзәш алып бирә, дип ачыктан-ачык языла. Карабәк шәҗәрәсенең 30 варианты Уфа архивларында да тупланган, Ә.Әсфәндияров «шәкертләре» шуны ачып та моңа инана ала.

Йәнәй-Җәнәй волостеның Исәнбай авылында бөек кенәз Алексей Михайлович Романов тарафыннан **1659** елда бирелгән грамота белән яшәүче дистәгә якын вотчинник **1713** елның 16 маенда төзелгән килешү буенча инде Бүләр волосте составына күчкән Байсар авылы җирләренә килеп урнаша. 1738 елның 9 сентябрендә төзелгән яңа бер килешү нигезендә Йәнәй волостеның Тугыз түбәсеннән (әлеге түбәдә 9 татар авылы тупланган) икенче партия «башкорт» типтәрләре дә күчеп килә. Беренче елларда алар үзләрен Бүләр волостендагы җир хуҗалары белән бертигез хокукта тоеп яшәсә дә, Оренбург конторасы 1816 елдан соң килмешәкләргә бер ир-атка 15 дисәтинә исәбеннән генә җир бүлеп бирү турында карар чыгара, чөнки Байсар авылына тиешле җирләр элек 586 кешегә генә исәпләп бирелгән була. Йәнәй волостеннан күчеп килгәннәр имана җирен һичьюгы 30 дисәтинәгә җиткерүне үтенеп хатлар юллап карый. Власть ияләре тарафыннан бернинди миһербанлык авазы да ишетелмәгәч, 1852 елда килмешәкләр үзләрен яңа Йәнәй волостена кайтаруны һәм аларга анда 40 ар дисәтинә имана җире бүлеп бирүне таләп итә башлый. Әмма хәзер Йәнәйлеләргә бу чорда инде Вятка губернасының Сарапул өязе составына күчерелгән якташлары хыянәт итә, алар Байсардагы якташларын

кире кабул итүдән баш тарта. Ә Байсар гаҗәеп зур тизлек белән үсеп баручы авыл бит. 1859 елда ук анда яшәүчеләр саны 1331 «башкорт»ны һәм 84 татарны тәшкил итә. 1860 елдан соң инде бер төркем крестияннар Сөн елгасы буйлап югарырак урынга, Яңа Байсар авылын нигезләп күченә. Илле гаиләдән дә ким булмаган икенче төркем нәкъ шул ук вакытта бүгенге Башкортстанның Яңавыл районы

АВЫЛЛАРЫ

● Бөек Ватан сугышы чорында тылда хезмәт куючы якташларыбыз хөрмәтенә һәйкәл.

территориясендәге Биз елгасы буена күчеп урнаша. Ул Биз башланган урыннан алып Буй елгасына кадәр сузылган җирләр һәм андагы Болан күле әле **1605** елда ук Йәнәй волосте вотчинникларына беркетелгән була (История башкирских родов. Гирей. 86 бит). Моны «Аулы мензелинских башкир» китабында (287 бит) галим Ә.Әсфәндияров та раслый: «Поля начинаются у селения Байсарово и кончаются в Бирском уезде». Икенче урында ул «Йәнәй волосте вотчинникларының җирләре Оса елгасына кадәр сузыла», дип тә өсти (25 бит).

Тагын шунысын да искә төшерик: **1738 елда** Сикия елгасы буенда Мәсагуть-Мәчти авылын корган чакта, аңа Байсардан да берничә гаилә күченә, алар янына Башкортстанның бүгенге Шаран районындагы Шыгай авылыннан 8 гаилә килеп өстәлә. Шулай ук XVIII гасырда Агыйдел буенда Каентүбә исеме астында яшәп яткан, ә бераздан Тат.Әҗбигә әверелгән авылга да 1800-1808 елларда Исәнбай (Әгерҗе районында), Байсар, Апач, Сикия, Кадермәт, юкка чыккан Кәлтәү авылларыннан күченгән 20 шәр гаилә килеп өстәлә. 1910 елда янә 15 ләп гаилә, Столыпин хөкүмәте вәгъдә иткән ссудаларга алданып, Омск өлкәсенә тикле күченә һәм Байсар исемендәге яңа авылны нигезли, әмма тора-бара урыслашып бетә һәм исемен дә җуя... Без Байсар авылыннан төрле якка күчеп киткән төркемнәрне махсус рәвештә саныйбыз, чөнки ул авылның әледән-әле халык санын югалтып торуын дәлилли, ә үзе тау чишмәсе кебек, һаман ургып тора...

Гаҗәп хәл: байсарлылар әле 1912 елда да бәрәңгенең ни икәнен дә белми!

Өшәр (Семиостров) – Йәнәй волостена караучы үз җирләрен саклау-яклау грамотасын патша Михаил Федорович заманында, Уфада воевода булып И.Ф.Желябужский утырган (1628-1634) вакытта, **1632** елда Баичка (?) Туктамышев һәм һәм нәкъ шундый ук грамота копиясен Бикгимер Кадыйров ала. Грамота Мәскәүдә бирелгән була.

Йәнәй волостеның **Богады** түбәсенә һәм Богады авылының үзенә вотчинная грамота **1640** елда, Мәскәүдә Михаил Федорович патша булган, ә Уфада И.И.Салтыков воеводалык иткәндә, ясаклы «башкортлар» Янбакты Ходабәхтин, Магозячка (Мәгас-?) Байбәхтин һәм аларның иптәшләре кулына бирелә. Әмма шул ук воевода канцеляриясе бу авылда Янбакты Ходабәхтинның этисе һәм бабасы гомер итүен дә раслый, ә аңа бүлеп бирелгән биләмә Сөн елгасы буйлап Терпеле кушылдыгыннан Тыңламас авылына кадәр сузылуын да билгели.

Шул ук Йәнәй волостена караучы **Суыксу** авылы «башкортлары» Ямалейка (Җамали) Ядегәров һәм Уркенячка (Иркәнәш-?) Чирмешев, урыс килмешәкләре борын сузмасын өчен, 1638 елда үз җирләрен саклау грамотасын эләктерә. Үз җирләре өчен ел саен Казанга 65 сусар (куница) тиресе һәм 22 батман бал белән ясак түләп торуга карамастан, килмешәкләр һаман аларның Ык елгасы тамагында, Агыйдел һәм Кама елгасы буендагы ау һәм балык тоту урыннарыннан, Котыш янындагы күлләреннән (ә бүген бу җирләр Тукай районына керә) оятсыз рәвештә файдалана. Шуңа күрә **1669** елда Йәнәй волосте вәкилләре Бориска Биздергәнов, Онтошка Бисарин, Уркенечка Чирмешев Уфа воеводасы Федор Сомов кулыннан үз җирләренә хәтта бабалары да хуҗа булып торуын ассызыклаучы өстәмә грамота ала.

Искәрмә. Әле алда да татар яки «башкорт» крестияннары дәүләткә ел саен түләп барырга тиешле ясак яисә салым күләме искә алыначак. Салымнарны ул заманда кулланылган акча рәвешендә күз алдына китерү өчен, салым түләүдә мәҗбүр ителгән байлыкның бәяләрен дә саныйк. XVII-XVIII гасырларда бер төлке тиресенең бәясе – 80, сусар тиресе 40 тиен торган. Бер батман бал – 10 кадак яки 4 килограммга тиң (кайбер документларда бер батман бал – 9 килограммга тиң), шул күләмдәге бал 90 тиен бәяләнгән.

Йәнәй волосте XVII гасырның II яртысында түбәләргә бүленә. Бүген Пермь өлкәсенә күчкән Камбарка түбәсе, Башкортстанның бүгенге Краснокама районындагы Җәнҗегет түбәсе, Илеш районының яртысын үз эченә алган Кыргыз волосте ул заманда Минзәлә өязендә исәпләнгән. Кама елгасының Сарапул каршысындагы Камбарка елгасы буйларына хәтта әле XVIII гасырда да Йәнәй волосте крестияннары хуҗа булып торган.

Тыңламас авылы крестияннары **1658** елда Уфа воеводасы А.И.Головин янына үтенеч кәгазе тотып бара. Алар борынгы бабалары ук хуҗа булып торган, әмма нәкъ менә шушы елда Кыр-Елан волостендагы Баулы, Исергәп, Кызылъяр авылы җирләренең Байлар волосте крестияннарына бүлеп бирелүенә үпкә белдерә. Үтенечтә алар шул төбәк буйлап аккан Ык, Дим, Бәләбәй, Авыргазы, Нокыш, Бәшенде елгалары буендагы җирләренә, Олы һәм Кече Баулы күлләренә (болар барысы да бүген ике республика чигендәге Бәләбәй, Туймазы, Баулы, Ютазы районнарына карый!) борынгы бабалары ук хуҗа булуын, ул җирләрдән файдаланган өчен үзләренең Уфага ел саен 16 сусар тиресе, аңа өстәп 12 алтын (1 алтын = 3 тиен) да 2 тиен күләмендә ясак түләп торуларын да раслый. Әмма Рәсәйнең «гадел» казыйлары ул җирләр белән Байлар һәм Кыр-Елан волосте крестияннары уртак, ягъни яртылаш бүлешеп файдалансын, дигән шома карар чыгара, чөнки **Байлар** волостена җир грамотасы **1574** елда ук бирелгән булган икән.

Кыргыз волосте Сөн елгасының ике як яры буенча Ык һәм Зәй елгаларына кадәр сузыла. Кыргызлар – гәрәй, елан, кыпчак ыруларының вәкилләре белән бергә, Агыйдел буена XIV гасыр ахырында ук килеп урнаша. Кыргызларны Төкәй һәм Казыйкай (соңрак Кәзкәй булып үзгәрә) атлы бабалары алып килгән, ә ыру башлыклары Коркыт би булган, диләр. Коркытның Кушык би атлы бер дәвамчысы Агыйдел ярындагы Тәтеш күле буенда яшәсә дә, Сөн буенда Кыргыз атлы авылны нигезләгән. Аның Аккош (Аккүз) би һәм Күккүз би атлы ике улы булган. Соңгысыннан Кылчан һәм Тонуз-Тәнеч атлы игезәк бала туган. Менә шул игезәкләр **1632** елда, Уфада воевода булып кенәз М.Ю.Трубецкой утырган чагында, үз волостьлары өчен Михаил Федорович Романов исеменнән бирелгән вотчинник грамотасын яңартып алуга ирешкән. Аларга волостьтагы барча авыллар өчен ел саен 83 сусар тиресе һәм 17 батман күләмендә ясак түләү бурычы җиткерелгән.

Волость чикләре **1604** елда өр-яңадан билгеләнгән һәм, аның бер ягы Сөн буенча югары күтәрелеп, Ютазы елгасы тамагына, Баулы белән Зәй елгаларының югары агымына кадәр барып җиткән. Кыргыз волостенда яшәүче тархан Яукилде Морзакилдиев 1690 елда Уфа воеводасы Иван Тостововка мөрәҗәгать итеп, элек Казан өязенең Арча юлындагы Ачы авылы крестияны Бәйрәмхуҗа хуҗа булып исәпләнгән, әмма **1615** елдан бирле ташландык хәлдә яткан һәм Юшады елгасы (Минзәлә районы җирләрендә Ыкка килеп кушыла) буенда, Кызылъяр авылыннан (Баулы) Самара елгасына кадәр сузылган җирләрне үзенә алуга ирешә. Бүгенге Ютазы районындагы Акбаш, Бәйрәкә, Кара-Җирек, Кәрәкәшле, Ташкичү авыллары хәтта әле XIX гасыр азагына чаклы – Кыргыз волосте биләмәләре, ә Әбсәлам, Алабугалы-күл, Яңа Байлар, Димтамак, Баулы районындагы Иске Чүти – Байлар волосте җирләре булып исәпләнә!..

Кыргыз волосте хуҗаларына әле **1467 елда** Казан ханы Ибраһим тарханлык грамоталары бирә, бу хәл үзе үк Сөн елгасы буендагы җирләрнең Казан ханлыгына буйсынып яшәвен исбатлый. Актаныш районының икенче як чиге, элек Бүләр волосте составындагы Мөшегә түбәсе дә (хәзер андагы Әтрәкле, Мөшегә, Чупай, Яңа Айман авыллары – Минзәлә районында) **1523 елда** ук Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгы белән Шәех-Әхмәт тарханга һәм аның туганнарына бүләк ителгән була.

Хәзерге Актаныш районының бер өлеше булган Гәрәй волосте **1632** елда Җәнҗегет (Краснокама районында, ул авыл 1612 елда нигезләнгән) һәм **Такталачык** түбәләренә бүленә. Агыйдел аръягындагы җирдә 1641 елда Бөртек Ходайбәхтин үз авылын нигезли һәм Уфага барып, воевода Лев Плещеевтан грамота ала (ул төбәктә Әлфия Авзалова туган Кабан авылы – 1678, Ялгызнарат 1649 елларда тәүге тапкыр документларда искә алына). Ә Такталачыкның ышанычлы «башкортлары» 1700 һәм 1701 елда алган грамоталарда аларның бабалары бу җирләрдә борынгыдан бирле гомер итүе һәм аларның Агыйдел аръягындагы Ямады (Яңавыл районында), Кабан (Краснокамада) һ.б. күлләргә дә хуҗа булып торуы раслана. Тарихи документларда Такталачык авылы **1631** елда искә алына. Ул вакытта ук авыл икегә бүленә: Түбәнендә – типтәрләр, Югарысында «башкорт» вотчинниклары көн күрә.

1960 еллар азагында Казан каласыннан килгән бер төркем археологлар Такталачык авылында казу эшләре үткәрде һәм авыл янәшәсендә соңыннан XIV гасыр һәйкәле дип тамгаланачак тарихи урын тапты. Җәсәдләр мөселман кануннары белән җирләнсә дә, һәр кабердән диярлек керамик чүлмәк яки кувшин калдыклары табылу вафат булучыларның әле мәҗүсилектән тулысынча аерылып бетә алмавы, аларның ислам диненә әле күчеп кенә баруын ачыклады.

Әгъбәс – Бүләр волостеның Чуракай түбәсенә караучы, Калмия елгасы буена утырган авыл. Аңа нигез салучы Әгъбәс Дускаев исеме тарихи документларга 1731 елның 22 мартында килеп эләгә. Килешүдә «башкорт» Әгъбәснең Йәнәй волосте мулласы Апач Тутаевны үз вотчинасына яшәргә кертүе һәм аңа Шәбез елгасы буеннан җир бүлеп бирүе тасвирлана. Чыннан да, Апач шул елда ук үз исемендәге авылны нигезли һәм ел саен Әгъбәскә бер сусар тиресе күләмендә «ясак» түләп тора.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Матбугатның киләчәге

Героебыз: Интернетта беренче булып рәсми рәвештә эшли башлаган татар матбугат чарасын – «Интертат» Республика электрон газетасын озак еллар җитәкләгән Әлфия Туфан кызы МИҢНУЛЛИНА.

– Әлфия ханым, Сез – Казанда туып үскән татар кызы. Казан дәүләт университетының механика-математика факультетын тәмамлагансыз, әле шул юнәлештә укыткансыз да. Ни өчен математиканы сайладыгыз?

– Мәктәпне тәмамлаганда, 17-18 яшьтә, без киләчәккә һөнәрне, гадәттә, гаиләдәге карашларга нигезләнеп сайлыйбыз. Механика-математика факультетына укырга керүемә әни тәэсир иткәндер. Ул укытучы булырга хыялланган. Мин мәктәпне алтын медальгә тәмамладым, шуңа күрә теләсә кайсы факультетка керә ала идем. «Син яхшы укыйсың, әйдә, иң авырын сайлыйк», – диде әни. Иң авыры дигәне – механика-математика факультеты.

– Әтиегез хупладымы?

– Әти хупламады, хәтта үпкәләде. Аның мине татар филологиясе факультетына укырга кертәсе килгән иде... Ләкин мин беркайчан үкенмәдем. Мантыйкый уй-фикерләү дәрәҗәсен үстерү өчен математика өлкәсендә белем алу бик файдалы. Диплом алгач, юллама буенча фәнни институтларның берсендә программист булып эшләдем. Аннан соң, 7 ел Казан дәүләт педагогика институтында укыттым.

– Шәһәрдә үссәгез дә, Сез татарча иркен аралашасыз...

– Әти-әни өйдә татарча гына сөйләшә иде. Өстәвенә, мин бит артист баласы – театрда үстем. Ул вакытта әни эшләгән Камал театры – Казанда татар мохитен һәм телен камил дәрәҗәдә саклый торган бердәнбер урын иде, дип әйтергә була. Театрда эшләүчеләрнең барысы да диярлек татарча гына сөйләшә, башка милләт кешеләре дә татарча аңлый иде. Балачагымның күп вакыты театрда үтте, шуңа күрә татарча аралашып үстем.

Тагын бер мөһим фактор: татарча китаплар күп укыдым. «Ялкын», «Азат хатын», «Казан утлары» һәм «Чаян» журналлары, «Яшь ленинчы» газетасы, гомумән, татар телендә чыккан бөтен вакытлы матбугатны яздыра идек. Рус мәктәбендә укыгач, татар теле безгә факультатив рәвештә генә – физкультура һәм хезмәт дәресләре урынына укытылды. Укытучыбыз – Абдулла Алишның туганының кызы Илсөяр Сөнкишева кулыннан килгәнчә укытырга тырышты. Әмма факультатив – «гарип» дәресләр инде ул.

– Журналистикага мәхәббәт тарихы ничек башланды?

– Студент елларында Казан дәүләт университетының Интернациональ дуслык клубына йөрдек. Француз теле укытучысы Эльмира Хәбибуллина яшьләрдә француз мәдәниятенә мәхәббәт уятырга тырышты. Безнең шундагы эшчәнлек турында университетның «Ленинец» газетасына мәкаләләр язганым булды.

Минем буынның яшьлеге бик катлаулы чорга эләкте. СССР таркалып, без ияләшкән тормыш берничә ай эчендә үзгәреп куйды. Миңа ул вакытта 30 яшьләр, педагогика институтында эшлим, гаиләдә 2 бала. Хезмәт хакы коточкыч кимеде. Эшне алыштыру мәсьәләсе көн кадагында торды.

Эштән китәргә җыенуымны әйткәч, әти: «Бәлки «Татар-информ»га барып карарсың? Алар да компьютерларда эшли», – диде. Шулай итеп, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына килдем. Ул вакыттагы җитәкче Умар Хәмзән улы Богдалов бик җылы каршы алды. Шул редакциядә чыга торган «Татар иле» газетасына эшкә урнаштым. Бу газетаны почта аша элеккеге союздаш республикаларда – Үзбәкстан, Казахстан һ.б. илләрдә яшәүче татарлар яздырып ала иде. Анда Татарстаннан читтә гомер иткән татарларның тормышы, язмышы, милли мәдәният, мәгариф мәсьәләләре яктыртылды. Мин дә мәдәният һәм сәнгать турында күп яздым. Әнине автор буларак матбугатка тарттым: ул да артистлар, театр турында мәкаләләр язды. Журналистика һөнәренә шулай аяк бастым.

Ул вакытта Россиядә әкренләп интернет тарала башлады. Компьютерлар белән эш иткән кеше буларак, интернет мөмкинлекләре белән кызыксынып тордым. Элек «Татар-информ»да корреспондентлар язган көндәлек яңалыкларның текстларын компьютерда җыялар, аннары принтерда кәгазьгә бастырып чыгаралар да, шуның күчермәләрен ясап, курьер белән Казан буйлап дәүләт оешмаларына (һ.б.) тараталар иде. Коточкыч катлаулы процесс! Ә башка төбәкләргә почта аша хат белән китә…

«Татар-информ»ның шул еллардагы генераль директоры Римма Ратниковага: «Безгә мәгълүматны «бабайлар ысулы» белән таратудан туктарга вакыт. Интернет форматны булдырып карыйк әле», – дидем. Ул: «Син аны беләсеңме?» – дип кызыксынды. Аннан «Татар-информ» хисабына мине Казан авиация институтына курсларда укырга җибәрде. Бераздан «Татар-информ»ның «Бердәмлек» редакциясендә «Татар дөньясы» исемле газета чыга башлады. Газетаның латин хәрефләре белән язылган варианты да әзерләнде, чөнки чит илләрдәге кайбер татар диаспоралары кирилл хәрефләрен белми. Үз вакыты өчен шактый уңышлы проект булды ул. Редакция туплаган яңалыкларны Казандагы татар редакцияләренә дә тараттылар. Финляндия, Төркия, Америка һ.б. илләрдәге татар диаспоралары безнең белән элемтәгә керде. Кырым татарлары даими рәвештә хәбәрләрен җибәреп торды. Бик күп танышлар, дуслар барлыкка килде.

– Матбугатның интернетка чыгуы дөнья буйлап сибелеп яшәүче татарлар белән элемтәләрне якынайтырга ярдәм иткән, димәк?

– Әйе, ләкин ул берьяклы гына процесс түгел. Милләттәшләребез ягыннан да омтылыш көчле иде. Аларның күбесе Казанга изге урын кебек карый. Алар, фантазияләренә бирелеп йөри дә, Казанга килгәч: «Нигә Казанда татарча сөйләшмиләр? Нигә татарча язулар юк?» – дип, безне аптырата иде. Чөнки Казанны татар үзәге итеп күрәләр. Хәзер алай ук түгел сыман, ләкин барыбер Казанга тартылу бар...

Үзгәртеп кору елларыннан соң Урта Азиядәге республикалар бәйсез дәүләтләргә әйләнгәч, аларда яшәүче татарлар милли матбугаттан мәхрүм калды. Элек алар татар матбугатын Казаннан яздырта иде. 90 нчы еллар башында бу мөмкинлек чикләнде, чөнки почта бәяләре кыйммәт, әлеге мәсьәләдә берничди сөйләшү-килешү юк... Шул чорда татар матбугатына зур зыян салынды – ул шактый киң катлау укучысын югалтты. Халык татарча укудан аерылды. Татарча укудан аерылдымы – телдән дә аерылды, дигән сүз. Читтә татар мәктәпләре юк бит.

● Әти-әнидә кунакта. 2010 ел.

– «Татар дөньясы» газетасы редакциясе күпме эшләде?

– 1-2 ел. Татарстанда без азмы-күпме татар мохитендә яшибез, ә читтәгеләр милли мохиткә сусаган. Кайберәүләр татар булып та, татар телен, мәдәниятен белмәскә мөмкин. Әмма иң мөһиме – татар булырга омтыла. Андый кешегә ничектер ярдәм итәргә кирәктер бит. Без әти белән шул темага бик күп сөйләштек. Әти Татарстан депутаты иде. «Әйдә, Дәүләт Советында бу мәсьәләне күтәрик, татарча электрон газета кирәклеге турында әйтик», – дигән фикергә килдек. Журналистлар арасында да бу турыда сүзләр күп булды. Мәсәлән, ул вакытта «Азатлык» радиосының Казандагы бюросын җитәкләгән Римзил Вәлиев белән татарларны барлау, туплау, Казанга җәлеп итү турында сөйләшкәнебез бар. «Интертат» Республика электрон газетасын булдырганда аның идеяләре дә роль уйнады.

«Интертат» сайты, Дәүләт Советы тәкъдиме белән, 2001 ел азагы – 2002 ел башында ачылды. Иң баштан без аны татарча электрон газета итеп күз алдына китердек, ләкин бөтенесе бездән генә тормый. Ул ике – рус һәм татар телләрендә мәгълүмат агентлыгы форматында эшли башлады. «Интертат»-ның беренче баш редакторы Владимир Шевчук киң карашлы кеше иде. «Татар редакциясе эшенә чикләүләр куймыйм. Үзегез ничек күзаллыйсыз, шулай эшләгез», – диде. Үзебез күзаллаганча ук эшләү мөмкин түгел иде, чөнки рус редакциясе өчен ясалган сайт структурасы кысаларында эшләргә мәҗбүр булдык. Шулай да татар аудиториясенә кызыклы темаларны яктыртырга тырыштык. «Татар дөньясы» газетасының аудиториясе «Интертат»ка күчте. «Татар-информ»нан киткәч, «Татар дөньясы» газетасы белән шөгыльләнүче калмады, шуңа күрә, кызганычка, ул проект ябылды.

● Әлфия әтисе Туфан Миңнуллин белән мәктәптәге чыгарылыш кичәсе алдыннан.

татар теленә бәйле

● Әлфия энисе Нәҗибә Сафина һәм кызы белән

– Беренче татар электрон газетасы – «Интертат»ка коллектив ничек тупланды?

– Башта үзем белгән журналистларга эш тәкъдим итеп карадым, тик компьютерда эшләргә теләк белдерүчеләр булмады. «Без кәгазьгә язып бирәбез, сез аны үзегез компьютерда җыегыз», – диләр. Ләкин электрон газетада эшне алай алып барып булмый. Үзе компьютерда җыеп яза торган журналистлар кирәк иде. Нәтиҗәдә, яшьләрне чакырдык. Педагогика институтында укыткач, миңа да яшьләр белән эшләве кызык, үзеңне яшьләрчә хис итә башлыйсың.

Беренче көннән редакциядә дус-тату коллектив тупланды. Яңа ел, 8 Март һ.б. бәйрәмнәрне бергәләшеп үткәргән күңелле мизгелләр истә. Шунысы куандыра: «Интертат»тан киткәнемә – 12 ел, газетада минем белән эшләгән журналистларның берсе дә тормышта югалып калмады. Аларның 80 проценты – хәзер Татарстан журналистикасында билгеле шәхесләр. Кайберсе баш редактор дәрәҗәсенә күтәрелде.

Мин, үземнән соң алмаш калдырдым, «Интертат» газетасыннан Татарстанда татар интернет журналистикасына нигез салынды, дип саныйм. Төп кадрлар шунда тәрбияләнде.

– Туфан абый электрон газета эшчәнлеген ничек кабул итте?

– Әти язучы гына түгел, публицист та – ул бик актив яза иде. Әкренләп, аны да интернетны кулланырга өйрәттек.

– «Интертат»та нинди темаларга, проектларга өстенлек бирелде?

– Онлайн форматта эшләгәч, «Интертат» редакциясендә пресс-конференция, иҗади очрашу, туры эфир һәм «түгәрәк өстәл»ләр үткәрә башладык. Беренче туры трансляцияне Салават Фәтхетдиновның концертыннан ясадык. Аны төрле илләрдән бик күп кеше карады. Татар кешесе кайларда гына яшәсә дә, барыбер күңел почмагында милли хисләрен саклый, аны кузгатып кына җибәрергә кирәк... Бөтендөнья татар конгрессының чираттагы корылтаеннан да туры трансляция ясаганыбыз булды. Болар – үз заманы өчен яңалык иде. Хәзер генә ияләштек, мәгълүмат таратуның мондый форматлары гел булган шикелле.

– Тукайга багышланган Gabdullatukay.ru сайтын да «Интертат» редакциясе ачкан. Бу проектны башларга нәрсә этәргеч бирде?

– Gabdullatukay.ru сайтын ясау безнең редакциягә йөкләнгән иде. Материаллар тупларга Татарстан Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Г.Тукайның Казандагы һәм Кырлайдагы музейлары, Татарстан Милли китапханәсе, Татарстан китап нәшрияты (һ.б.) күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итте.

Минем хыялым – Gabdullatukay.ru сайтын ачып җибәргәндә культурологик үзәк төзү иде. Мәсәлән, Германиядә немец шагыйре Гёте исемендәге институт бар, ул – алман мәдәниятен таныту белән шөгыльләнә. Казахстанда «Абай институты» проекты казах мәдәниятен бөтен дөньяга таныта. Мин дә Г.Тукай сайтын шундый үзәкнең башлангычы итеп күзаллadым. Ләкин бу идея чынга ашмады, чөнки финанслау булмады. Шулай да сайт бүгенге көнгә кадәр сакланды. Киләчәктә Татарстанда татар мәдәниятен, әдәбиятын, телен пропагандалаучы Тукай үзәге барыбер булыр, дип хыялланам.

● Татарстанның халык артисты Наилә Гәрәева «Интертат» редакциясендә кунакта. Татар редакциясе җитәкчесе Әлфия Миңнуллина, редакция хезмәткәрләре – журналистлар Вәсилә Шәмсевәлиева, Ләйсән Әсәдуллина, Римма Гатина, Ландыш Гаделшина, Лилия Гаделшина.

– «Татар журналистларына мескенлек хас, кыю фикерле журналистлар юк дәрәҗәсендә», – дигән бәя белән килешәсезме?

– Татарстанда гомер кичергән татарлар – шактый куркытылган, авыр шартларда ничек тә исән калырга өйрәнгән, яраклашкан халык... Курыкмыйча булмый да, югыйсә сыталар. Татар халкының тарихын сөйләп тормыйм, миннән яхшырак белүчеләр бар... Шуңа күрә шушы җәмгыятьтә яшәгән журналист нигә дип үзенең башын балта астына салсын, ди?! Аңардан моны таләп итәргә дә кирәкми. Шуңа да карамастан, журналистлар тел яшерми. Татар телендә күбрәк тә әйтәләр әле. Әгәр кеше үзен мескен дип саный икән, мескен кебек яза. Мескен дип санамый икән, юмор аша булса да, борчыган мәсьәләләрне яңгырата. Беренче чиратта, журналист булып эшләгән кешенең мәгълүмат җиткерергә теләге булырга тиеш. Калганы кешенең холык-фигыленнән тора: кемдер җайлап яза, кемгәдер җәнҗал кирәк…

– Бүген журналистларга игътибар җитәрлекме?

– Ә кемгә бүген игътибар җитә? Журналистлар да җәмгыятьтә яши. «Бу илдә кешенең кадере юк», – дип әйтә иде әти. Үлгәч кенә, зар елап: «Нинди яхшы кеше!» – дип, җирлиләр дә 2 көннән оныталар. Кайчан да булса кешенең кадере артыр, дип өметләник. Шул вакытта журналистларның да кадере артыр.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.
Интертат.

Айга карама

Халык медицинасы чаралары белән дәваланууга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

26 август (шимбә). ***Сәфәр аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,17.54 сәгатьтә калка, 23.11 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.21 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Балан сихәте

Йөрәк авыртканда, 3-4 аш кашыгы баланны 1 стакан кайнар суда 4 сәгать төнәтәләр, көненә 3-4 тапкыр 1 әр стакан эчәләр. Хроник баш авыртудан интеккәндә, көн саен 1-2 стакан балан согын бал белән эчү файдалы. Бөердәге, үт һәм бәвел куыкларындагы ташларны эретү өчен, көн саен 10-15 балан җимешен төше белән берәм-берәм ашарга кирәк. Бавырны чистарту өчен, ярты килограмм баланны эмальләнгән кәстрүлдә йомшарганчы пешерәләр, иләк аша сыттырып чыгаралар, 250 грамм бал кушалар. 2 атна буе иртән ач карынга һәм йоклар алдыннан 2 шәр аш кашыгы кабалар.

27 август (якшәмбе). ***Сәфәр аеның 11нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 18.46 сәгатьтә калка, 0.31сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.16 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Кан тамырларын ныгыту

4 аш кашыгы нарат ылысы, 2 аш кашыгы гөлҗимеш җимеше, 4 аш кашыгы суган кабыгын 0,8 литр суга салып, кайнатып чыгаралар, төреп, төнгелеккә калдыралар. Иртән, сөзеп, тигез 4 өлешкә бүләләр дә, һәр порциясенә 1әр аш кашыгы лимон согы өстәп, көн дәвамында эчеп бетерәләр.

28 август (дүшәмбе). ***Сәфәр аеның 12нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 19.18 сәгатьтә калка, 2.06 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.12 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Буын сызлаганда

3 баш сарымсак һәм 4 лимонны иттарткычтан чыгарып, 1,5 литр кайнар суга салалар, болгатып, 3 тәүлек төнәтәләр, сөзәләр, суыткычта саклыйлар, көненә 1 тапкыр, ашар алдыннан, 1әр аш кашыгы эчәләр. Өлгереп саргайган кыярны иттарткычтан чыгарып, согын сыгып алалар (анысыннан лосьон ясарга була), калган массага тоз кушып болгаталар да, җитен тастымалга сылап, авырткан буынга бәйлиләр, өстеннән пленка һәм шарф урап, 2-3 сәгать тоталар. Тозлы май белән дә дәваланып була. Моның өчен 0,5 килограмм йодлы тоз өстенә аз гына су салып, бөтен су парга әйләнгәнче

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

кайнаталар да, 200 грамм эретелгән каз яки тавык мае кушып болгаталар, яхшылап ябылган карасу төстәге банкада салкынча урында саклыйлар. Буын сызлаганда, йон тукымага шул майны сылап, авырткан җиргә урыйлар.

29 август (сишәмбе). ***Сәфәр аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 19.37 сәгатьтә калка. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.07 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

30 август (чәршәмбе). ***Сәфәр аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 19.50 сәгатьтә калка, 3.45 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.02 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

31 август (пәнҗешәмбе). ***Сәфәр аеның 15 нче көне.16 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 20.00 сәгатьтә калка, 5.23 сәгатьтә бата. 4 сәгать 36 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 13.58 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Диабеттан – миләш

Диабет интектергәндә, кандагы шикәрне киметә торган даруларга өстәп, мондый компот та эчү файдалы: 1әр стакан кипкән миләш һәм грушаны 1 литр суда йомшарганчы пешерәләр, 4 сәгать төнәтәләр һәм көненә 4 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Каһвәтарткычта тарттырылган кипкән миләшне ризыкка кушып ашау да шикәрне киметә.

1 сентябрь (җомга). ***Сәфәр аеның 16нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 20.08 сәгатьтә калка, 6.59 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.54 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Аджика

200 әр г ачы борыч һәм сарымсак, 2,5 кг помидор, 1әр кг татлы борыч, кишер һәм алма, 1 стакан үсемлек мае, өчтән ике стакан шикәр, 2 аш кашыгы тоз, 15 әр г петрушка һәм укроп кирәк. Кузаклы ачы борычның орлыгын алмыйлар, ә татлы болгар борычының эчен бушаталар. Алманы дүрткә бүлеп, төшләрен алалар, кабыгын әрчиләр. Помидорларны кайнар суга тыгып алып, кабыгын чистарталар. Татлы борыч, помидор, кишер һәм алманы иттарткычтан чыгаралар, чуен казанга салып, өстен капламыйча, 40-60 минут пешерәләр. Шуннан соң петрушка белән укроп яфракларын, борыч кузакларын һәм сарымсакны иттарткычтан чыгарып өстиләр. Май, шикәр һәм тоз кушып, яхшылап болгаталар, кайнатып чыгаралар һәм сүндерәләр. Стерильләнгән банкаларга тутырып, тимер капкач белән ябалар.

Мортыда күргәннәрем...

Алабуга районының Морты авылында булдым. Анда баруымның сәбәбе – Морты белән бәйле тарихи шәхесләр турында материал туплау иде. Мортыда мине фикердәшем Раиф Галиев каршы алды. Раиф белән без 1990-1995 елларда Татарстан Югары Советы депутаты булдык, милләт өчен иң мөһим карарларны кабул итүдә катнаштык. Ул үзе яшәгән Түбән Кама шәһәрендә милли хәрәкәткә нигез салды, Татарстанда Аксакаллар Шурасын оештырды һәм җитәкләде, туган авылы Мортыда мәчеткә ярдәм итте, борынгы зираттагы кабер ташларын тәртипкә китерде. Болар өстенә, Казанда һәм Түбән Камада үткән митингларда башлап йөрде, милли һәм дини чараларның барысында да диярлек катнашырга тырышты.

Мине кызыксындырган шәхесләр исә икесе дә дин әһелләре, икесе дә Морты белән бәйле. Әхмәди Мөхәммәди 1873 елда Мортыда туа, 1963 елда Япониянең Кобе шәһәрендә үлә, кабере шундагы мөһаҗирләр зиратында. Ул узган гасырның утызынчы еллар башында, репрессияләр сәбәпле, илдән качарга мәҗбүр була, Харбин аша Кобе шәһәренә килеп урнаша, татар мөһаҗирләре төзегән мәчеттә үлгәнчегә кадәр мөәзин булып эшли.

Әхмәди Мөхәммәдинең Мортыда калган хатыны Хәдичә абыстайны төрмәгә утырталар, ул шунда үлә. Аның фамилиясе Хөснетдинова була, ул 1882 елда Мортыда туа, үлгән елы билгесез. Аларның 5 балалары була. Әхмәди хәзрәт аларга Япониядән хатлар язып тора, әмма үзе илгә кайтырга курка, балаларына «әниегез язмышы кабатланыр дип куркам», дип яза. Сагыш-моң тулы ул хатларны тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Хәзер ул хатлар Әхмәди Мөхәммәдинең оныкчыкларында саклана, аларны өйрәнү, гарәпчәдән кирилл хәрефләренә күчерү дәвам итә.

Без мәчеттә булдык, болар хакында сөйләдек. Авылда Әхмәди Мөхәммәдинең туганнары да яши икән, бабайның Казанда яши торган оныкчыгы монда кайтып, аларны эзләп тапкан. Хәзер золым корбаны Хәдичә әбинең язмышын ачыклау, аның ягыннан да туганнарны эзләү дәвам итә. 2011 елда Казанда «Морт – туган йорт» дип аталган китап басылып чыккан, әмма анда Әхмәди Мөхәммәди һәм Хәдичә абыстай язмышы турында бер хәбәр дә юк.

Кызыксынуга лаек икенче шәхес – Хәбибрахман хәзрәт Мәсәгутов. Ул – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Морты авылы имамы, Алабуга өязенең ахуны, аңа төбәктәге 12 мәчет-мәхәллә карый, ул 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), «Мөселман хезмәт таифәсе» әгъзасы, «Дума» газетасын чыгаручыларның берсе. Ул хәзерге Әгерҗе районының Кодаш авылында 1862 елда туа, 1921 елның апрелендә хәзерге Казахстанның Җидепулат-Семи шәһәрендә үпкә чиреннән үлә. Бу көннәрдә Семи шәһәренең иске татар зиратында Хәбибрахман хәзрәтнең каберен эзләп таптылар, янәшәсендә 5 яшьтә үлгән баласының да кабер ташы бар.

Хәбибрахман Мәсәгутовның кабер ташында аның Морт авылы имамы, Алабуга һәм Сарапул мөхтәсибе, 2 Дума әгъзасы, матбугат хадый, Семипулатта мосафир хәлендә 59 яшендә, 1921 елда үлүе язылган.


ВЯТСКАЯ губернія.

МАССАГУТОВЪ,
ХАБИБРАХМАНЪ САТДИКОВЪ.

Родился въ 1862 г Трудовикъ.

Татаринъ дер. Морты. Ахунъ ортовской мечети.
Образованіе получилъ въ уѣздномъ училищѣ.

71



Дөрестән дә, Хәбибрахман хәзрәт 24 яшендә Морты авылы Җәмигъ мәчетендә имам булып эшли башлый, 1896 елда инде Алабуга өязенең ахуны итеп билгеләнә. Күргәнебезчә, ул җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, Сарапул һәм Алабуга өязләреннән Думага депутат итеп сайлана, милләт хокукларын яклап, «Шура» журналына мәкаләләр яза. Революциядән соң Җидесу төбәгенә китә, үләр алдыннан бер ай Семипалатның Җәмигъ мәчетендә имам булып эшләп өлгерә.

Мортыда Хәбибрахман хәзрәтне хәтерләүчеләр юк инде, әмма нигезе тора. Анда оныгы кайтып өй салган булган, әмма ул үлгәч, нигез марҗа кызларына калган...

«Морт – туган йорт» китабыннан Хәбибрахман хәзрәт турында мәгълүмат эзлим, мондый билгеле шәхес турында язмыйча калмаслар, дип уйлыйм. Дөрестән дә, бар аның турында мәкалә, әмма ул булмаса яхшырак булыр иде. Китапка Мортыда колхоз оештыручы һәм аның рәисе Фома Тихоновның «Дәүләт Думасы депутатлары» дип аталган мәкаләсен биргәннәр, ул 1957 елның 18 декабрендә «Алга» газетасында басылган булган. Минә шул ата коммунист Фома татар муллаcын җир белән тигезли, намусын пычрата, аны эчкечелектә, сәдака өчен кеше кыйнауда, совет власте яклы активистларның исемлеген төзеп, хәтта аларны аттыруда гаепли. Имеш, «Ахун хәзрәт кулына Коръән тотып: «Бар гөнаһларын үз өстемә алам. Атыгыз!» – ди. Аннан халык ачуыннан куркып авылдан качып китә... (Күрсәтелгән хезмәт, 135 бит.)

Бу җыентыкның төзүчесе һәм мөхәррире Гөлүсә Закирова мондый пычрак язманы китапка нинди максат белән кертте икән? Имам һәм җәмәгать эшлеклесе Хәбибрахман Мәсәгутов турында төпле язма бирәсе урында, милләтебезнең билгеле бер шәхесенә яла яккан хәбәрне урнаштырган. Болай итеп ул Хәбибрахман хәзрәтне генә түгел, ул яшәгән һәм эшләгән Морты авылын да, үзенең китабын да түбәнәйткән…

Инде Морты авылы турында берничә сүз. Авыл, дөрестән дә, борынгы, тарихи авыл, заманында милли һәм дини дә булган. Сугыштан соң район үзәге дә булып торган, шул чакта ук авыл мәктәбендә рус класслары ачылган һәм шулай калган. Соңгы елларда исә Морты мәктәбендә укыту нигездә русча гына. Дин дә шул чама. Мәктәпне һәм мәчетне русча сөйләшә торган лезгин балалары тутыра. Алабуга якын булгач, кала урыслары бу авылдан буш калган татар йортларын сатып ала, хәзер Морты урамнарында русча сөйләшеп йөрү гадәти күренеш. Шундый зур, тарихи татар авылының күз алдында урыслашып ятуы – аяныч, әмма җирле халык моңа гадәти хәл итеп карый кебек. Болар хакында авыл зыялылары белән очрашып сөйләшсәм килде, әмма алар клубта сугыш өчен җәтмә бәйлиләр, диделәр. Югыйсә, безнең үзебезгә җәтмәләр салынган бит инде, телебез дә, динебез дә, халык үзе дә җәтмәдәге балык хәлендә... Мортыдан минә шундый уйлар белән кайттым...

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Шәфкать ГАНИЕВ кыйтыклары

Җиз самавыр

Көтмәгәндә танышымның әтисе үлеп китте. Авылда үзе генә яши иде. Җирләп килгәч, хәлләрен сораштым. Авылда бит кеше бер-берсенә ярдәмчел. Авыр вакытларда ташламыйлар, кешенең кайгысын да уртаклаша беләләр. Җидесен дә уздырырга булышканнар.

Әтисен озатып кайткач, күрше әбие кергән. «Менә әтиең сиңа калдырды, акчаң беткәч, уздават итәрсен», – дип, күгәреп беткән җиз самавыр калдырып, чыгып киткән. Танышым югалып калган, әти ни өчен мине шулай мыскыл иткән икән дип уйлаган. «Гарьләндем, самавырны атып бәрәсем килде», – ди. Шулай җиделәре узганчы өйдә торган бу самавыр. Ташларга кулы бармаган. Чыннан да үткән гасыр самавыры бит бу, азмы-күпме бәясе булыр дип, шәһәргә алып килгән. «Антиквариат» дигән игълан буенча шундый әйберләр җыючының адресын да тапкан. «Минем белән бар әле, алдамасыннар», – дип үтенде. Самавырны караштырдым: Туланыкы, озтасының пичәте дә бар. Инетка кереп, бәясен дә чамаладым.

Киттек танышым белән. Ул машинада калды. «Үзең генә кер инде», – ди бу. Кибет хуҗасы самавырның капкачы төшмәскә дип бәйләгән тимерчыбыкны сүтеп ташларга кушты. «Кайчагында таш та салалар эченә, авырлыгын арттыралар, имеш», – дип көлде. Чиләнә-чиләнә ачтым капкачын – егылып китә яздым, валлаһи. Саргаеп беткән кәгазьгә тип-тигез матур хәрефләр белән: фәлән-фәлән алтын акча, көмеш акча, фәлән грамм алтын, фәлән грамм көмеш дип язылган. Пергамент кәгазенә төрелгән берничә төргәк! Баштан мең төрле уйлар йөгереп узды. Тиз кулга алдым үземне.

Самавырның бәясен килештек. Кибеттән ничек чыкканымны хәтерләмим.

Танышыма әтисенең хаты белән төргәкләрне тоттырдым. Ул калтыранган куллары белән бер төргәкне ачкан иде – менә ул кайда байлык – һушын югалтып, ауды да китте. Селкетә торгач, аңына китердем мин аны. Тормыш бит, төрлесе була көтмәгәндә.

Танышың ничек соң дип сорасагыз – ал да гөл, калганын үзең бел дигәндәй. Узган ел Сабантуйда күреп, хәлләрең ничек дип сорамакчы булган идем… Күрмәмешкә салышып узып китте.

Шәүкәт түгел, Шәфкать мин

Исемем Шәфкать бик сирәк очрый, шуңа күрәдер еш кына Шәүкәт дип эндәшәләр миңа. Бервакыт Мәскәүдә командировкада чакта юк кына нәрсә өчен милиция бүлегенә алып киттеләр. Кунакханәдә күрше бүлмәдә яшәгән кыргыз егетеннән акча кыса башлагач, түзмәдем – халыкара мөнәсәбәтләр турында әйттем аларга. Паспортны бөтен документлар белән кунакханәдә калдырганмын. Бәйләнәләр бит болар миңа. «Исемең, фамилияң?» – дигәч, «Шәүкәт Галиев», – дидем. Мәскәү милициясе Ижауга минем эшкә шалтыратып: «У Вас работает Шаукат Галиев?» – дип сорагач, безнекеләр: «Әйе», – дип җавап бирде. Чыннан да, исемем дә, фамилиям дә танылган шагыйребезнекенә охшаган. Соңрак эшкә минем тәртибем турында хат та килде әле. Югалып калмадым: «Өч хәрефе туры килми. Мин бит Шәфкать Ганиев, ә монда Шәүкәт Галиев турында язылган», – дидем. «Ул – танылган язучы», – дип, интернетта аның исем, фамилиясен җыйдым. Танылган татар шагыйре дигән язманы күргәч, бөтенләй аптырап калдылар.

Хәзер дә бутап эндәшсәләр, Шәүкәт абыйны хөрмәтләп искә алам!

Менә шулай

Автобуста кеше күп. Якында гына матур итеп киенгән ике кыз саф татарча сөйләшеп бара. Сирәк күренеш бит, бигрәк тә Ижау өчен. Кешеләр чыга тора, минем дә аяклар кызларга таба атлады. Нәрсә сөйләшәләр икән дип кызыксыну түгел, шушы чын татар кызларының йөзләрен күрәсем килде. Алар янына басуым булды: «Садитесь», – дип берсе миңа урын бирде. «Спасибо», – дидем дә, гадәтемчә, планшетымны ачып яза башладым. «Бу абыйга урын биргән булдым, ә ул яшь икән әле. Контактта кызларга яза», – дип елмаеп әйтте урын биргән кыз икенчесенә. Әлбәттә, мин татарча аңлыйм бит. Түзмәдем, көлеп җибәрдем: «Рәхмәт сезгә, кызлар! Чын татарча матур, төгәл итеп сөйләшкәнегез өчен», – дип әйттем. Өчәүләшеп көлдек. Ә күңелдә матур хисләр калды: шундый яшьләребез күбрәк булса, телебез дә яшәр, иншалла!

Сигарет исе

Мин эшкә 50 минут тирәсе автобуста барам. Планшетымны алып почталарны караштырам, көндәлеккә нидер язып та куям. Гел утырып барам, чөнки мин беренче тукталышта яшим. Бер көнне икенче тукталышта автобуска 40 яшьләр тирәсендәге ир кеше керде, кинәт тирә-якка сасы сигарет исе таралды. Шул арада миңа якташ кешем шалтыратты, аның белән бераз сөйләшкәч: «Радик, әйдә соңрак сөйләшәбез, монда бер сасыган кеше минем янга килеп басты, соңрак, яме», – дип әйткәнемне сизми дә калдым… Теге кеше татар булып чыкты күрәсең, кызарып, тиз генә чыгып китте!.. Хәзер удмурт телендә өйрәнәм шушы ук сүзләрне.

Булдырасыз бит

Эш телефонына бер әби шалтырата. Домофонын төзәтүне таләп итә. Дүрт тапкыр шалтыратты бу. Моның белән безнең фирма шөгыльләнмәвен тырышып-тырышып та аңлатып булмагач, тиешле сервисны таптым да, әбинең адресын бирдем. Аның домофонын төзәткәч, миңа хәбәр итүләрен үтендем. Бераздан: «Ремонтладык, әшне бәяләгез», – дип шалтыратты алар. Мин әбине телефон аша: «Домофоның эшли, төзәттек!» – дип шатландырдым. «Менә бит, теләсәгез, булдырасыз икән. Рәхмәт сезгә!» – диде әбекәй, күңеле булып.

Бер күзле кунак

Дөнья булгач, төрле хәл була бит. Бервакыт мине туй мәҗлесендә фотога төшерергә чакырдылар.Туйның ахырында диярлек соңлап кына бер ир белән хатын-кыз килде. Яшьләрне котлаганнан соң, барысын да җыеп фотога төшерергә уйладылар. Кунаклар болай да арыганнар иде инде. Аларны көч-хәл белән җыйдым, чиләнеп кадр төзедем. Мин һәр кадрны өчәр тапкыр төшерәм, чөнки төркемдә кемдер барыбер күзен йома, кемдер һаман төзәтенә. Бу юлы бер тапкыр төшергәч үк тарала да башладылар. Соңга калып килгән ханым, миңа берничә кадр гына кирәк, зинһар өчен, менә шушы почтага салыгыз әле, дип электрон адресын язып бирде.

Өйгә кайткач та, җибәрим әле онытканчы дип карасам, бу хатынның иренең бер күзе юк. Менә бит, бер генә кадр, анысы да брак! Инде нишләргә?.. Озак чиләнә торгач, фотошоп белән икенче күзен дә ясап куйдым. Фотоны тиз генә почта аша җибәрдем. Бер сәгать тә узмады, теге ханымнан миңа рәхмәтләр язган хат килеп тә җитте. Баксаң, аның иренең бер күзе чыннан да булмаган икән.

Пошмас солдат

Армиядә бергә хезмәт иткән танышымны очраттым. Әлбәттә, кызыклы хәлләрне искә төшердек. «Иң әкрен солдат идең син», – дип көлде танышым. Әйе шул, ротада иң әкрен киенүче мин идем. Ничек кенә тырышсам да, ике-өч секундка артта калам. Уйлый торгач, җаен таптым бит – җиңнәргә сәдәпләрнең урыннарын күчереп тектем, киң итеп… Шул көннән мин иң җитез солдатка әверелдем. Фокусчы сыман, тиз генә киенәм: кулны банкага тыккандай итәм дә, сәдәпләргә кагылып кына алам. Аптыраашта калдылар бары да, ничек итеп шулай оста киенгәнне киткәндә генә әйттем.

Татарча сөйләшәбез

Бер Ижау кешесе: «Тик татарча, рус сүзләрен кушмыйча сөйләш. Безнең тел камил бит», – дип мине гел әрли иде. Бервакыт ул: «Син нәрсә эшлисең? – дип сорады. Мин аңа «Фотосурәткә төшерү өчен әзерләнәм, даими ток чыганагы җыелмасын корам», – дидем. Ул: «Нәрсәәә? Шул ук сүзләрне хәзер кешечә әйт әле», – ди.

Казанышлар китабы

1955 елның 27 августында Гиннессның рекордлар китабының беренче чыгарылышы дөнья күргән. Йөздән артык илдә 25 телдә нәшер ителеп, ул иң күп сатыла торган еллык басма буларак үзе дә рекорд куйган – Библия, Коръән һәм Мао Цзедун цитаталары тупланмасының гына тиражы аныкыннан зуррак. Бу китапка кешелек тормышындагы төрле казанышлар туплана. Алар арасында чынлап сокланырлыклары да, кеше көлдерерлекләре дә бар. Кайберләрен искә төшерик әле. Опера җырчысы Лучано Паваროттины 165 тапкыр биска чакырганнар, алкышлар 1 сәгать 7 минут буе тынмаган. Пушкар Непал исә, китапка керү өчен, минутына 134 тапкыр үз башына үзе суккан. Австралиядән Лес Стюарт дөньяда иң зур һәм иң мәгънәсез китап язган: 16 ел һәм 7 айда ул, җиде язу машинкасын туздырып, 19890 биттә бердән миллионга кадәр саннарны хәрефләр белән язып чыккан. “Даһи” әсәрнең соңгы юлы мондый: “Тугыз йөз туксан тугыз мең тугыз йөз туксан тугыз, бер миллион”. Рекордлар китабына кертелгән россиялеләр дә шактый. Мәсәлән, дөньяда иң күп бала тапкан хатын – Шуя өязе крестьяны Федор Васильевның хәләл җефете (1707-1782). Ул 69 бәби тапкан: 16 игезәк, 7 тапкыр өчәр игезәк, 4 тапкыр дүртәр игезәк. Сабыйларның күпчелеге исән калган. Безнең көннәр каһарманнары - Красноярскидан Николай Петшак һәм Наталья Усачева Тын һәм Төньяк Боз океаннарында Чукоткадан Арктикага кадәр 134 чакрымны бозлы суда йөзеп үткән. Данлыклы фигуралы шуу остасы, өч тапкыр Олимпия, ун тапкыр дөнья чемпионы Ирина Роднина Гиннесс китабына үзенең һөнәри карьерасы дәверендә бер генә ярышта да җиңелмәгән спортчы буларак кертелгән. Виртуоз гитарачы Виктор Зинчук 2001 елда Николай Римский-Корсаковның “Төклетура очышы” вариациясен бик тиз – секундына 20 нота алып, нибары 24 секундта башкарган. 2015 елның 7 маенда Орел шәһәрендә Александр Муромский үзенең китапка кертелгән тугызынчы дөнья рекордын куйган – бер минут эчендә диаметры 10 миллиметрлы 12 тимерчыбыкны башына куеп бөккән. Аңа кадәр ул минут эчендә меңәр битле 11 белешмәлекне ерткан булган. Валентина Закорецкая 1976, 1987, 1998 елларда парашют белән иң күп сикерүче хатын-кыз буларак Рекордлар китабына кертелгән – ул барлыгы 11500 тапкыр сикергән!

(“Интересно.cc”).

Зур җиләк

Кабак – дөньяда иң күп таралган җиләкләрдән берсе, аның кайбер төрләренең авырлыгы 1 килограммга да җитмәскә, кайберләренеке исә 600 килограммнан да артырга мөмкин. Аның ватаны – Мексика, бу ил территориясендә галимнәр моннан 7 мең ел элек үскән кабак орлыкларын тапкан. Дөньяда кабакның сигез йөздән артык төре бар, шулардан ике йөз төре генә ашарга яраклы. 1 литр май алу өчен 35 кабак кирәк. Әлеге сихәтле май кандагы холестерин микъдарын киметә һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан саклый. Ул A, E, К, В, С, D витаминнарына, селен, натрий, калий, магний, тимер, кальцийга, бета-каротинга бай, фосфор һәм кремний кислоталары да шактый. Кабак 90 процентка судан тора, 100 граммында нибары 25 калория бар. Тутыяга (цинкка) бай булганга, кабак төше бигрәк тә ир-атларга файдалы.

(“ИнтересNIK”).

Тамаксау патша

Англия короле Генрих VIII тиран һәм залим буларак тарихка кергән, җитмәсә ул алты тапкыр өйләнгән һәм бик комагай булган. Аның күп вакыты ашап үткән. Корольгә сыйны илле бүлмәдә 200 пешекче әзерләгән, табында һәрвакыт егермедән артык ризык торырга тиеш булган. Генрих озак йокларга яратмаган, һәм инде иртәнге сәгать 6 да аңа алты бәлеш китергәннәр. Шуннан соң ул ит ашаган һәм сыра эчкән. Ул чакта король табынында яшелчә һәм җиләк-җимеш бик сирәк пәйда булган, чөнки зыянлы ашамлыкка саналган. Ә 1569 елда, чума һәм ваба чирләре таралу чыганагы дип, аларны бөтенләй тыйганнар. Корольнең аш пешерүчеләре тәүлек буе эшләгән, ризыклар аның бихисап кунакларын сыйларга да җитәрлек булган. Түшкәсе белән ит кыздырганда пешекчеләргә ис тимәсен өчен, шешне этләр әйләндергән. Аларны барабан кебек читлеккә кертеп, тәгәрмәчтәге тиен кебек әйләндергәннәр. Ризыкларны көмеш савытларга куйганнар, кашык һәм пычак белән генә ашаганнар - ул вакытта дошман саналган италиялеләр уйлап тапканга, Генрих чәнечкене санга сукмаган. Король баллы ризыкларга мөкиббән киткән, ул чакта шикәр кыйбат торганга, барлык баллы сыйны сандыкка бикләп саклаганнар. Генрих хәтта бөтен итле ризыкларга да шикәр сиптергән. Ул бик симергән, шикәр чиреннән интеккән, бил әйләнәсе 137 сантиметрга җиткән. Әмма гомеренең соңгы көннәренә кадәр король, иң шәп диета – ит һәм шикәр, дигән фикереннән кайтмаган.

(“Интересно.cc”).

Теленңне йотма!

Дөньяның төрле илләрендә нинди генә деликатеслар очрамый. Безгә күңел болгаткыч булып тоелган ризыклар кем өчендер искиткеч тәмле тоела. Кытай, Малайзия, Вьетнам, Тайвань, Сингапурда карлыгач ояларыннан пешерелгән аш деликатеска санала. Мәгарәләрдәге яр карлыгачлары, диңгез сүүсемнәрен үз селәгәйләре белән беркетеп, ап-ак оя кора, шуның килограммы 2500 долларга бәяләнә. Кайбер кошлар исә оя ясаганда каурый, маймычлар, хәтта балык уылдыгы да куша. Мондыйлары да ашарга яраклы, әмма аклары кебек үк кыйммәт түгел. Җыючылар әле кошлар бала чыгарып өлгермәгән ояларны табарга тырыша, кайвакыт керәшәләргә бер сезонда бернича оя ясарга туры килә, чөнки кешеләр әзер булган саен алып китеп бара. Шунлыктан кошлар аларны чукый, тырный, кычкыра, тик кешене җиңә алмый. Карлыгач оясыннан пешерелгән аш дөньяда иң борынгы нигъмәтләрдән исәпләнә, ул 618-907 елларда кулланыла башлаган дип фаразлана. Риваятьләр буенча исә, XIII гасырда Чыңгыз хан Кытайга һөҗүм иткәндә, император Цзинь армиясенең соңгы сугышчылары белән бер утрауда яшеренә. Анда үлән һәм кошлардан башка бернәрсә дә булмый, шунлыктан карлыгач оясыннан аш пешерергә өйрәнәләр, һәм ул күбесенең күңеленә хуш килә. Әлеге аш куелыгы белән кесәлне хәтерләтә, үтә күренмәле була. Ул көч-куәт, дәрт өсти, дип санала. Иң кыйммәтле оялар Малайзиядә җыела. Бирегә ел саен 25 тонна карлыгач оясы җыеп, дөньяның төрле илләренә җибәрәләр.

(“Вокруг света”).

Газета өчен
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

28 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «СВАТЫ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Родная земля». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Алсу Тимергалина турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Адымнар». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «АВАНТЮРИСТКИ». 16+
11.10 «Архивы истории». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОДНОЛЮБЫ». 16+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Севморпуть. Дорога во льдах». 6+
16.30 «НА ДАЛЬНЕЙ ЗАСТАВЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ВОЛШЕБНИК». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00, 20.15 «Престольный праздник. Успение Пресвятой Богородицы».
7.40 «Я очень люблю эту жизнь...»
8.20 «ХОЗЯЙКА ДЕТСКОГО ДОМА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Писатели нашего детства. «Приоткрытая дверь. Писатель Л. Пантелеев».
10.45 «ИЮЛЬСКИЙ ДОЖДЬ».
12.45 «Печоры. Ворота Вечности».
13.15 Линия жизни. Василий Мищенко.
14.10 «Гиперболоид инженера Шухова».
14.45, 23.25 «Три минуты тишины».
14.50, 23.30 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.30 Искусственный отбор.
16.15 «Предки наших предков».
17.15 «Запечатленное время».
17.45 Российские музыкальные фестивали. XIII Международный виолончельный фестиваль VIVACELLO.
18.40 «История жизни».
19.45 Невский ковчег. Теория невозможного. Евдокия Дашина.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Георгий Свиридов. Остановись, время!»
22.00 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
23.40 «Путь бойца». 18+

Сишәмбе

29 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «СВАТЫ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Казаннан - казанга». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 0.50 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30 «Заман көзгесе». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОЛШЕБНИК». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОДНОЛЮБЫ». 16+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Севморпуть. Дорога во льдах». 6+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Первые в мире».
7.20, 16.15 «Предки наших предков».
8.00 «Жизнь и судьба».
8.20 «ХОЗЯЙКА ДЕТСКОГО ДОМА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Писатели нашего детства. «На самой легкой лодке. Юрий Коваль».
10.45 «НАШЕ ПРИЗВАНИЕ».
12.00 «Школа будущего». «Мир без учителя?»
12.45 Земля людей. «Карачаевцы. Большая река».
13.20, 22.00 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
14.45, 23.25 «Три минуты тишины».
14.50, 23.30 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.30, 20.15 Искусственный отбор.
17.15 «Запечатленное время».
17.45 Российские музыкальные фестивали. Московский международный фестиваль «Виртуозы гитары».
18.40 «История жизни».
19.45 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Колчак.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.20 «Николай Обухович. За амальгамой бытия».

«НТВ»
4.40 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
23.40 «Путь бойца». 18+

Чәршәмбе

30 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 22.05 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+
14.00 «Каравай». 6+
14.45 «Новый век Татарстана». 16+
15.15 «Халкыбыз мирасы».
16.30 «Татарлар». 12+
17.00 «Халкым минем...» 12+
17.30 «Зов Родины». 16+
18.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты.
19.00, 20.00 «Туган көнең белән, Республикам! С Днём рождения, Республика!»
22.35 «БЕСТСЕЛЛЕР ПО ЛЮБВИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Казан» бию ансамбле концерты. 16+
9.30 Спектакль «Мәхәббәт турында сөйләшик». 16+
12.05 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.00, 18.30, 22.05, 0.00 «Яңалыклар». 16+
15.30 «Халкыбыз мирасы - Народное наследие». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+
17.30, 0.40 «Татарлар». 12+
18.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты. 6+
19.00 «Туган көнең белән, Республикам! С Днем рождения, Республика!» 6+
22.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОЛШЕБНИК». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОДИН СУНДУК НА ДВОИХ». 12+
14.30 «Архивы истории». 12+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Русская Антарктида. XXI век». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Первые в мире».
7.20, 16.15 «Предки наших предков».
8.00 «Жизнь и судьба».
8.25 «СЛАДКАЯ ЖЕНЩИНА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Писатели нашего детства. «Быть взрослым очень просто... Валентин Берестов».
10.45 «НАШЕ ПРИЗВАНИЕ».
12.00 «Школа будущего». «Школа идёт к вам».
12.45 Земля людей. «Сойоты. Тайна древнего имени».
13.20, 22.00 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
14.45, 23.25 «Три минуты тишины».
14.50, 23.30 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.30 «Николай Обухович. За амальгамой бытия».
17.15 Российские музыкальные фестивали. XV Зимний международный фестиваль искусств.
18.40 «История жизни».
19.45 Невский ковчег. Теория невозможного. Абрам Ганнибал.
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.10 105 лет со дня рождения Михаила Рожкова. Линия жизни.

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
23.40 «Путь бойца». 18+

Пәнҗешәмбе

31 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00 «Зов Родины». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АННА ГЕРМАН». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
17.30 «Точка опоры». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10 «Ватандашлар». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
21.25 «Йөрәктән-йөрәккә» Искәндәр Гыйләҗев турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»
1.15 «Театральное закулисье». 12+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОЛШЕБНИК». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОДИН СУНДУК НА ДВОИХ». 12+
14.30 «Вместе с наукой». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Русская Антарктида. XXI век». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».

9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Первые в мире».
7.20, 16.15 «Предки наших предков».
8.00 «Жизнь и судьба».
8.25 «Забытое ремесло».
8.40 «ТРАКТИРЩИЦА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Писатели нашего детства. «Редактор «Лесной газеты». Виталий Бианки».
10.45 «НАШЕ ПРИЗВАНИЕ».
12.00 «Школа будущего». «Большая перемена».
12.45 Земля людей. «Тундренные юкагиры. В Созвездии оленя».
13.20, 22.00 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
14.45, 23.25 «Три минуты тишины».
14.50, 23.30 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.30, 20.15 Искусственный отбор.
17.15 Российские музыкальные фестивали. Рамон Варгас и солисты музыкального театра «Геликон-опера» под руководством Д. Бертмана на VII Международном фестивале искусств П.И. Чайковского в Клину.
18.40 «История жизни».
19.45 Невский ковчег. Теория невозможного. Владимир Балыбердин.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.10 100 лет со дня рождения Галины Серговой. Линия жизни.

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
23.40 «Путь бойца». 18+

Җомга

1 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 Хоккей. ЦСКА - «Ак Барс». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ПОЗНАЛ БЕСКОНЕЧНОСТЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Татар халык җырлары». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Роберт Миңнуллин турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ВОЛШЕБНИК». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДЖИМ ПУГОВКА И МАШИНИСТ ЛУКАС». 6+
15.00 «Джек и механическое сердце». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ДУЭЛЯНТ». 16+
23.45 «ПРО ЛЮБОFF». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Уже не дети». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню знаний.
23.40 «ДВА БИЛЕТА ДОМОЙ». 18+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Первые в мире».
7.20 «Предки наших предков».
8.00 «Жизнь и судьба».
8.20 «ПЕРВОКЛАССНИЦА».
9.30 «Запечатленное время».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.25 «Я - ВОЖАТЫЙ ФОРПОСТА».
12.00 «Школа будущего». «Школа без звонка».
12.45 «Траектория Глушко».
13.20 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
14.45, 22.00 «Три минуты тишины».
14.50 К 95-летию Иона Друцэ. «Театральная летопись. Избранное».
15.45 Искусственный отбор.
16.30 «Лесной дворец Асташово».
17.15 Российские музыкальные фестивали. Фестиваль Российского национального оркестра в музее-заповеднике «Царицыно». Солист Константин Емельянов. Дирижер Алексей Богорад.
18.25 Линия жизни. Шалва Амонашвили.
19.45 Искатели. «Либерея: в поисках потерянной библиотеки».
20.35 «ДВА ФЕДОРА».
22.05 65 лет Сергею Гармашу. «Белая студия».
22.55 Спектакль «Кроткая».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+

Шимбә

2 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Болгар радиосы» концерты. 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Ялт-йолт». «Мунча ташы»ның сатирик күңел ачу тапшыруы. 16+
17.30 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «ХОТЕЛ БЫ Я БЫТЬ ЗДЕСЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Нажар Нәҗми турында телеочерк. 16+
7.00, 15.05 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 Спектакль «Сихерче». 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Мәхәббәтле көзләрем». Роберт Миңнуллинның юбилей кичәсе. 12+
23.00 Спектакль «Әлдермештән Әлмәндәр». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Вместе с наукой». 12+
5.30 «Предки наших предков». 12+
6.30 «Я тебя знаю». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «БОЛЬШОЙ АРТИСТ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МАМА НАПРОКАТ». 16+
14.45 «Ночной дожор». 12+
15.45 «ВЕРНЕШЬСЯ - ПОГОВОРИМ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БЕГЛЕЦЫ». 12+
22.30 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Прими «Вызов» - почувствуй силу!» 12+
14.40 Ко дню рождения Елены Прокловой. «До слез бывает одиноко...» 12+
15.25 «БУДЬТЕ МОИМ МУЖЕМ». 12+
17.05 «Александр Балуев. Герой, одержимый страстью». 12+
18.20 «Сегодня вечером». 16+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 «9 ПРИЧИН, ЧТОБЫ ЖИТЬ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 Фестиваль детской художественной гимнастики «Алина».
12.45 «НЕСЛОМЛЕННАЯ». 12+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ПУСТОЙ ДОМ». 12+
0.40 «ЯРКИЕ КРАСКИ ОСЕНИ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.30 «В НОЧЬ ЛУННОГО ЗАТМЕНИЯ».
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ДВА ФЕДОРА».
11.40 «Передвижники. Григорий Мясоедов».
12.10 Черные дыры. Белые пятна.
12.50 «Первые в мире».
13.05, 22.35 «Три минуты тишины».
13.10 Гала-концерт Международного фестиваля народной песни «Добровидение».
14.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.00 Большие и маленькие.
17.55 «КЛЮЧ БЕЗ ПРАВА ПЕРЕДАЧИ».
19.45 «Эстрада, которую нельзя забыть».
20.35 «ЖЕЛЕЗНАЯ МАСКА».
22.40 Клуб «Шаболовка, 37».
23.45 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «НашПотребНадзор». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.30 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

3 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Сынатмый яшик!» Илсур Сафинның юбилей кичәсе. 16+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20, 20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
14.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ТЫ У МЕНЯ ОДНА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Кайда сез, яшьлек елларым». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Рәхмәт сиңа». Равил Галиев һәм Резидә Шәрәфиева концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 Спектакль «Мәхәббәт чишмәсе». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Вместе с наукой». 12+
5.30 «Предки наших предков». 12+
6.30 «Я тебя знаю». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30, 14.35 «Первые в мире». 12+
8.45 «ВЕРНЕШЬСЯ - ПОГОВОРИМ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОТ ПРАЗДНИКА К ПРАЗДНИКУ». 12+
14.50 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.45 «БОЛЬШОЙ АРТИСТ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПОЙМАННЫЙ В РАЮ». 16+
22.50 «ОБ ЭТОМ ЛУЧШЕ НЕ ЗНАТЬ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Повара на колесах». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.10 «РОЗЫГРЫШ». 12+
16.05 К 65-летию Сергея Гармаша. «Какой из меня Ромео!» 12+
17.00 «Звезды на передовой». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «МАТЬ МОЕГО СЫНА». 16+

«РОССИЯ»
6.10 «ПОРТРЕТ ЖЕНЩИНЫ В КРАСНОМ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Большие перемены». 6+
12.35 «НЕСЛОМЛЕННАЯ». 12+
17.50 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.45 «ЗА ВСЕ В ОТВЕТЕ».
9.55 Диалоги о животных.
10.35 «ДРУГ МОЙ, КОЛЬКА!..».
12.00 «Башкирия. Из Уфы к Юмагузинскому водохранилищу».
12.40 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Кедринский.
13.05, 23.30 «Три минуты тишины».
13.10 Гала-концерт Международного фестиваля народной песни «Добровидение».
14.25 «Игра в бисер» «Валентин Распутин. «Уроки французского».
15.05 «УРОКИ ФРАНЦУЗСКОГО».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.30 «Пешком...»
18.00 Большая опера. Гала-концерт в Уфе.
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «Эстрада, которую нельзя забыть».
21.10 «АННА КАРЕНИНА».
23.35 «Лесной дворец Асташово».

«НТВ»
4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! Суперсезон». 6+
23.15 «Звезды сошлись». 16+

Дәрдемәнд даирәсендәге шәхесләр

● Закир Рәмиев-Дәрдемәнд.

(Ахыры. Башы 8-9 нчы битләрдә).

Элекке редакторның басмаханә идарәсе белән килешмәве һәм Закир Рәмиев-Дәрдемәнд белән аерылышуы нилектән килеп чыккан соң? Бу сорауларга өлешчә җавапны Фатих әфәнденең сеңлесе Закирә Шәрәфнең истәлек язмаларында китерелгән Сәхи Рәхмәти хатларыннан чамаларга була. Сәхи Рәхмәти берара «Вакыт»та да күренгәләп киткән, шул төркемгә кергән кешеләр белән якыннан аралашкан шәхес. 1917 елдан соң ул Совет хакимияте оешмаларында актив катнашкан кеше. Хәзер аның Закирә Шәрәфкә язган хатларыннан кайбер өзекләр китерик.

«Февраль революциясенең башларында ук Фатих абзый «Вакыт»та эшләүне ташлау фикеренә кушыла. «Һава үзгәрә, дулкын якынлаша. Шуңар хәзерләнеп эшли башларга кирәк. Үз фикеремне иркенрәк язуыма идарәдә каршы карыйлар. Яңалык ишек төбенә килеп җитте,» дия иде ул... Шул арада «Вакыт» редакциясендә үзгәрешләр булып алды... «Яңа вакыт» исеме белән (яңа) газета чыга башлады. Фатих абый янәдән күңел биреп, җиң сызганып (шунда) эшкә керешүе. «Яңа вакыт» кызыл гаскәр Оренбургны алгач та чыгып торды. (1918 елның гыйнвар урталары була). Ә «Вакыт» 1918 елда чыгудан туктады», дип хәбәр итә С.Рәхмәти ул хатында.

Әйе, хаттагы соңгы җөмләдә бертуган Рәмиевләр нәшер иткән «Вакыт» газетасының большевиклар тарафыннан 1918 елның 25 гыйнварында ябылуы турында хәбәр ителә. Ф.Кәрими киткәч «Вакыт» газетасы өч ай чамасы Ярулла Вәли мөхәррирлегендә нәшер ителгән. Байларның, буржуйларның мал-мөлкәте кичекмәстән Совет хакимиятенә тапшырылырга тиеш, дигән карарны үтәп, Закир Рәмиев белән Я.Вәлиев шул ук көннәрдә (гыйнвар ахырында) «Вакыт» типографиясен дә Совет хакимияте вәкилләре кулына «тоттыралар». Шул ук карарда күрсәтелгәнчә, Дәрдемәнд яңа хуҗаларга басмаханә ике атна дәвамында тоткарлыксыз эшләрлек күләмдә акча да тапшыра. Киләсе атнада ук элекке «Вакыт» басмаханәсендә Заһид Шәркый-Йосыпов мөхәррирлегендә «Мөхбир» газетасы нәшер ителә башлый...

Янәдән Сәхи Рәхмәти хатында теркәлгән вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк. Анда мондый җөмлә дә бар. «Аның Октябрь революциясенә карашын күрсәтер өчен «Яңа вакыт» газетасында Фатих Кәрими имзасы белән басылган баш мәкаләнең берничә җөмләсен күчерү дә җитәр. «Ниһаять Октябрь революциясе булды. Монысы инде чын-чыннан зур үзгәреш иде. Бу үзгәрештә бөтен хакимиятне халык үз кулына алды», диелә ул баш мәкаләдә». Әйе, чордашы кабатлап язган шушы җөмләләрне укыгач та Фатих Кәриминең ул еллардагы фикер үзгәрешен тоясың, аңлыйсың...

1919 елның гыйнварында кызыллар гаскәре Оренбург шәһәрен икенче мәртәбә яулап ала. Атаман Дутов гаскәре шәһәрдән бик еракка һәм бөтенләйгә куып җибәрелә. Яңа тормыш башлана. «Яңа вакыт»ның элекке редакция бүлмәсендә узган бер утырышны да Сәхи Рәхмәти бик тәфсилләп искә ала. Анда катнашучылардан комиссарлар Шамил Усманов, Кәрим Хәкимов, Карип Хайруллин, Гали Шәмигулов һ.б. белән бергә журналистлар Фатих Кәрими, Борһан Шәрәф, Заһид Шәркый-Йосыпов, Шәриф Камал, Сәхи Рәхмәти һ.б. да була. Ул утырышта Ф.Кәримине яңа заманга ятышлы, «большевистик эчтәлекле» яңа чыга башлаячак газета редакторлыгына димлиләр. Бу очракта ул: «Шул партиядә тормагач, мин бу газетага баш мөхәррир була алмыйм. Болай эшләү сезгә сәяси зыян булып чыгарга ихтимал... Сезнең гәзитәдә эшләүдән дә баш тартмыйм. Тик баш мөхәррир булып эшли алмам», дип белдерә ул. Җыелыштагылар шуннан соң шундый ук тәкъдим белән Борһан Шәрәфкә мөрәҗәгать итә. Ул да бу эшкә алынмый. «Хәзерге вакытта бик күләмле бер тарихи хезмәтне эшләргә алындым, шуның белән утырам», дип җавап бирә. Шул утырышта чыгачак газетаның биш кешелек редакция советы сайлана. Берничә большевик белән бергә ул советка Фатих Кәрими дә керә.

Ә элек ул баш мөхәррир булган «Яңа вакыт» газетасы 1918 елның 3 нче октябрендә үк – Дутовчылар шәһәрдә баш булган чорда чыгудан туктатыла.

Элек Дәрдемәнд даирәсенә кергән, аеруча хөрмәт ителгән Шәриф Камалның да шул ук үзгәрешләр чорында мәҗбүри рәвештә диярлек беркадәр сулга талпынышы сизеләчәк. Дөрес, бу вакыйгалар чорында Дәрдемәнднең үзенең дә мәҗбүри рәвештә, 1918 елның гыйнвар ахырында ук, Оренбургны ташлап, приискаларга якынрак булган Орск шәһәренә китүенә дә бәйледер. Ул Совет хакимияте Оренбургны беренче мәртәбә берничә айга яулап алгач ук диярлек шәһәрдән китә һәм аңа кабат шунда кайтып яшәү насыйп булмый. 1921 елның сентябрендә Оренбургта тиф чиреннән вафат булган кызы Өммегөлсемне соңгы юлга озату вакыйгаларында катнашканнан соң, октябрь ае башында ул Орск шәһәрендә шул ук авырудан вафат булачак...

Лирон ХӘМИДУЛЛИН.
2014-2020 еллар.

● «Кызыл паша» Кәрим Хәкимов.

● Шамил Усманов.

Атнаның сәяси мизгелләре

Ашлык һәм сәясәт

Төркия президенты Р.Эрдоганның август аенда Анкарада РФ президенты В.Путин белән күзгә-күз очрашып сөйләшү теләге барып чыкмас кебек. Чөнки соңгы вакытларда В.Путин үз иленнән читкә чыгарга базмый башлады (бу атнада инде ул хәтта БРИКС саммитына да тышкы эшләр министры С.Лавровны гына җибәрде). Кремльдә элегрәк моны, хәзер вакыты шундый, Путинга илдә булырга кирәк, дип аңлаттылар. Ә NTV телеканалы хәбәр итүенчә, В.Путин белән очрашу өчен Төркия лидеры Мәскәүгә үзе дә килергә мөмкин һәм аның сәфәре ашлык алыш-биреше буенча килешүне яңартуда хәлиткеч әһәмияткә ия булачак. Очрашуда шулай ук ике арадагы мөнәсәбәтләр һәм Украинадагы хәтәр хәлләр дә игътибар үзәгендә булырга мөмкин икән. Билгеле булганча, ашлык сәүдәсе буенча килешү 18 июльдә РФ таләбе буенча туктатылды. Мәскәү моны үзенә карата килешү шартларын үтәлмәве белән аңлатты. Анкара исә ашлык буенча альтернатив килешү төзү мәсьәләсендә Вашингтон белән дә киңәш-табыш иткән. АКШның бу мәсьәләдә Украина һәм ЕС белән сөйләшүләр алып баруы да мәгълүм. Әмма кыенлыкларның авыр башы иң элек Африканың ашлык кытлыгы кичерә торган илләренә төшә.

Көнбатыш Африка илләренең икътисади җәмгыяте (ECOWAS) Нигерга каршы хәрби интервенциянең инде датасын да үзара килештергән. Ә хәрби фетнәчеләр лидеры генерал Габдерахман Тчиани, илнең эчке эшләренә тыкшыну да оккупация буларак бәяләнәчәге турында кисәткән. Шуңа карамастан, ECOWAS илләре аэропортларында Нигердагы фетнәчеләргә каршы хәрби операциягә әзерлек башланган. Ә фетнәчеләр интервенция куркынычы фонында илдә «ихтыяри мобилизация» игълан иткән.

Игътибарны сәяси атнаның башка вакыйгалары да җәлеп итә. Йоханнесбургта (КАР) БРИКСның 15 нче саммиты башланды. Аурупа комиссиясе (ЕК) Украинага 2023 елга планлаштырылган 18 миллиард евро күләмендәге ярдәмнән тагын 1,5 миллиард евросын түләгән. РФ Иминлек советы секретаре Н.Патрушев Магаданда, Ерак Көнчыгыш федераль округының иминлек буенча киңәшмәсендә, Россия дөньяны Көнбатыш акылсызлыгыннан коткарырга тиеш, дип белдергән. Япония 2024 нче финанс елына хәрби бюджетны моңарчы күрелмәгән күләмдә – 53 миллиард доллар итеп әзерли. Июль аенда Кытай АКШның дәүләт әҗәтенә кертемен тагын 11,3 миллиард долларга – 835,4 миллиард долларга кадәр киметкән.

Кадр артында – табиб

Рөстәм Хәйруллинны күпләр талантлы табиб, төбәкара клиника-диагностика үзәгенең генераль директоры, 120 дән артык фәнни мәкалә һәм бер патент авторы буларак белә. Ә менә аның фоторәссам икәне бик сирәкләргә генә мәгълүмдер.



Наил улы Рөстәм фото белән 13 яшьтән үк шөгыльләнә. «Россия суы» бәйгесендә җиңгән, «Фотопризер» дип исемләнгән халыкара бәйгедә беренчелекне яулаган, Рус география җәмгыятенең төрле проектларында катнашкан.

Р.Хәйруллинның иҗат эшләрен гап-гади фото дияргә тел әйләнми. Аларда авторның иҗат кешесенә генә хас нечкә күңеле тоемлана. Мәктәп елларында, яшүсмер чакта иҗатның бөтен төрләрен дә якын итүе, әйтик, байтак еллар балчык әвәләве дә, республикабызның баш табибы дәрәҗәсенә ирешсә дә, Рөстәм Наил улының хисле шәхес булуын искәртә.

Ушу, каратэ, тхэквондо кебек көрәш төрләре белән шөгыльләнүе дә үз-үзен һәм дөньяны тирәнрәк аңларга ярдәм иткәндер, мөгаен, чөнки һәркайсының нигезендә фәлсәфә ята.

Фоторәссам пейзажларны аеруча яратып кадрга ала. Кешенең күңел халәте табигать торышы белән тыгыз бәйләнгән дип саный ул. Пейзажлардагы энергия кешене төшенкелектән дәваларга, күңелендә өмет уятырга мөмкин, ди.

Бу сәхифәбездә Р.Хәйруллинның «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә күрсәтелгән кайбер иҗат эшләрен тәкъдим итәбез. Анда авторның 70 ләп фоторәсеме урнаштырылган иде. Һәрберсе зур итеп эшләнгән һәм берсе дә кысага утыртылмаган. Кысалар булмагач, пейзажлардагы елга-күлләр менә-менә тамаша залына агып чыгар кебек.

Ә бер көнне экспозицияне Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә килеп карады.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип өчен В. ИМАМОВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазлаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 25.08.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе иркен

Тираж – 2550 данә

Заказ 2632

16+